Әхмәдһади Максуди

ГЫЙБАДӘТЕ ИСЛАМИЯ

Әхмәдһади Максуди

ГЫЙБАДӘТЕ ИСЛАМИЯ

Издательский дом Хузур

Казан – 2016

УДК 28
ББК 86.38
М-17

ӘХМӘДҺАДИ МАКСУДИ

ГЫЙБАДӘТЕ ИСЛАМИЯ – Казан: «Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты, 2016 – 176 б.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең эксперт шурасы №16-18 карары нигезендә бастырырга рөхсәт ителә.

12+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436-ФЗ.

Танылган татар галиме Әхмәдһади Максуди хәзрәтләренең «Гыйбадәте Исламия» китабы гасырдан артык гыйбадәт кылуда ярдәмлек ролен башкарган классик дәреслек, татар халкының, мөселманнарның рухи мирасы булып санала. Бу китапта Хәнәфи мәзһәбе шәригате гадиләштерелгән вариантта тәкъдим ителә. Хезмәттә исламның биш баганасы турында сөйләнә. Аның мәгънәсе, нәрсә өчен кирәклеге һәм куллану рәвеше аңлатыла. Автор Әхмәдһади Максуди диндәге әһәмиятле һәм шул ук вакытта четерекле мәсьәләләрне гади һәм бар кешегә дә аңлаешлы тел белән бәян итә алган. Китап диндә беренче адымнарын ясаучыларга да, шул ук вакытта исламда күптәннән булучы кешеләр өчен дә файдалы һәм актуаль булып тора.

Китап битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала

ISBN 978-5-9907871-2-4

© Ә. Максуди, 2016

بسم الله الرحمن الرحيم

Исламда традицион сәлам бирү сүзләре түбәндәге тамгалар белән белдерелә:

ﷺ аңа Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын
салләллаһу галәйһи вә сәлләм
(Пәйгамбәребез ﷺ гә сәлам юллаган вакытта)

عليه السلام аңа Аллаһының сәламе булсын
галәйһиссәлам
(башка пәйгамбәрләрне һәм олуг фәрештәләрне искә алгач)

رضي الله عنه Аллаһ аннан разый булсын
радый Аллаһу гәнһу
(Пәйгамбәребез ﷺ нең сәхабәләрен искә алганнан соң)

رضي الله عنها Аллаһ аннан разый булсын
радый Аллаһу гәнһә
(Пәйгамбәребез ﷺ нең хатыннарын һәм сәхабә хатын-кызларны искә алганнан соң)

رضي الله عنهم Аллаһ алардан разый булсын
радый Аллаһу гәнһүм
(берничә сәхабәне искә алганнан соң)

رحمه الله аңа Аллаһының мәрхәмәте булсын
рәхимәһуллаһ
(галимнәрнең исемен искә алганнан соң)

ӘХМӘДҺАДИ МАКСУДИ

Әхмәдһади Максуди (Һади Максуди, Әхмәд Максуди буларак та билгеле) – атаклы татар мөгаллиме, җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм нәшир. 1868 елның 28 сентябрендә Казан губернасы Ташсу авылында (хәзерге Биектау районына керә) авыл мулласы Низаметдин гаиләсендә туган. Бу гаиләдә татар дөньясының ике олуг шәхесе – Һади һәм Садри Максудилар туып үскәннәр.

Әхмәдһади башта үз авылындагы әтисе мәдрәсәсендә укый. 1881 елны ул Казанга килә, заманының мәшһүр мәдрәсәләренең берсе булган «Күл буе» мәдрәсәсенә укырга керә һәм сигез ел дәвамында шунда белем ала. Укып бетергәч, 1890-1892 елларда шунда мөгаллимлек итә. Мәдрәсә мәгариф системасына җитди үзгәрешләр кертергә кирәклеген аңлап, Һади хәзрәт 1892 елда татар мәгарифендә чын мәгънәсендә инкыйлаб ясый: татар әлифбасына 6 хәреф кертә һәм «Имляда ишетелгәнчә язу тиешле» дигән кагыйдәсеннән файдаланып, үзенең «Мөгаллим әүвәл» әлифбасын бастырып чыгара. Әлеге дәреслек 1918 елга кадәр барлыгы 32 басма кичерә, татар балалары өчен генә түгел, ә казакъ, башкорт, кыргыз, үзбәк балаларының да уку китабы булуы белән уникаль күренешкә әйләнә.

1894 елда Истамбулга сәяхәт итеп, андагы мәктәп-мәдрәсәләрне күреп, Әхмәд Мидхәт (1884-1913), Әхмәд Җәүдәтләр кебек мәшһүр төрек әдип-мәгърифәтчеләре белән аралаша. Истамбулдан кайтышлый Кырымда, заманының университеты булган Зынҗырлы мәдрәсәсендә гарәп әдәбияты һәм мантыйк фәннәре мөгаллиме булып хезмәт итә. Зынҗырлы мәдрәсәсендә рус теле мөгаллиме Исмәгыйль әфәнде Леманковдан үзе

русча укый, Лемановка гарәп һәм татар әдәби телләре буенча сабак бирә. Кырымда ике ел мөгаллим булып торганнан соң Казанга кайтып, күп дәреслекләр яза. Әйтергә кирәк, Әхмәдһади Максудиның рус, гарәп һәм татар телләре буенча эшкәрткән дәреслекләре заманында зур абруй казанып дистәләгән еллар дәвамында нәшер кылына.

Әхмәдһади хәзрәтнең 40 тан артык хезмәте билгеле. Ул 1898 елда нәшер ителгән «Шифаһия» дип исемләнгән гарәп телендәге укыту әсбабы авторы. 1925 елда Рәсәй мөселманнары өчен үзөйрәткеч ролен үтәгән «Русистан. Гамәли дәреслек» һәм рус телендә «Самоучитель татарского языка для русских» китапларын язучы. Шулай ук Әхмәдһади Максудиның хезмәтләрен рус, гарәп, төрек телләрендә фәнни, һөнәри һәм әдәби терминнар язуы тулыландыра. Аның мәктәп дәреслекләре сыйфатында кулланылган, Ислам динендә популяр булган «Гакыйдә», «Намаз», «Тәһарәт», «Җәмәгать», «Гыйбадәте Исламия», «Мөгаллим сәни», «Пәйгамбәрләр тарихы», «Галәм турында белешмә» исемле хезмәтләре билгеле.

Әхмәдһади хәзрәт 1906 елның башында татар телендә «Йолдыз» газетасын чыгара башлай. Бу газета 13 ел дәвамында чыга.

Бөек Октябрь инкыйлабыннан соң да галим-педагог фәнни мәсьәләләр белән кызыксынуын дәвам итә. Аеруча аның 1928 елда Казанда нәшер кылынган, безнең көннәрдә дә әһәмиятен югалтмаган «Фәнни сүзлеге» игътибарга лаек.

Ул, вакыйгаларга бай гыйльми хәят кичереп, 1941 елда Казан шәһәрендә вафат була. Кабере Яңа татар бистәсе зиратында урнашкан.

ГАКЫЙДӘ

ИСЛАМ ДИНЕ

Ислам – Аллаһы Тәгаләнең хак дине буенча гамәл кылу дигәнне аңлата[1]. Ул – Аллаһы Тәгалә тарафыннан Мөхәммәд ﷺ гә кешеләрне яхшылыкка өндәр өчен иңдерелгән дин. Аның хөкемнәре буенча гамәл кылган кеше дөньяда да, ахирәттә дә даими рәхәтлектә һәм иминлектә булыр. Ислам диненең хаклыгына ышанган кеше мөэмин-мөселман була. Динебез – Ислам дине. Без, Әлхәмдүлилләһ – һәркайсыбыз мөэмин-мөселман.

[1] Ислам сүзе гарәп теленнән буйсыну, тапшырылу, бирелү рәвешендә тәрҗемә ителә

ГАМӘЛ

Ислам дине буенча кешеләрнең гамәлләре сигез төргә бүленә: фарыз, вәҗиб, сөннәт, мөстәхәб, мөбәх, хәрам, мәкрүһ һәм мөстәкрәһ.

Фарыз гамәлне кылган кеше саваплы, кылмаганы гөнаһлы, ә аның фарызлыгына (тиешле булганына) ышанмаган кеше кяфер (имансыз) була. Фарыз гамәлләр: Ислам диненең хаклыгына ышану, көн саен биш вакыт намаз уку, Рамазан аенда ураза тоту, ел саен малның зәкятен бирү, мөмкинлеге булган кешегә, гомерендә бер мәртәбә Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып хаҗ кылу һ. б.

Вәҗиб гамәлне кылган кеше саваплы, кылмаганы гөнаһлы, ә аның вәҗиблегенә (тиешле булганына) ышанмаган кеше зур гөнаһлы була. Вәҗиб гамәлләр: витр һәм гает (ураза һәм корбан бәйрәме) намазларын уку, фитыр сәдакасын бирү, корбан чалу, Коръәндәге һәрбер сәҗдә аятьләрен укуга яисә ишетүгә сәҗдәи тиләвәт кылу һ. б.

Сөннәт гамәлне кылган кеше саваплы була, әмма кылмаганы гөнаһлы булмаса да, Мөхәммәд ﷺ нең шәфәгатенә (яклавына) ирешми. Сөннәт гамәлләр: яхшы эшләрне «Бисмилләәһ» сүзе белән башлау, Коръән укыр алдыннан «Әгүүзе», ә төчкергәч «Әлхәмдүлилләһ» дип әйтү, иманлы кешеләргә сәлам бирү һ. б.

Мөстәхәб гамәлне кылган кеше саваплы була, ә кылмаганы гөнаһлы булмый һәм Кыямәт көнендә дә моның өчен шелтә алмый. Мөстәхәб гамәлләр: нәфел (өстәмә)

намазлар уку, нәфел уразалар тоту, нәфел сәдакалар бирү, буш вакытта Коръән уку һ.б.

Мөбах гамәлне кылган яки кылмаган кеше – саваплы да, гөнаһлы да булмый. Мөбах гамәлләр: хәләл ризыкларны туйганчы ашау яки эчү, утыру, басып тору, зарарсыз сүзләр сөйләү һ. б.

Хәрам гамәлне кылучы зур гөнаһлы, ә мондый гамәлләрне эшләргә ярый (хәләл) дигән кеше кяфер була. Хәрам гамәлләр: кешене яисә хайванны җәберләү, гайбәт сөйләү, урлау, исерткеч эчемлекләр эчү, зина кылу һ. б.

Мәкруһ гамәлне кылган яки дөрес дигән кеше гөнаһлы була. Мәкруһ гамәлләр: отыш уеннар уйнау, ямьсез җырлар җырлау, кеше алдында әдәпсез кылану һ. б.

Мөстәкрәһ гамәлне кылган кеше гөнаһлы булмаса да, әдәпсезлек кылган була. Мөстәкрәһ гамәлләр: базарда яисә урамда ашау, авызны капламыйча иснәү, кычкырып кикерү һ. б.

БАЛИГЪЛЫК ҺӘМ АКЫЛ

Фарыз, вәҗиб, сөннәт, мөстәхәб гамәлләрне кылу, хәрам, мәкруһ, мөстәкрәһ гамәлләрдән тыелу – балигъ һәм акылы булган кешегә тиешле эшләр. Балигъ булган дип, сабыйлыктан чыгып җитлеккән кешегә әйтелә. Сабый балалар, акылга зәгыйфь (тиле) кешеләр фарыз һәм вәҗиб гамәлләрне кылмасалар да гөнаһлы булмыйлар.

Ир балалар 12 яшьтән, үсеп җитүләре беленгәч балигъ, ә кыз бала 9 яшьтән, өлгереп җитүе беленсә, балига булып санала. 15 яшьләре тулгач, җитлегүләре мәгълүм булмаса да, ир балалар да, кыз балалар да, балигъ булып саналалар. Балигъ саналган һәм акылы булган кешеләр Шәригать кушканнарны үтәп, кушмаган эшләрдән тыелып яшәргә тиешләр.

ГЫЙБАДӘТ

Аллаһы Тәгалә Үз бәндәләрен хөрмәтләп, аларга бик күп нигъмәтләр бирде: бу дөньяга килүебез, һәрбер әгъзаларыбыз, ашаган ризыкларыбыз, эчкән суларыбыз, сулаган һаваларыбыз, сәламәт килеш гомер итүебез – һәркайсы Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән бүләге.

Җаныбыз, тәнебез һәм малыбыз белән Аллаһы Тәгаләгә никадәр гыйбадәт кылсак та, Аның нигъмәтләре өчен тулысынча шөкрана кылып бетерә алмыйбыз, шулай булса да балигъ һәм акыллы һәрбер мөэмин кеше фарыз һәм вәҗиб булган гамәлләрнең һәркайсын үтәп, хәрам һәм мәкруһ булган гамәлләрнең барысыннан да тыелып, кулдан килгәнчә Аллаһы Тәгаләгә даими гыйбадәт кылырга тиеш. Мөэмин-мөселман кешеләргә фарыз булган гыйбадәтләрнең олуглары биш: иман, намаз, ураза, зәкят һәм хаҗ. Иман – Ислам диненең хаклыгына һәм анда булган хөкемнәргә ышану. Намаз – көн саен биш вакыт (билгеле рәвештә) гыйбадәт кылу. Ураза – Рамазан аенда көндез ашау-эчүдән тыелып тору. Зәкят – ел саен бер

мәртәбә байлыктан фәкыйрьләргә өлеш чыгару. Хаҗ – мөмкинлеге булган кешегә Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып хаҗ гамәлен кылу.

ИМАН ҺӘМ ИКЪРАР

Ислам динендә һәрбер балигъ һәм акылы булган кешегә фарыз саналган олуг гыйбадәтләрнең беренчесе ул – иман. Иман – чын күңелдән ышану, ә икърар – ышанганыңны тел белән әйтү. Мөэмин-мөселманга Ислам диненең хаклыгына, анда булган һәрбер хөкемгә ышанып иман китерү һәм ышануын тел белән әйтеп икърар кылу фарыз.

Иманны гарәпчә икърар кылу өчен түбәндәге мәшһүр иман кәлимәләре кулланыла:

Кәлимәи шаһәдәт

أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

Әшһәдү әл-ләә иләһә илләл-лааһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһү үә расүүлүһ

Мәгънәсе: Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк. Шулай ук гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Мөхәммәд ﷺ Аллаһы Тәгаләнең колы һәм бәндәләргә дин өйрәтер өчен җибәрелгән илчесе.

Кәлимәи иман

أَمَنْتُ بِاللهِ وَمَلاَئِكَتِهِ وَكُتُبِهِ وَرُسُلِهِ وَالْيَوْمِ الْأَخِرِ وَالْقَدَرِ خَيْرِهِ وَشَرِّهِ مِنَ اللهِ تَعَالَى وَالْبَعْثِ بَعْدَ الْمَوْتِ

Әмәнтү билләәһи үә мәләә'икәтиһи[1] үә күтүбиһи үә рүсүлиһи үәл-йәүмил-әәхыри үәл-кадәри хайриһи үә шәрриһи минәл-лааһи тәгәәләә үәл-бәгҫи[2] бәгдәл-мәүт

Мәгънәсе: Ышандым мин Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, ахирәт көненә, тәкъдирнең (язмышның) яхшысы да, яманы да Аллаһы Тәгаләдән булуына һәм үлгәннән соң янә терелүгә.

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ

Аллаһы Тәгаләне белү һәрбер бәндәгә фарыз, ләкин Аның затын белергә акылыбызның куәте җитми. Аны мәшһүр сыйфатлары аркылы гына таный алабыз. Аллаһы Тәгаләнең күркәм сыйфатлары гаять күп:

Аллаһы Тәгалә Мәүҗүд, Әхәд, Хәййү, Галим, Сәмигъ, Бәсыйр, Мөтәкәллим, Кадир, Мохтар, Халикъ, Рәззак, Рабби, Гадел, Гафур, Мөҗиб.

---

[1] ' – әлеге тамга һәмзәне аңлата

[2] ҫ - әлеге хәреф сакау булып укыла. Гарәпчә ث – сә хәрефе

Мәүҗүд – бар дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә бар, барлыгы һичбер затка мохтаҗ түгел. Ул Үзеннән Үзе бар. Барлыгының әүвәле дә, ахыры да юк, ягъни Ул дөньядагы мәхлуклар (кешеләр, хайваннар һ.б.) кебек башта юк булып, соңыннан бар булмаган. Аллаһы Тәгалә һәрвакыт булган һәм мәңге булачак.

Әхәд – бер дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә бер генә, Аның бернинди тиңдәше юк.

Хәййү – тере дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә тере, ләкин Аның тереклеге безнең кебек тән һәм җан сыман түгел.

Галим – белүче дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне белә: булган һәм булачак һәрнәрсә дә Аллаһы Тәгаләгә мәгълүм. Аңа билгесез әйбер юк. Аның белүе безнең кебек өйрәнү, уйлану рәвешендә түгел.

Сәмигъ – ишетүче дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә һәрбер тавышны ишетә. Аның ишетүе безнең кебек колак белән түгел.

Бәсыйр – күрүче дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне күрә. Аның күрүе безнең кебек күз белән түгел.

Мөтәкәллим – сөйләүче дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә сөйләүче: Коръәни-Кәримдә язылган барлык сүзләр – Аллаһының сүзләре. Аның сөйләве безнең кебек авыз, тел, тавыш белән түгел.

Кадир – көчле дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгаләнең көче һәрнәрсәгә җитә. Ул ни теләсә, шуны булдыра. Аның көче безнең кебек әгъзалар һәм кораллар белән түгел.

Халикъ – барлыкка китерүче дигәнне аңлата. Галәмдәге һәрбер нәрсәне барлыкка китерүче – Аллаһы Тәгалә.

Мохтар – ихтыярлы дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә һәрбер эшне Үз ихтыяры (теләге) белән башкара.

Рәззак – ризыкландыручы дигәнне аңлата. Җир йөзендәге һәр кешегә, барлык хайваннарга ризык бирүче – Аллаһы Тәгалә. Һәрбер җан иясе Ул биргән ризык һәм нигъмәтләр белән тукланып яши.

Рабби – тәрбия кылучы һәм хуҗа булучы дигәнне аңлата. Барча галәмгә Үз рәхмәтен бирүче, тәрбия кылучы һәм бөтен галәмнең хуҗасы – Аллаһы Тәгалә.

Гадел – тугры дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә һәрбер эшен һәм һәр хөкемен тугрылык, гаделлек белән башкара, һичбер кешегә җәбер-золым итми. Ул ахирәттә изге кешеләрне җәннәт белән бүләкли, ә имансыз һәм гөнаһлы кешеләрне җәһәннәм белән газаплый. Болар һәрберсе хаклык һәм тугрылык белән башкарыла.

Гафур – гафу итүче дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә һәрберебезнең гөнаһларын гафу итүче. Тәүбә кылган (гафу сорап үкенгән) һәм тәүбә итмәгән кешеләрнең дә гөнаһларын гафу итү Аллаһы Тәгаләнең Үз ихтыярында.

Мөҗиб – догаларны кабул итүче дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә ихлас күңелдән кылган доганы кабул итә һәм Үзенең рәхмәте белән сораганнарыбызны бирә.

Аллаһы Тәгалә һәрбер гаеп һәм кимчелекләрдән пакь. Аның затында да, сыйфатында да һәм кылган эшләрендә дә һичбер кимчелек юк.

Аллаһы Тәгалә бернинди мәхлукатка охшамаган. Аны һичбер нәрсәгә охшатып булмый. Ул гәүдәле зат түгел. Аның бер рәвеше һәм сурәте юк. Ул һичбер урында һәм һичбер тарафта (өстә, аста, уңда, сулда, алда, артта) түгел, шулай булса да, Ул бар[1]. Аның кайбер сыйфатлары безгә билгесез. Аллаһы Тәгаләгә ашау, эчү, ару, йоклау хас түгел. Аллаһы Тәгалә һичбер заттан тумаган һәм беркемне дә тудырмады.

ФӘРЕШТӘЛӘР

Аллаһы Тәгаләнең фәрештәләре бар. Алар барысы да Аллаһының итәгатьле коллары. Фәрештәләр һәрвакыт Аңа гыйбадәт кылалар һәм хезмәт итәләр, һичнинди гөнаһ эшләмиләр. Аларда безнең кебек ашау, эчү, йоклау кебек эшләр, ирлек һәм хатынлык юк. Һәрберсе

[1] Аллаһы Тәгаләне бу галәм эчендә дип күзалларга ярамый. Мәшһүр галим Сиражеддин Габделхәсән Гали ибне Госман әл-Ошиның «Әмәли» китабында болай диелгән: «Гарешнең Раббысы гареш өстендәдер, ләкин гарештә урнашу сыйфатыннан башка һәм шулай ук гарешкә тоташу рәвешеннән башка»

нурдан яралтылган. Гадәттә, кеше күзенә күренмиләр. Күренергә теләсәләр, төрле кыяфәтләргә керергә мөмкиннәр. Җәбраил, Микаил, Газраил һәм Исрафил исемлеләре – мәшһүр фәрештәләр.

ПӘЙГАМБӘРЛӘР

Аллаһы Тәгалә кешеләргә дин хөкемнәрен өйрәтер өчен бик күп пәйгамбәрләр җибәргән. Барлык пәйгамбәрләр дә кеше затыннан. Алар яшь чакларында ук бик акыллы, зирәк, тугры һәм күркәм холыклы булганнар. Билгеле бер вакытка ирешкәннән соң, Аллаһы Тәгалә аларны пәйгамбәр иткән, ягъни Җәбраил исемле фәрештә аркылы аларга Үз хөкемнәрен җибәреп, шулар буенча кешеләрне Хак дингә һәм изге гамәлләргә өндәргә боерган.

Хәзрәти Адәм عليه السلام заманыннан бирле дөньяга бик күп пәйгамбәрләр килеп киткән, аларның төгәл саны безгә билгеле түгел. Коръәни Кәримдә 25 пәйгамбәрнең исемнәре искә алына: Адәм, Идрис, Нух, Һуд, Салих, Лут, Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Йосыф, Әюб, Шөгаиб, Муса, Һарун, Давыт, Сөләйман, Юныс, Ильяс, Әльясәгъ, Зөлкифел, Зәкәрия, Яхъя, Гайсә عليه السلام һәм Мөхәммәд ﷺ. Шулай ук Коръәндә Гозәер, Локман, Зөлкарнәйн дигән исемнәр дә искә алына, ләкин аларның пәйгамбәр булулары ачык билгеле түгел. Шис, Юшагъ, Хозер, Бишер, Даниял, Ышмуил, Ашгия, Әрмия عليه السلام исемле пәйгамбәрләр турында хәдисләрдә сөйләнә.

Иң беренче пәйгамбәр – Адәм عليه السلام, иң соңгысы – Мөхәммәд ﷺ. Мөхәммәд ﷺ – ахырзаман пәйгамбәре, аннан соң дөньяга һичнинди пәйгамбәр килмәячәк. Аның дине, ягъни Ислам дине Кыямәт көненә кадәр һич үзгәрмәячәк. Мөхәммәд ﷺ – безнең пәйгамбәребез, без һәркайсыбыз аның өммәтеннән.

КИТАПЛАР

Аллаһы Тәгалә, дин һәм шәригать хөкемнәрен аңлатып, пәйгамбәрләренә 104 китап иңдергән. Алар шул китаплардагы хөкемнәр белән үз кавемнәрен (халыкны) иманга һәм изге гамәлләр кылырга өндәгәннәр. Адәм عليه السلام гә – 10, Шис عليه السلام гә – 50, Идрис عليه السلام гә – 30, Ибраһим عليه السلام гә – 10 кәгазь (күрсәтмә язма) иңдерелгән. Шулай ук Муса عليه السلام гә Тәүрат, Давыт عليه السلام гә Зәбур, Гайсә عليه السلام гә Инҗил һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә Коръән иңдерелгән. Иң соңгы иңдерелгән китап – Коръәни Кәрим. Анда алдарак җибәрелгән китапларның кайбер кануннары гамәлдән чыгарылган. Коръәндә кешеләргә бу дөнья һәм ахирәт өчен кирәкле барча хөкемнәр дә бар.

ТӘКЪДИР

Тәкъдир – булачак нәрсәне алдан ук билгеләү дигәнне аңлата. Дөньяда булачак һәм башкарылачак һәрнәрсә Аллаһы Тәгаләгә алдан ук билгеле. Ул һәрнәрсәне һәм

һәрбер эшне алдан ук тәкъдир кылган. Дөньяда барлык (булган, була торган, булачак) эшләр Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире буенча башкарыла. Кешеләр гамәлләрне үз ихтыярлары белән сайласалар да, аларга көч-куәтне Аллаһы Тәгалә бирә.

АХЫРЗАМАН ҺӘМ КЫЯМӘТ

Бу дөньядагы һәрнәрсә (кешеләр, хайваннар һ. б.) фани, ягъни мәңгелек түгел. Бер заман дөньяда булган барлык мәхлукат та юкка чыгачак. Ул ахырзаман дип атала. Аның кайчан булачагы Аллаһы Тәгаләдән башка һичкемгә билгеле түгел.

Бу дөньядагы бөтен мәхлукатлар һәлак булып беткәннән соң, Аллаһы Тәгалә барлык кешеләрне яңадан терелтер. Черлеп беткән һәм таралган әгъзалар яңадан җыелып, тере вакытындагы хәленә кайтырлар. Кабер өсләре ярылып ачылганнан соң, һәр кешенең җаны үз гәүдәсенә кереп урнашыр. Шуннан соң, һәр кеше йокыдан уянган кебек, үз кабереннән чыгып, Мәхшәр мәйданына җыелыр. Мәхшәрдә Аллаһы Тәгаләнең фәрештәләре кешеләрнең дөньядагы башкарган эшләрен гаделлек мизанында (үлчәвендә) хисап кылып, гамәлләренә карап әҗер яки җәзаларны төгәл билгеләрләр. Һәрбер имансыз кеше җәһәннәм чокырына төшер. Гөнаһсыз, иманлы кешеләр һәм гөнаһлары гафу ителгәннәр җәннәткә керер. Гафу ителмәгән мөэминнәр җәһәннәмгә төшеп, гөнаһлары өчен газапланырлар. Гөнаһлардан арынгач, җәһәннәмнән

чыгып, алар да җәннәткә керерләр. Имансыз кешеләр – җәһәннәмдә, ә иманлы кешеләр җәннәттә мәңгегә калырлар. Җәннәттәгеләр дә һәм җәһәннәмдә калган кешеләр дә һичкайчан үлмәсләр, мәңге тере булырлар.

ҖӘННӘТ ҺӘМ ҖӘҺӘННӘМ

Җәннәт – оҗмах йорты, ул зиннәтле сарайлар һәм җимеш бакчалары белән тулы. Анда татлы сулы елгалар һәм баллы чишмәләр ага. Җәннәттәге хөрмәтне һәм нигъмәтләрне сөйләп бетерү һич мөмкин түгел. Анда керүчеләрне гомердә күрмәгән һәм ишетмәгән ләззәтле нигъмәтләр көтә.

Җәннәт – мәңгелек йорт. Анда кергән кешеләр беркайчан үлмәс, алар кайгы-хәсрәт, авыру, сызлау, уңайсызлык, күңелсезлек кебек хәлләрдән азат булырлар һәм кайчан да булса Аллаһы Тәгаләнең нурын күрерләр.

Җәһәннәм – тәмуг йорты. Анда кергән кешеләр ут һәм башка газаплар белән җәзаланырлар. Зур гөнаһлар кылмаучыларга җиңелчәрәк газап булыр, ә кешеләргә һәм хайваннарга җәбер-золым иткән зур гөнаһлылар олы җәзалар белән газапланырлар.

МӨХӘММӘД ﷺ

Безнең пәйгамбәребез – Мөхәммәд ﷺ. Аллаһы Тәгалә Ислам дине хөкемнәрен Җәбраил фәрештә аркылы аңа иңдерә һәм Мөхәммәд ﷺ ул хөкемнәрне үзенең сәхабәләренә, ягъни иң әүвәлге шәкертләренә өйрәтә. Ислам дине хөкемнәре һич үзгәрмичә безнең заманга килеп ирешә һәм һич үзгәрмичә кыямәт көненә кадәр калачак.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ Гарәбстан ярымутравындагы Мәккә шәһәрендә туган. Атасының исеме – Габдулла, гарәп халкының Корәеш кабиләсеннән. Бабасының исеме Габделмоталлиб, ә аның атасы – Һашим. Анасының исеме – Әминә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ туганчы ук аның атасы сәфәрдә вафат була. 6 яшенә җиткәндә анасы Әминә дә дөньядан китә һәм Мөхәммәд ﷺ бөтенләй ятим кала. Шуннан соң аны бабасы Габделмоталлиб тәрбиягә ала. Бабасы вафат булгач, атасының абыйсы Әбу Талиб тәрбиясендә була. 25 яшендә Хәдичә исемле бер бай хатынга өйләнә.

Кырык яшендә аңа Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештә аркылы пәйгамбәрлек иңдерә, ягъни кешеләрне ислам диненә чакырырга боера. Мөхәммәд ﷺ Мәккә халкын мөселман булырга өнди башлагач, берничә йөз кеше иман китереп, Ислам динен кабул итәләр. Калганнары дошман булып, Мөхәммәд ﷺ гә төрле җәбер-золым кылырга тырышалар. Хәтта берничә тапкыр үтермәкче дә булалар. Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд ﷺ не дошманнарының яман-

лыгыннан саклый. Мәккә кяферләре аңа артык зарар һәм зыян кыла алмыйлар.

Мәккәдә 13 ел пәйгамбәр булганнан соң, Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте буенча, ул Мәдинә шәһәренә күчә. Ул вакытта Мәдинә халкы Ислам динен бик ярата һәм шәһәрнең берничә хөрмәтле кешесе дә мөселман була. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ Мәдинәгә күчкәннән соң, Ислам дине куәтләнә (көчәя). Мәдинәгә якын шәһәр һәм авыл кешеләренең күбесе Ислам динен кабул итә.

Мәккә халкы башта мөселманнарга дошман була, хәтта аларны юк итү максатыннан берничә мәртәбә Мәдинә шәһәренә зур гаскәр белән сугышка киләләр. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән һәр сугышта мөселманнар җиңеп, дошманнардан өстен чыга. Соңыннан, Мәдинә шәһәренә күчкәннән соң 8 нче елда, Мөхәммәд ﷺ унике меңлек мөселман гаскәре белән Мәккә тарафына юнәлә. Мәккә халкы аларга каршы тора алмауын белә һәм каршылык күрсәтмичә һәрберсе өйләренә кача. Рамазан аеның 20 нче көнендә мөселманнар җиңү белән Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә керәләр. Ахырда бөтен Мәккә халкы үз ихтыяры белән Ислам динен кабул итә. Шуннан бирле Мәккәи Мөкәррәмә шәһәре мөселманнар кул астында. Ул – хаҗ гамәлләре кыла торган изге һәм мөбарәк шәһәр. Кыйблабыз – мөбарәк Кәгъбә йорты да шул шәһәрдә. Мәдинәгә күчкәннең 10 нчы елында Мөхәммәд ﷺ туксан мең мөселман белән Мәккә шәһәренә барып хаҗ кыла. Шуннан соң пәйгамбәребезгә Мәккәи Мөкәррәмәне күрү насыйп булмый...

Мәдинә шәһәрендә ун ел торганнан соң, 63 яшендә пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ вафат була. Кабере Мәдинәи Мөнәвәрә шәһәренең уртасындагы Раузаи Мөтаһһәрә мәчете эчендә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ бик камил, олуг кеше була. Ул туган кичтә дә дөньяда берничә төрле могҗиза күзәтелә һәм аның бала чагында да төрле гаҗәеп хәлләр күренә.

Мөхәммәд ﷺ пәйгамбәрлек иңгәнче кырык ел Мәккә шәһәрендә гади кеше кебек яши, ләкин һәрвакыт бик изге, күркәм холыклы, һәркем каршында әхлаклы һәм ышанычлы була. Яшь чагыннан ук кяферләрнең бозык эшләрен күреп үсә, аларның потларына беркайчан да табынмый һәм бервакытта да начар, кимчелекле гамәлләр кылмый. Пәйгамбәрлек иңгәч Аллаһы Тәгалә аның аша могҗизаларны, ягъни гадәти булмаган гаҗәеп хәлләрне бик күп күрсәтә, шул сәбәпле аның хак пәйгамбәр булуына һичкемдә шик-шөбһә калмый. Тарихел-әнбия (пәйгамбәрләр тарихы) китапларында аның күп кенә могҗизалары бәян ителә.

СӘХАБӘЛӘР

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ не сәламәт вакытында күргән мөселманнарны сәхабәләр дип атыйлар. Алар – 114 мең чамасы һәм һәрберсе бик яхшы, изге кешеләр. Пәйгамбәребез ﷺ нең мәҗлесендә булып, безгә кадәр

мөселманлыкны кабул итеп һәм Ислам диненең безнең көннәргә кадәр килеп ирешүенә сәбәпче булулары аркасында, сәхабәләрнең һәркайсы – безгә дус һәм якын. Иң олуг сәхабәләр – Мөхәммәд ﷺ нең якын дуслары – Әбу Бәкер, Гомәр, Госман, Гали رضي الله عنهم исемле кешеләр. Бу сәхабәләр пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә һәрвакыт ярдәм иткәннәр, Ислам диненең таралуына сәбәпче булганнар. Мөхәммәд ﷺ , Хәдичә исемле хатыны вафатыннан соң, хәзрәти Әбу Бәкернең кызы Гәйшәгә өйләнә. Шулай ук пәйгамбәребез ﷺ нең Хәфса исемле хатыны – хәзрәти Гомәрнең кызы. Хәзрәти Госман Пәйгамбәребез ﷺ нең Рокыя һәм Өммегөлсем исемле кызларына, ә хәзрәти Гали – Фатыйма исемле кызына өйләнә. Фатыйма белән Галинең Хәсән һәм Хөсәен исемле ике улы туа. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ сәламәт вакытында аларны үз баласы кебек якын итә.

Шушы урында мөхтәрәм Әхмәдһади Максуди хезмәтенең беренче – «Гакыйдә» бүлеге тәмамлана.

ТӘҺАРӘТ

Хәдис-шәриф

إِنَّ الْإِسْلَامَ نَظِيفٌ فَتَنَظَّفُوا فَإِنَّهُ لَا يَدْخُلُ الْجَنَّةَ إِلَّا نَظِيفٌ

Иннәл-исләәмә нәҙыйфүн[1] фәтәнәҙҙафуу, фәиннәһү ләә йәдхулүл-җәннәтә иллә нәҙыйф

Мәгънәсе: Ислам – пакь дин, шуңа күрә пакь булырга тырышыгыз. Пакь булмаган кеше җәннәткә кермәс.

Хәдис-шәриф

بُنِيَ الدِّينَ عَلَى النَّظَافَةِ

Бүнийәд-диинә гәлән-нәҙаафәһ

Мәгънәсе: Ислам пакьлек өстендә төзелгән.

Ислам дине – хак һәм бик пакь дин. Аллаһы Тәгалә бәндәләренә һәрчак пакь булырга боера. Мөселман булган кешенең күңеле яман сыйфатлардан һәм явыз фикерләрдән; тәне, киеме, йорты, ашаган ризыклары, эчкән сулары һәрбер нәҗестән[2] пакь булырга тиеш. Намаз укыганда һәм башка гыйбадәтләрне кылганда мөселманга бигрәк тә пакь булу зарур.

[1] Әлеге хәреф сакау булып укыла. Гарәпчә ظ –зат, ذ – зәл хәрефләре

[2] Нәҗес сүзе – арусыз, пычрак дигәнне аңлата

ТӘҺАРӘТ

Намаз укыр алдыннан кешегә тәнен, киемен һәм намаз укыласы урынын һәртөрле нәҗесләрдән пакьләү һәм Шәригать боерганча тиешле әгъзаларны су белән юып, тәһарәт алу фарыз.

Тәһарәт алганда 8 төрле эш түбәндәге тәртиптә башкарыла. Тәһарәт алучы:

1) башта пакь су белән истинҗа кыла, ягъни гаурәтләрен нәҗестән пакьли;

2) аннан соң беләзекләренә кадәр ике кулын юа;

3) аннан соң өч мәртәбә авызын чайкый;

4) аннан соң өч мәртәбә борынын юа;

5) аннан соң өч мәртәбә йөзен юа (бу вакытта маңгай чәченнән алып, ике колагына һәм ияк астына кадәр булган һәр җиренә, шулай ук кашына һәм сакалына да су тидерә);

6) аннан соң өч мәртәбә терсәкләренә кадәр ике кулын юа;

7) аннан соң, учларын һәм бармакларын суга чылатып, ике кулы белән әүвәл башына, аннары колакларына, аннары муенына бер мәртәбә мәсех[1] кыла;

8) аннан соң тубыкларына кадәр өч мәртәбә ике аягын юа.

---

[1] Мәсех кылу – ышку дигәнне аңлата.

Кулларын һәм аякларын юганда бармак араларына һәм йөзек астына су тими калмаска тиеш. Әгәр аякларында читек булса, алар өстенә өч бармагы белән мәсех кыла.

ТӘҺАРӘТНЕҢ ФАРЫЗ, СӨННӘТ ҺӘМ МӨСТӘХӘБЛӘРЕ

Тәһарәтнең фарызлары дүрт:

1) бер мәртәбә йөзне юу;

2) бер мәртәбә терсәкләргә кадәр ике кулны юу;

3) бер мәртәбә башның чирегенә мәсех кылу;

4) бер мәртәбә тубыкларга кадәр ике аякны юу.

Тәһарәтнең мәшһүр сөннәтләре унбиш:

1) тәһарәтне «бисмилләәһ» сүзләре белән башлау;

2) күңел белән ният кылу;

3) ике кулны беләзекләргә кадәр юу;

4) мисвәк (теш чистарткыч) кебек нәрсә белән тешләрне пакьләү;

5) өч мәртәбә авызны юу;

6) өч мәртәбә борынны юу;

7) сакалны аралаштыру;

8) бармакларны аралаштыру;

9) йөз, кул һәм аякларны өчәр мәртәбә юу;

10) уң кул һәм уң аякны сулларыннан әүвәл юу;

11) башның һәр җиренә мәсех кылу;

12) ике колакка мәсех кылу;

13) кул аркалары белән муенга мәсех кылу;

14) тәһарәтне билгеле тәртип белән алу;

15) тәһарәтне бүленмичә алып бетерү;

Тәһарәтнең мөстәхәбләре биш:

1) тәһарәт алганда кыйблага каршы тору;

2) су чәчрәмәслек биек җирдә тору;

3) суны үзеңә әзерләү;

4) тәһарәт алып бетергәнчегә кадәр тыйнаклык саклау (сөйләшмәү).

5) тәһарәт тәмам булганчы түбәнчелекле кыяфәттә тору.

ТӘҺАРӘТНЕҢ МӘКРУҺ ҺӘМ МӨФСИДЛӘРЕ

(ТӘҺАРӘТ АЛГАНДА ШЕЛТӘЛӘНӘ ТОРГАН ҺӘМ ТӘҺАРӘТНЕ БОЗУЧЫ НӘРСӘЛӘР)

Тәһарәт алганда түбәндә китерелгән сигез төрле эш мәкруһ (шелтәләнгән) булып санала:

1) суны күп исраф итү;

2) уң кул белән борын сеңгерү;

3) әгъзаларны өчтән артык яки ким юу;

4) башка ике мәртәбә мәсех кылу;

5) йөзгә суны каты итеп сибү;

6) суны кешедән салдырту;

7) тәһарәт алганда дөнья сүзләрен сөйләү;

8) тәһарәт алганда суга йә төкермәк, йә сеңгермәк.

Тәһарәтнең мөфсидләре (бозучы нәрсәләре) тугыз, ягъни түбәндәге эшләр тәһарәтне боза:

1) арт юлдан һава (газ) чыгу;

2) гаурәттән (ал һәм арт юлдан) нәҗес (олы яки кече хаҗәт) яки башка нәрсә килү;

3) җәрәхәттән кан, эрен яки сары су агу;

4) борын яки теш канау канау;

5) күздән авыру сәбәпле лайлалы яшь агу;

6) авыз тутырып азык яки әз генә кан косу;

7) ятып яки сөялеп йокыга китү;

8) тилереп яки исереп аңны югалту;

9) намаз эчендә кычкырып көлү.

Җәрәхәтләнгән җирдән кан, эрен яки сары су әз генә чыкса һәм читкә акмаса тәһарәт бозылмый. Тирләү, күздән лайласыз яшь агу, авыздын какрык килү тәһарәтне бозмый. Тәһарәтсез килеш Коръәни Кәримне яисә аятьләр язылган кәгазьләрне тоту тыела, әмма букча (сумка) аркылы тотарга рөхсәт ителә. Тәһарәтсез килеш Коръән сүрәләрен (күңелдән) укырга ярый, мәчеткә керү һәм зиратка бару хупланмый. Бу эшләрне тәһарәт алып яки тәяммүм белән башкару мөстәхәб (хуплана).

ЧИТЕКЛӘРГӘ МӘСЕХ КЫЛУ

Тәһарәтле вакытта аякларына читекләр кигән кеше икенче тапкыр тәһарәт алганда аякларын юып тормыйча читекләр өстенә мәсех кенә кыла, ягъни кул бармакларын суга чылатып, ике кулның өч урта бармаклары белән читекләрнең өстеннән тубыкка кадәр сыпыра. Шул рәвешчә читекләргә мәсех кылына. Мәсехнең мөддәте (чиге, вакыты) мокыйм[1] кешегә – бер тәүлек,

[1] Мокыйм – өйдә торучы кеше.

ягъни 24 сәгать, мосафир[1] кешегә – өч тәүлек, ягъни 72 сәгать. Мөддәтнең башы читекләрне кигәннән соң, алынган тәһарәтнең бозылган вакытыннан хисаплана. Күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң, читекләргә мәсех кылу дөрес булмый (кабат аякларны юып, тәһарәт алырга кирәк). Күн оек (тубыкка кадәр җиткән күн оек, кыска читек) һәм тубыкны каплый торган аяк киеме (ботинки, сапожки) – һәрберсе читек хөкемендә (читеккә тиешле кагыйдәләр алда санап кителгән аяк киемнәренә дә кагыла). Нәҗестән пакь булып тәһарәтле вакытта киелгәндә, аларга да мәсех кылу дөрес була, әмма кәвешкә[2], тубыкны капламаган башмакларга, суны тиз үткәрә торган юка оекларга һәм тубыктан түбән җирендә өч бармак сыйдырышлы тишек булган читекләргә мәсех кылу ярамый. Әгәр читекнең ике-өч җирендә кечкенә ертыклар булса, барысын кушып, аларның гомуми зурлыгы хисаплана, ләкин ике читектәге ертыклар бергә хисапланмый. Әгәр читекләр үкчәгә кадәр килсә (салынса) яки читекләрнең тәһарәт вакыты чыкса – мәсех бозыла (әгәр читекләрнең мөддәте тәһарәтле вакытта бетсә, бу очракта аякларны гына юу да җитә, тулысынча тәһарәт алу фарыз түгел).

БӘЙЛӘВЕЧ (ПОВЯЗКА)

Тәһарәт яки госел алганда юылачак әгъзаның бер җирендә җәрәхәт булып, аны юу зарарлы булса, ул юылмый,

---

1 Мосафир – өч көнлек юлга чыккан кеше.

2 Кәвеш – тубыкка кадәр җитми торган милли аяк киеме – *Тәрҗемәченең аңлатмасы.*

ә юеш кул белән аның өстенә мәсех кылына. Әгәр мәсех кылу да зыян китерсә, шул җәрәхәтне каплаган бәйләвеч яки кәгазь өстенә мәсех кылына. Бәйләвечне куптару да җәрәхәткә зарар китерсә, аның астында калган сәламәт җиргә дә мәсех кылу җитә. Бәйләвечкә мәсех кылу өчен аның тәһарәтле вакытта ябылуы шарт түгел. Тәһарәтсез вакытта ябылган булса да, мәсех кылу дөрес була. Бәйләвеч ниндидер сәбәп аркасында төшеп китсә яки куптарылса да мәсех бозылмый, әмма астындагы җәрәхәте төзәлгәннән соң аңа мәсех кылырга ярамый.

ГОСЕЛ

Госел – бөтен тәнне юып су белән коенуны дигәнне аңлата. Госел алачак кеше түбәндәге эшләрне башкара:

1) әүвәл истинҗа кылып гаурәтләрен пакьли;

2) аннан соң беләзекләренә кадәр ике кулын юа;

3) аннан соң тәһарәт ала, ләкин аякларын юмый;

4) аннан соң әүвәл башына, соңыннан тәненең һәрбер җиренә бер кат су коя;

5) аннан соң мөмкин кадәр тәненең һәр җирен куллары белән ышкып чыга;

6) аннан соң янә икенче кат тәненең һәр җиренә су коя;

7) аннан соң янә тәненең һәр җиренә су йөгертә;

8) аннан соң аякларын юа.

Госел шулай алына. Госелле кеше камил тәһарәтле булып санала. Намаз уку өчен госел өстенә тәһарәт алу кирәкми.

ГОСЕЛНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ

Госелнең фарызлары өчәү:

1) авыз эчен су белән чайкау;

2) борын эчен юу;

3) тәннең һәр җиренә су тидерү.

Госелдә тәннең һәр җиренә: чәч, каш, сакал-мыекка, күз чокырларына, җыерылып торган җирләргә, йөзек астына, кендеккә су тидерергә кирәк. Ирләргә чәчнең һәр бөртегенә су тидерү фарыз, шул сәбәпле аларга чәчләрен кистерү яки кыскарту (Ислам әһеле – мөселманнар арасында) сөннәт булып санала. Хатын-кызларга чәчләренең төбенә су тидерү җитә. Толымларына су тимәсә дә ярый, чөнки хатын-кыз өчен чәч – бер зиннәт. Аларга чәчләрен кистерү яки кыскарту дөрес түгел.

ГОСЕЛНЕҢ СӨННӘТЛӘРЕ

Госелнең сөннәтләре унбер:

1) бисмилләәһир-рахмәнир-рахиим (Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһының исеме белән) дип әйтү;

2) җенес әгъзаларын юу;

3) тәннең нәҗесле җирләрен юу;

4) беләзекләргә кадәр кулларны юу;

5) госелгә кадәр тәһарәт алу;

6) әүвәл башны, аннары башка җирләрне юу;

7) уң тарафтагы әгъзаларны сул тарафтагылардан алданрак юу;

8) бер кат су койганнан соң, тәнне бер кат ышкып чыгу;

9) тәннең һәр җиренә өчәр кат су тидерү;

10) суны күп түгеп, исраф кылудан саклану;

11) госел алганда кыйблага арка белән тору.

ГОСЕЛНЕҢ СӘБӘПЛӘРЕ

Госелне фарыз итә торган сәбәпләр өчәү:

1) җөнеб (госелсез) булу;

2) хәез тәмамлану (хатын-кызларда һәр ай саен була торган күремнең тәмамлануы);

3) нифас тәмамлану (бала тудырганнан соң хатын-кызларның аналыгыннан килә торган канның туктавы).

Җөнеб булуның сәбәпләре дә өчәү:

1) шәһвәт вакытында мәни (сперма) чыгу;

2) җенси якынлык кылу;

3) йоклаганда хатыннарның һәм ирләрнең җенес әгъзаларыннан сыеклык килү.

Госелсез кеше тәненең һәр җире арусыз була. Җөнеб (госелсез) кешегә Коръәнне тоту, аны уку, мәчеткә керү, тәһарәт яки тәяммүм алмыйча ашау-эчү – мәкруһ, шуның өчен аңа мөмкин кадәр тиз арада госел алып пакьләнү фарыз. Тәһарәтсез кешегә Мөсхаф шәрифне (Коръәнне) тоту мәкруһ булса да, Коръән уку мәкруһ түгел. Догалар уку, сәлам бирү һәм тәсбих әйтү җөнеб кешегә дә, тәһарәтсез кешегә дә рөхсәт ителә.

САХИБЕ ГОЗЕР

(ГОЗЕР ИЯСЕ)

Авыру сәбәпле бер намаз дәвамында тәһарәтле була алмаган кеше – (мәсәлән, борыныннан даими кан чыгып тору,

күзләреннән һәрчак лайлалы яшь агу) сахибе гозер[1] дип атала. Андый кешегә һәр намаз өчен аерым тәһарәт алу кирәк. Шул гыйбадәте вакытында авыру сәбәпле тәһарәте бозылса да, намазы дөрес булып санала. Гыйбадәт вакытында нәҗесләре агып торса да тәһарәт тә, намаз да бозылмаган санала, әмма бер намаз өчен алынган тәһарәт икенче намаз өчен бозылган санала. Авыру сәбәпле аккан нәҗес, икенче намаз вакыты кергәнче тәненә я киеменә тисә дә, шул вакыт эчендә нәҗес булып саналмый. Икенче намазның вакыты кергәч тә ул нәҗес булып санала һәм гыйбадәтне үтәү өчен әлеге киемне юарга яки алмаштырырга кирәк була.

ТӘЯММҮМ

Су белән тәһарәт алу мөмкинлеге булмаганда тәһарәт урынына чиста җир белән тәяммүм кылына. Ул түбәндәге тәртип буенча башкарыла:

1) пакь җиргә ике кулның учы белән сугу;

2) учлар белән йөзне сыпыру (мәсех кылу);

3) янә шулай җиргә сугып, терсәкләргә кадәр кулларны сыпыру (мәсех кылу).

Йөзгә, кулларга мәсех кылганда, тәһарәт алгандагы кебек үк, су тияргә тиешле барлык җирләр дә сыпырыла. Тәяммүм кылу – су белән тәһарәт алу мөмкин булмаган очракта тәһарәт һәм госел урынына кулланыла.

---

[1] Гозер сүзе гарәп теленнән үтенеч, ялыныч, йомыш, сәбәп, сылтау рәвешендә тәрҗемә ителә

Түбәндәге очракларда намазны тәяммүм белән уку рөхсәт ителә:

1) су чыганагы намаз укыла торган урыннан ике чакрым чамасы ераклыкта булса;

2) су куллану намаз укучының авыруына зарар китерсә;

3) салкын тиюдән курыкса;

4) су чыганагына барырга нәрсәдән дә булса курыкса;

5) суны алыр өчен кирәкле җайланма булмаса;

6) үзе белән алынган суы сәфәрдә эчәр өчен генә җитәрлек булса;

7) тулы тәһарәт алу аркасында җеназа яки гает намазларына өлгерә алмау куркынычы туса.

Биш вакыт намазга яки җомга намазына өлгерә алмау очрагында намазны тәяммүм белән уку дөрес булмый. Туфрак, тузан, ком, балчык һәм таш кебек утта янмый торган нәрсәләр җир (туфрак) затыннан санала. Киемдәге тузанга яки тузансыз шома ташка да тәяммүм кылу рөхсәт ителә. Агач, үлән, тимер, кургаш һ. б. шундый нәрсәләр җир затыннан саналмый. Аларга һәм нәҗес (пычрак) нәрсәләргә тәяммүм кылу ярамый. Су табылу ихтималы булган очракта, аны бераз эзләп карамыйча, тәяммүм кылу дөрес түгел.

ТӘЯММҮМНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ, СӨННӘТЛӘРЕ ҺӘМ МӨФСИДЛӘРЕ

(АНЫ БОЗУЧЫ НӘРСӘЛӘР)

Тәяммүмнең фарызлары дүрт:

1) тәяммүмне намаз уку нияте белән башкару;

2) тәяммүм өчен җир затыннан булган нәрсәләрне куллану;

3) йөзгә мәсех кылу;

4) ике кулга мәсех кылу.

Тәяммүмнең сөннәтләре җиде:

1) «Бисмилләәһ» белән башлау;

2) җир затыннан булган нәрсәгә ике кул учы белән сугу;

3) тузаны күп ягылмасын өчен, кулларны бер тапкыр селкү;

4) бармакларны аралаштыру;

5) башта йөзгә, аннары кулларга тәртип буенча мәсех кылу;

6) әүвәл уң кулга, аннары сул кулга мәсех кылу;

7) йөзгә мәсех кылганнан соң, арага башка эш катыштырмыйча, кулларга мәсех кылу.

Тәяммүмне түбәндәге ике төрле эш боза:

1) таһарәтне боза торган һәрбер эш;

2) су белән таһарәт алу мөмкинлеге.

НӘҖЕСЛӘР

Намаз укырга җыенган кешенең тәне, киеме һәм намазлыгы да пакь булырга тиеш. Нәҗесле килеш намаз уку дөрес түгел. Нәҗес ике төрле була: җиңел һәм авыр. Карга һәм карчыга кебек итләре хәрам булган кошларның тизәкләре; ат, сыер һәм сарык сыман итләре хәләл булган хайваннарның бәвелләре (сидекләре) – җиңел нәҗесләр. Болардан кала барлык нәҗесләр дә авыр нәҗес булып санала. Мәсәлән, кешенең тизәге һәм бәвеле; ат, сыер, сарык кебек итләре хәләл булган хайваннарның тизәкләре; эт, бүре сыман итләре хәрам булган хайваннарның тизәкләре, бәвелләре, селәгәйләре, тиреләре; каз, тавык кебек итләре хәләл булган кошларның тизәкләре; үләксә һәм дуңгыз каннары, хайванның бугазыннан йә җәрәхәтеннән аккан кан, эрен, сары су; авыру күз яше, исерткеч эчемлек һәм авыздан чыккан косык – болар барысы да авыр нәҗескә керә. Күгәрчен, чыпчык кебек кошларның тизәкләре, балык һәм бөҗәк каны, ару итнең юеше, барлык су хайваннарының каны һәм мае, елаганда чыккан күз яше, авыз тулмаслык аз күләмдәге косык, төкерек һәм какырык – нәҗес түгел, пакь нәрсәләр булып санала.

Дуңгыздан башка хайваннарның йоннары, кипкән сөяк һәм сеңерләре нәҗескә керми. Шәригатьчә бугазланган хайваннарның итләре – ашарга хәләл булмаса да, нәҗес түгел, тиреләре эшкәртелмәсә дә, пакь булып санала[1]. Шәригатьчә бугазланмаган хайваннарның итләре дә, эшкәртелмәгән тиреләре дә – нәҗес. Әгәр тиреләре эшкәртелсә, пакь була. Дуңгызның бөтен гәүдәсе нәҗес санала, һичбер вакытта да пакьләнми.

Бер нәҗес нәрсә янып көлгә, черәп туфракка әйләнсә яки тозланып тоз рәвешенә килсә – пакь була. Исерткеч эчемлек тоз белән катышып серкәгә (уксуска) әйләнсә, нәҗес майдан сабын ясалса – әлеге серкә дә, сабын да пакь санала. Тәндә, киемдә яки намазлыкта зурлыгы бер карыштан (17,78см) артык булмаган җиңел нәҗес яисә бер мыскал (4,26г) чамасыннан артык булмаган авыр нәҗес булса, шуның белән намаз уку дөрес була. Әгәр аның күләме бу күрсәткечләрдән артып китсә, намаз уку дөрес булмый. Зур паласның бер башы нәҗесләнгән булса, нәҗесләнмәгән өлешендә намаз укырга ярый. Нәҗес сыеклык түгелгән туфрак кипсә, аның өстендә намазлык җәймичә дә намаз укырга була.

НӘЖЕСЛӘРДӘН ПАКЬЛӘҮ

Нәҗесләнгән киемне пычрактан пакьләү өчен нәҗесне кырып бетергәннән соң өч тапкыр юып, тамчысы таммас-

[1] Мәсәлән, төлке, бүре кебек итләре хәрам булган хайваннар шәригатьчә бугазланса, аларның тиреләре, эшкәртелмәсә дә, пакь булып санала

лык булганчы өч тапкыр сыгарга кирәк. Тун, палас һәм юрган кебек сыгу мөмкин булмаган нәрсәләрне өч мәртәбә юып, тамчысы тамып беткәнче өч мәртәбә элеп куярга кирәк. Пычрак калмаса, аз гына исе йә табы калса да, кием нәҗесле булып саналмый. Су белән юылса бигрәк тә пакь була. Күннән тегелгән әйбердәге кипкән каты нәҗес уып төшерү белән пакьләнә, әмма сыек һәм юеш нәҗес өч мәртәбә юмыйча пакьләнми. Бер нәрсәнең кай җиренә нәҗес тигәнлеге онытылса, якынча шул җире юылса, пакь булып санала. Бал, май һәм сөт кебек нәрсәләргә бераз сыек нәҗес катышса, өч мәртәбә ару су кушып, суы беткәнче өч мәртәбә кайнату белән пакь була.

ПАКЬЛӘНҮ

Бәдрәфкә кергәндә сул аяктан атлап керү һәм чыкканда уң аяктан атлап чыгу мөстәхәб. Хаҗәтне (йомышны) үтәгән вакытта кыйблага каршы, йә арка ягы белән булу һәм гаурәткә, нәҗескә карау – мәкруһ (шелтәләнә). Хаҗәтне ачык җирдә үтәгәндә айга яки кояшка каршы, яисә арка ягы белән булу да мәкруһ санала. Бәдрәфтә кечкенә хаҗәтне үтәгән кешегә сул кулы белән истибра кылу, ягъни нәҗесне нәрсә белән булса да корыту зарур. Бәдрәфтә зур хаҗәтне үтәгән кешегә сул кулы белән истинҗа кылу, ягъни гаурәтне пакьләү тиешле. Истибра һәм истинҗаны уң кул белән үтәү, печән һәм кәгазь[1] кебек кадерле нәрсәләр куллану – мәкруһ. Әгәр нәҗесе тәнен

---

[1] Әхмәдһади хәзрәт яшәгән заманда бәдрәф кәгазе булмаган, шуңа күрә бәдрәфтә язулы кәгазь куллану мәкруһ булып саналган

буяса, истибраны да, истинҗаны да су белән башкарырга кирәк.

ПАКЬ СУЛАР

Чишмә, елга, күл, диңгез, кое, кар, яңгыр һәм боз сулары – һәркайсы пакь. Аларга чиста нәрсә кушылган булса да тәһарәт алырга ярый. Серкә, шулпа, әйрән сулары, кавын кебек җимешләрдән чыккан сулар пакь булсалар да тәһарәткә ярамыйлар. Тәһарәт алганда ару савытка җыелган су – «мәэ мөстәгъмәл» (кулланылган су) дип атала. Андый су тыштан пакь булып күренсә дә, икенче тапкыр тәһарәт алырга ярамый. Агым суга, әйләнәсе 40 аршын (якынча 29 м) һәм тирәнлеге ярты карыш (8,89 см) кадәр булган сулыкка (бассейнга) нәҗес катышса да пычранмый. Моннан ким булган суга аз гына нәҗес катышса да пычрана. Әгәр катышкан нәҗес суның тәмен йә исен, йә төсен үзгәртсә, бик зур су булса да яки агым су булса да пычрана (нәҗесләнә). Ат, сыер һәм сарык кебек ите хәләл булган хайваннар эчкәннән соң савытта калган су пакь санала, тәһарәт алырга да яраклы, әмма эт, бүре кебек ите хәрам булган хайваннардан калган су – нәҗес. Тавык, мәче һәм карчыгадан калган сулар нәҗес булмасалар да, алар белән тәһарәт алу мәкруһ.

КОЕ СУЫ

Коега бер нәҗес төшсә, аның суы тулысынча пычрана. Кое суының тулаем күләме чамаланса, шулкадәр суны

чыгарып түкмичә пакьләнми. Әгәр анда чыпчык кадәр бер кечкенә хайван төшеп үлсә – 20 чиләккә кадәр, тавык кадәр бер хайван төшеп үлсә – 40 чиләккә кадәр суын түгәргә кирәк була. Ә ул хайваннарның эчләре күпкән яки тәннәре җебегән булса, барча суын түкмичә коеның суы пакьләнми. Кеше яки сарык кадәр бер хайван төшеп үлсә, эче күпмәсә дә, коеның барлык суын түгү тиешле була. Әгәр коеның кайсы көнне пычранганы билгеле булмаса, өч тәүлек дәвамында нәҗескә санала. Шул вакытта алынган сулар түгелергә тиеш.

ГАУРӘТ

(ОЯТ ЖИР)

Намаз укыганда гаурәт җирләр (тәннең кешегә күрсәтергә ярамый торган урыннары) капланган булу фарыз. Аулак бүлмәдә дә ялангач рәвештә намаз укырга ярамый. Ирләрнең кендекләре турысыннан башлап тез асларына кадәр булган тәннәре – гаурәт. Ә билләреннән югары һәм тездән түбән җирләре ачык булса да, намаз уку дөрес санала. Хатын-кыз тәненең һәр җире – гаурәт, әмма йөзләре, беләзекләренә кадәр ике учлары һәм тубыкларына кадәр аяк башлары гаурәт саналмый. Янында һичбер ару кииеме булмаса, киемен юарга суы да булмаса, намазны нәҗесле кием белән уку яки ялангач уку да дөрес була. Намаз ялангач укылса, утырып кына укырга тиешле.

ГОЗЕРЛЕ ХАТЫННАР

Яшь баласы булган хатыннар кырык көнгә кадәр, ягъни гозерләреннән пакьләнгәнче арусыз саналалар. Шул вакытта алар намаз да укымыйлар, ураза да тотмыйлар. Гозерләре тәмамлангач алар госел коенып пакьләнергә һәм Рамазан аенда тотылмаган уразаларын соңыннан каза кылырга тиешләр. Балигъ булганнан соң ай саен гозерле булган хатыннар да, шул вакытларда арусыз булып, ураза һәм намазларын калдыралар. Гозерләре тәмамлангач аларга да госел алып пакьләнү фарыз. Пакьләнгәч калган уразаларын тоталар. Балигъ хатын-кызларның айлык гозерләре өч көннән ким һәм ун көннән артык булмаска тиеш. Әгәр артык булса – авыру галәмәте. Унберенче көннән башлап уразаларын тотарга, сахибе гозер булып намазларын да укырга тиешләр.

Шушы урында хөрмәтле Әхмәдһади Максуди хезмәтенең икенче – «Тәһарәт» бүлеге тәмамлана.

НАМАЗ

Коръән аяте:

إِنَّ الصَّلاَةَ كَانَتْ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ كِتَابًا مَّوْقُوتًا

Иннәс-саләәтә кәәнәт гәләл-мү'миниинә китәәбәм-мәүкуутәә

Мәгънәсе: «Намаз – мөселманнарның төгәл вакытларда укылырга фарыз ителгән гыйбадәтедер».

(«Ниса /Хатыннар/», 4:103)

Хәдис-шәриф

اَلصَّلَوَاتُ الْخَمْسُ وَالْجُمْعَةُ إِلَى الْجُمْعَةِ كَفَّارَاتٌ لِمَا بَيْنَهُنَّ مَا اجْتُنِبَتِ الْكَبَائِرُ

Әс-саләуатүл-хамсү үәл-җүмгәтү иләл-җүмгәти кәффәәраатүн лимәә бәйнәһүннә мәҗтүнибәтил-кәбәә'ир

Мәгънәсе: Зур гөнаһлардан саклангганда биш вакыт намаз һәм җомга намазы икенче җомгага кадәр араларында булган кечкенә гөнаһларның гафу ителүенә сәбәпче булырлар.

1) Намаз ул – Аллаһы Тәгаләгә билгеле рәвештә күңел һәм тән белән гыйбадәт кылу.

2) Барча мөэминнәргә һәр тәүлектә биш вакыт намаз (иртәнге, өйлә, икенде, ахшам һәм ястү) уку фарыз.

3) Һәрбер мөселманга ястү намазыннан соң витр намазын уку – вәҗиб.

4) Җомга көнне өйлә намазы урынына җомга намазы уку – фарыз.

5) Гает Фитыр (Ураза бәйрәме) белән Гает Корбан (Корбан бәйрәме) көннәрендә гает (бәйрәм) намазларын уку – вәҗиб.

6) Рамазан аенда ястү намазыннан соң витр намазына кадәр тәравих намазын уку – сөннәт. Башка нәфел (өстәмә) намазлар – мөстәхәб.

7) Мәет өчен җеназа намазын уку – фарыз кифая[1].

НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

Һәр намазны үз вакытында уку – фарыз. Вакыты кергәнче укылган намаз фарыз намаз булып саналмый.

Вакытында укылмаган намазны соңыннан каза кылу – фарыз.

Иртәнге намазының вакыты – таң яктылыгы җәелгәннән башлап кояш чыга башлаганчыга кадәр.

---

1 «Фарыз кифая» – арадан бер йә берничә кеше үтәгән очракта, башка кешеләр үтәмәсә дә ярый торган фарыз.

Өйлә намазының вакыты – кояш иң югары ноктасыннан авышканнан башлап икенде намазы вакытына кадәр.

Икенде намазының вакыты – һәр әйбернең күләгәсе үзеннән ике мәртәбәгә зуррак булудан башлап кояш тәмам батып беткәнчегә кадәр.

Ахшам намазының вакыты – кояш батып, тулысынча күмелгәннән башлап шәфәкъ[1] кызыллыгы беткәнчегә кадәр.

Ястү намазының вакыты – шәфәкъ кызыллыгы беткәннән башлап таң яктылыгы җәелгәнчегә кадәр.

Витр һәм тәравих намазларының вакыты – ястү намазы укылганнан соң таң атканчыга кадәр.

Җомга намазының вакыты – өйлә намазы вакыты белән бер.

Гает намазларының вакыты – кояш чыгып, бераз күтәрелгәннән башлап өйлә вакыты кергәнчегә кадәр.

Кояш чыкканда, ул иң югары ноктада вакытта (зәвәл) һәм кояш батып торганда һичбер намазны укырга ярамый.

Иртәнге намазны укыганда кояш чыга башласа – намаз бозыла, әмма икенде намазын укыганда кояш бата башласа – намаз бозылмый. Икендене кояш батуга якын вакытка кичектерү – мәкруһ.

Таң атканнан соң кояш чыкканчы, икенде намазы укыганнан соң ахшам укыганчы, мәчеттә имам хөтбә укыган

---

[1] Шәфәкъ – кояш батканнан соң мәгъриб (көнбатыш) тарафларында күренә торган кызгылт яктылык.

вакытта һәм гает намазларын укыр алдыннан нәфел намазларын уку – дөрес түгел.

КЫЙБЛА

Намазны кыйбла тарафына карап уку – фарыз. Кыйбланың кайсы якта икәнен белә торып намазны башка тарафка таба карап уку дөрес булмый.

Мөселманнарның кыйбласы – Гарәбстан ярымутравының Мәккәи Мөкәррәмә шәһәрендә Кәгъбә исемле мөбарәк бинаның урыны.

Казан шәһәреннән караганда, кыйбла ягы көньяктан 9 дәрәҗәгә кадәр уң яктарак. Казанда июнь аенда көндезге сәгать беренче 36 минутта кояш нәкъ кыйбла турысында була.

Сахрада яки урманда кыйбла кайсы якта икәнлеге билгеле булмаганда һәм якын тирәдә әлеге мәгълүматны белүче кеше дә табылмаганда, көндез кояш яктысына карап, төнлә Тимер Казык йолдызына яки юлга һәм тауларга карап, күңел белән чамалап кыйбланы эзләргә кирәк. Боларны истә тотып күңел кай тарафның кыйбла булуын якын күрсә – намаз шул якка карап укыла.

Намаз укыган вакытта кыйбланың икенче яктарак булуы сизелсә, намазны бозмыйча гына шул якка таба борылырга кирәк.

Куркыныч янаганда юлда намазны атка атланган килеш уку да дөрес, ул чагында кыйбла ягына таба карау мөһим түгел. Юл кайсы якка таба барса, шул якка таба карап уку дөрес санала.

НИЯТ

(УЙ, ТЕЛӘК)

Намазга керешкәндә укылачак намазны күңел белән ниятләү – фарыз. Тел белән кайсы намаз икәнен әйтеп ниятләү – мөстәхәб.

Имамга оеган кешегә аңа оюы турында ниятләү тиеш.

Биш вакыт намазны түбәндәгечә ниятлиләр:

Ният кылдым иртәнге намазның 2 рәкәгать сөннәтен үтәмәккә, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Ният кылдым иртәнге намазның 2 рәкәгать фарызын үтәмәккә, оедым ошбу имамга[1], халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Ният кылдым өйлә намазының 4 рәкәгать сөннәтен үтәмәккә, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Ният кылдым өйлә намазының 4 рәкәгать фарызын үтәмәккә, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Ният кылдым өйлә намазының 2 рәкәгать сөннәтен үтәмәккә, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Ният кылдым икенде намазының 4 рәкәгать фарызын үтәмәккә, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Ният кылдым ахшам намазының 3 рәкәгать фарызын үтәмәккә, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

---

[1] «Оедым ошбу имамга» дигән сүз имамга оеп укыганда гына әйтелә.

Ният кылдым ахшам намазының 2 рәкәгать сөннәтен үтәмәккә, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Ният кылдым ястү намазының 4 рәкәгать фарызын үтәмәккә, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Ният кылдым ястү намазының 2 рәкәгать сөннәтен үтәмәккә, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Ният кылдым 3 рәкәгать витр намазын үтәмәккә, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

АЗАН ҺӘМ КАМӘТ (ИКАМӘТ)

Биш вакыт фарыз намазларының һәм җомга намазының вакыты кергәч азан әйтү, фарызларын укыр алдыннан камәт төшерү – сөннәт.

Бер мәхәллә мәчетендә әйтелгән азан һәм камәт бөтен мәхәллә өчен җитә. Мәчеттә азан әйтелгәч, әлеге мәчет мәхәлләсенә кергән өйләрдә намаз уку өчен азан да, камәт тә кирәкми.

Азан сүзләре:

Дүрт тапкыр:

اَللّٰهُ أَكْبَرُ

Аллаһу әкбәр

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәдән олуграк».

Ике тапкыр:

أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ

Әшһәдү әл-ләә иләһә илләл-лааһ

Мәгънәсе: «Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк».

Ике тапкыр:

أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللهِ

Әшһәдү әннә Мүхәммәдәр-расүүлүл-лааһ

Мәгънәсе: «Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Мөхәммәд ﷺ – Аллаһы Тәгаләнең илчесе».

Ике тапкыр:

حَيَّ عَلَى الصَّلَاةِ

Хәййә гәләс-саләәһ

Мәгънәсе: «Ашыгыгыз намазга».

Ике тапкыр:

حَيَّ عَلَى الْفَلَاحِ

Хәййә гәләл-фәләәһ

Мәгънәсе: «Ашыгыгыз газаптан котылырга».

Ике тапкыр:

اَللّٰهُ أَكْبَرُ

Аллаһу әкбәр

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәдән олуграк».

Бер тапкыр:

لَا إِلَهَ إِلَّا اَللّٰهُ

Ләә иләһә илләл-лааһ

Мәгънәсе: «Бер Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк».

Иртәнге намаз азанында «**Хәййә гәләл-фәләәһ**» дигәннән соң ике тапкыр:

اَلصَّلَاةُ خَيْرٌ مِنَ النَّوْمِ

Әс-саләәтү хайрүм-минән-нәүм

дип әйтергә кирәк. *Мәгънәсе:* «Дөреслектә, намаз уку йокыдан яхшырак».

Камәт тә азан кебек әйтелә. Каматтә фәкать «**Хәййә гәләл-фәләәһ**» дигәннән соң ике тапкыр:

قَدْ قَامَتِ الصَّلَاةِ

Кадъ кааматис-саләәһ

дип әйтергә кирәк. *Мәгънәсе:* «Дөреслектә, намаз укыла башлады». Камәт азанга караганда тизрәк әйтелә.

Камәт укучы **«Хәййә гәләс-саләәһ»** дигәннән соң, намаз укырга җыенган кешеләргә урыннарыннан торып ниятләргә һәм **«Кадъ кааматис-саләәһ»** дигән вакытта тәкбир әйтеп намазга керешү – мөстәхәб.

АЗАННЫҢ МӨСТӘХӘБЛӘРЕ

1) Мәзингә, ягъни азан әйтүче кешегә тәһарәтле булу, кыйблага каршы аягүрә тору, ишарә бармакларын колак очларына кую, азанның сүзләрен ачык итеп, сузып, ике сүзне бергә кушмыйча, һәрберсен аерып әйтү, **Хәййә гәләс-саләәһ** дигән сүзләрне уң якка таба карап һәм **Хәййә гәләл-фәләәһ** дигән сүзләрне сул якка карап әйтү – мөстәхәб.

2) Азан әйткәнне ишеткән кешегә йөрүдән һәм ашаудан туктап, сөйләшмичә, мәзин артыннан азан сүзләрен кабатлау – мөстәхәб.

3) Мәзин **Хәййә гәләс-саләәһ** дигәч,

لَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللهِ الْعَلِيِّ الْعَظِيمِ

Ләә хәүлә үә ләә ку-үәтә илләә билләәһил-гәлиййил-гәҙыйм, ягъни «Һәрбер хәл һәм куәт олуг Аллаһы Тәгаләдән генә» дип әйтү;

4) Мөәззин **Хәййә гәләл-фәләәһ** дигәч,

مَا شَاءَ اللهُ كَانَ وَمَا لَمْ يَشَاءْ لَمْ يَكُنْ

Мәә шәә'әллааһу кәәнә үә мәә ләм йәшәә' ләм йәкүн, ягъни «Аллаһы Тәгалә теләгән эш һич булмый калмас һәм Ул теләмәгән эш һич булмас» дип әйтү – мөстәхәб.

5) Тәһарәтсез, җөнеб, дивана, исерек һәм фасикъ (начар юлда йөргән, азгын) кешеләрнең, хатыннарның, сабый балаларның азан яки камәт әйтүләре мәкруһ.

6) *Азан догасы*

اَللَّهُمَّ رَبَّ هَذِهِ الدَّعْوَةِ التَّامَّةِ وَالصَّلَاةِ الْقَائِمَةِ آتِ مُحَمَّدًا الْوَسِيلَةَ وَالْفَضِيلَةَ وَالدَّرَجَةَ الْعَالِيَةَ الرَّفِيعَةَ وَابْعَثْهُ مَقَامًا مَحْمُودًا الَّذِى وَعَدْتَهُ وَارْزُقْنَا شَفَاعَتَهُ يَوْمَ الْقِيَامَةِ إِنَّكَ لَا تُخْلِفُ الْمِيعَادَ

Әллааһүммә раббә һәәҙиһид-дәгъүәтит-тәәммәти үәс-саләәтил-каа'имәһ. Әәти Мүхәммәдәнил-үәсиләтә үәл-фәдыйләтә үәд-дәраҗәтәл-гәәлийәтәр-рафиигәһ. Үәбъгәҫһү мәкаамәм-мәхмүдәнил-ләҙии

үәгәдтәһү үәр-зүкнәә шәфәәгәтәһү йәүмәл-кыйәәмәһ. Иннәкә лә түхълифүл-мигәәдъ

Мәгънәсе: «Әй, шушы камил азанның һәм вакыты кергән намазның хуҗасы Аллаһы Тәгалә. Мөхәммәд ﷺ гә ярдәмне, артыклыкны һәм югары дәрәҗәне бир. Шулай ук аны Үзең вәгъдә кылган мактаулы урынга ирештер һәм Кыямәт көнендә аның шәфәгатен безгә насыйп ит. Дөреслектә, Син Үз вәгъдәңә хилафлык кылмыйсың».

НАМАЗНЫҢ ЗИКЕРЛӘРЕ

1) Сәнә догасы:

سُبْحَانَكَ اللّٰهُمَّ وَبِحَمْدِكَ وَتَبَارَكَ اسْمُكَ وَتَعَالٰى جَدُّكَ
وَ لَآ اِلٰهَ غَيْرُكَ

Сөбъхәәнәкәл-лааһүммә үә бихәмдикә үә тәбәәракәс-мүкә үә тәгәәләә җәддүкә үә ләәә иләәһә гайрүк

Мәгънәсе: «Әй Аллаһы, Сиңа дан һәм мактау булсын. Синең исемең мөбарәк һәм дәрәҗәң олуг. Синнән башка бернинди Илаһи зат юк».

2) Тәгәү’үз:

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

Әгүүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим

Мәгънәсе: «Куылган шайтанның явызлыгыннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам (сыенам)».

3) Бәсмәләһ:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим

Мәгънәсе: «Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы исеме белән башлыйм эшемне».

4) «Фатиха» сүрәсе:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ﴿٢﴾ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ﴿٣﴾

مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ ﴿٤﴾ إِيَّاكَ نَعْبُدُ وإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ ﴿٥﴾

اِهْدِنَـا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ ﴿٦﴾ صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ

غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلاَ الضَّالِّينَ ﴿٧﴾

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әл-хәмдү лилләәһи раббил-гәәләмиин. Әр-рахмәәнир-рахиим. Мәәлики-йәүмид-диин. Иййәәкә нәгбүдү үә иййәәкә нәстәгиин. Иһдинәс-сыраатаәль-мүстәкыйм.

Сырааталь-ләҙиинә әнгәмтә гәләйһим. Гайриль-мәгдууби гәләйһим үәләд-дааааааллиин. Әмин

Мәгънәсе: «Бөтен галәмнәрнең Тәрбиячесе, Раббысы Аллаһыга мактаулар булсын! Ул – мәрхәмәтле, рәхимле. Җәза көненең (Ахирәтнең) Хуҗасы. Бары тик Сиңа гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Безне туры юлга күндер. Сине ачуландырмаган һәм хак юлдан адашмаган кешеләр юлына күндер». (Фатиха сүрәсен укып бетергәч: «Әмин», ягъни теләкләребезне кабул кыл» дип әйтергә кирәк)[1].

5) «Мәсәд» сүрәсе:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

تَبَّتْ يَدَا أَبِي لَهَبٍ وَتَبَّ ﴿١﴾ مَا أَغْنَى عَنْهُ مَالُهُ وَمَا كَسَبَ
﴿٢﴾ سَيَصْلَى نَاراً ذَاتَ لَهَبٍ ﴿٣﴾ وَامْرَأَتُهُ حَمَّالَةَ الْحَطَبِ
﴿٤﴾ فِي جِيدِهَا حَبْلٌ مِّن مَّسَدٍ ﴿٥﴾

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Тәббәт йәдәә әбии ләһәбиү-үә тәббъ. Мәә әгънәә гәнһү мәәлүһүү үә мәә кәсәбъ. Сәйәсъләә нәәраң ҙәәтә ләһәбъ. Үәмра'әтүһүү хәммәәләтәл-хәтабъ. Фии җиидиһәә хәбълүм-мим-мәсәдъ

[1] Намазда «Фатиха»дан соң «Әмин» сүзен эчтән генә әйтергә кирәк

Мәгънәсе: «Әбү Ләһәбнең[1] ике кулы корысын! Үзен дә ләгънәт орсын! Кәсеп итеп җыйган малы да, байлыгы да аңа ярдәм итмәде. Ул ялкынлы утта яначак; хатыны да, утын күтәргән килеш. Хатынының муенында хөрмә мунчаласыннан ишелгән бау булыр».

6) «Ихлас» сүрәсе:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ ﴿١﴾ اللَّهُ الصَّمَدُ ﴿٢﴾ لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ
﴿٣﴾ وَلَمْ يَكُن لَّهُ كُفُوًا أَحَدٌ ﴿٤﴾

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль һү-үәл-лааһү әхәдъ. Әл-лааһүс-самәдъ. Ләм йәлидъ үә ләм йүләдъ. Үә ләм йәкүл ләһүү күфү-үән әхәдъ

Мәгънәсе: «Әйт син, әй Мөхәммәд ﷺ: «Аллаһы бер генә. Ул камил Хуҗа. Ул тудырылмаган да, тудырмаган да. Аллаһыга тиңдәш юк».

7) «Фәләкъ» сүрәсе:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ ﴿١﴾ مِن شَرِّ مَا خَلَقَ ﴿٢﴾ وَمِن شَرِّ

---

1 Әбү Ләһәб – Мөхәммәд ﷺ нең атасы белән бертуган абыйсы. Үзе дә, хатыны да Пәйгамбәребез ﷺ гә дошман булган.

غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ ﴿٣﴾ وَمِن شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ ﴿٤﴾

وَمِن شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ ﴿٥﴾

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль әгүүҙу бираббиль-фәләкъ. Миң шәрри мәә халәкъ. Үә миң шәрри гаасикыйн иҙәә үәкабъ. Үә миң шәррин-нәффәәҫәәти фил-гүкадъ. Үә миң шәрри хәәсидин иҙәә хәсәдъ

Мәгънәсе: «Әйт син, әй Мөхәммәд ﷺ аларга: «Мин сыенамын таңны тудыручы Раббыма. Мәхлукларның мәкереннән (зарарыннан), дөм караңгы төннәрдәге мәкердән, ырым төеннәрен өшкерүче им-томчыларның (бозучыларның) мәкереннән (явызлыгыннан), көнчел кешенең хөсетлегеннән (көнчелегеннән) Аллаһыга сыенамын».

8) «Нәс» сүрәсе:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ ﴿١﴾ مَلِكِ النَّاسِ ﴿٢﴾ إِلَهِ النَّاسِ ﴿٣﴾ مِن شَرِّ الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ ﴿٤﴾ الَّذِي يُوَسْوِسُ فِي صُدُورِ النَّاسِ ﴿٥﴾ مِنَ الْجِنَّةِ وَ النَّاسِ ﴿٦﴾

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль әгүүҙу бираббин-нәәс. Мәликин-нәәс. Иләәһин-нәәс. Миң

шәррил-үәсүәәсил-ханнәәс. Әлләҙии йүәс-үисү фии судүүрин-нәәс. Минәл-җиннәти үән-нәәс

Мәгънәсе: «Әйт син, әй Мөхәммәд ﷺ : «Кешеләрнең Раббысына сыенамын. Кешеләрнең Патшасына, кешеләрнең Аллаһына, шайтанның мәкерле котыртуыннан, кешеләрнең күңеленә вәсвәсә салучы шайтаннан, (ул яманлыкка котыртучы) җен токымыннан булса да, кешеләрдән булса да (Аллаһыга сыенамын)».

9) Рөкүгъ тәсбихе:

سُبْحَانَ رَبِّيَ الْعَظِيمِ

Сөбхәәнә раббийәл-гәҙыйм

Мәгънәсе: «Олуг Раббымны пакь дип беләм».

10) Тәсмиг:

سَمِعَ اللّٰهُ لِمَنْ حَمِدَهُ

Сәмигәл-лааһу лимән хәмидәһ

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә Үзен мактаган кешенең мактавын ишетә».

11) Тәхмид:

رَبَّنَا لَكَ الْحَمْدُ

Раббәнәә ләкәл-хәмдъ

Мәгънәсе: «Әй Раббыбыз, һәрбер мактау Сиңа гына тиеш».

12) Сәҗдә тәсбихе:

سُبْحَانَ رَبِّيَ الْأَعْلَى

Сөбхәәнә раббийәл-әгләә

Мәгънәсе: «Бөек булучы Раббымны пакь дип беләм».

13) Тәшәһһүд:

اَلتَّحِيَّاتُ لِلّٰهِ وَالصَّلَوَاتُ وَالطَّيِّبَاتُ اَلسَّلاَمُ عَلَيْكَ اَيُّهَا النَّبِيُّ

وَرَحْمَةُ اللهِ وَ بَرَكَاتُهُ السَّلاَمُ عَلَيْنَا وَ عَلٰى عِبَادِاللهِ الصَّالِحِينَ

اَشْهَدُ اَنْ لآَ اِلٰهَ اِلاَّ اللهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًاعَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

Әт-тәхийййәәтү лилләәһи үәс-саләүәәтү үәт-таййибәәт. Әс-сәләәмү гәләйкә әййүһән-нәбиййү үә рахмәтул-лааһи үә бәракәәтүһ. Әс-сәләәмү гәләйнәә үә гәләә гибәәдил-ләәһиссаалихиин. Әшһәдү әл-ләәә иләәһә илләл-лааһу үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһүү үә расүүлүһ

Мәгънәсе: «Тел гыйбадәтләре дә, тән гыйбадәтләре дә, мал гыйбадәтләре дә – һәркайсы Аллаһы Тәгалә өчен. Әй Пәйгамбәребез, Сиңа Аллаһының сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын. Сәлам безгә дә һәм Аллаһы Тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә булсын. Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи

зат һич юк. Шулай ук гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Мөхәммәд ﷺ – Аллаһы Тәгаләнең колы һәм илчесе».

14) Салават:

اَللّٰهُمَّ صَلِّ عَلٰى مُحَمَّدٍ وَ عَلٰى اٰلِ مُحَمَّدٍ كَمَا صَلَّيْتَ عَلٰى
اِبْرَاهِيمَ وَ عَلٰى اٰلِ اِبْرَاهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ اَللّٰهُمَّ بَارِكْ عَلٰى
مُحَمَّدٍ وَ عَلَى اٰلِ مُحَمَّدٍ كَمَا بَارَكْتَ عَلٰى اِبْرَاهِيمَ وَ عَلٰى اٰلِ
اِبْرَاهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ

Әллааһүммә салли гәләә Мүхәммәдин үә гәләә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә гәләә Ибрааһиимә үә гәләә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид. Әллааһүммә бәәрик гәләә Мүхәммәдин үә гәләә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә гәләә Ибраһиимә үә гәләә әәли Ибраһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид

Мәгънәсе: «Йә Рабби, Ибраһим (عليه السلام) гә һәм аның гаиләсенә рәхмәтеңне биргән кебек, Мөхәммәд ﷺ гә һәм аның гаиләсенә дә рәхмәтеңне бир. Дөреслектә, Син мактаулы һәм олуг зат. Йә Рабби, Ибраһим (عليه السلام) гә һәм аның гаиләсенә бәрәкәтеңне биргән кебек, Мөхәммәд ﷺ гә һәм аның гаиләсенә дә бәрәкәтеңне бир. Дөреслектә, Син – мактаулы һәм олуг зат».

15) Дога аяте:

رَبَّنَا اٰتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَ فِي اْلاَخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

Раббәнәә әәтинә фид-дүнйәә хәсәнәтән үә фил-әәхырати хәсәнәтән үә кыйнәә гәӟәәбән-нәәр

Мәгънәсе: «Йә Раббыбыз, безгә дөньяда да, ахирәттә дә изге нигъмәтләреңне бирсәң иде. Һәм безне җәһәннәм газабыннан сакласаң иде».

16) Сәлам:

اَلسَّلاَمُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ اللهِ

Әс-сәләәмү гәләйкүм үә рахмәтул-лааһ

Мәгънәсе: «Сезгә Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын».

17) Сәлам догасы:

اَللّٰهُمَّ اَنْتَ السَّلاَمُ وَمِنْكَ السَّلاَمُ تَبَارَكْتَ يَا ذَاالْجَلاَلِ وَالْإِكْرَامِ

Әллааһүммә әнтәс-сәләәмү үә минкәс-сәләәмү тәбәәрактә йәә ӟәл-җәләәли үәл-икраам

Мәгънәсе: «Йә Рабби, Син һәрбер бәладән саклаучы. Һәрбер сәламәтлек Синнән генә. Син – мөбарәк зат, әй олуглык һәм хөрмәт иясе Аллаһ».

18) Кунүт догасы:

اَللّٰهُمَّ إِنَّا نَسْتَعِينُكَ وَ نَسْتَغْفِرُكَ وَ نَسْتَهْدِيكَ
وَ نُؤْمِنُ بِكَ وَ نَتُوبُ
اِلَيْكَ وَ نَتَوَكَّلُ عَلَيْكَ وَ نُثْنِي عَلَيْكَ الْخَيْرَ كُلَّهُ نَشْكُرُكَ
وَ لاَ نَكْفُرُكَ وَ نَخْلَعُ وَ نَتْرُكُ مَنْ يَفْجُرُكَ
اَللّٰهُمَّ اِيَّاكَ نَعْبُدُ وَ لَكَ نُصَلِّى وَ نَسْجُدُ وَ اِلَيْكَ نَسْعٰى وَ
نَحْفِدُ نَرْجُو رَحْمَتَكَ وَ نَخْشٰى عَذَابَكَ اِنَّ عَذَابَكَ بِالْكُفَّارِ
مُلْحِقٌ

Әллааһүммә иннәә нәстәгиинүкә үә нәстәгфирүкә үә нәстәһдиикә үә нү'минү бикә үә нәтүүбү иләйкә үә нәтәүәккәлү гәләйкә үә нүҫни гәләйкәл-хайра күлләһү нәшкүрүкә үә ләә нәкфүрүк. Үә нәхъләгү үә нәтрүкү мән йәфҗүрүк. Әллааһүммә иййәәкә нәгбүдү үә ләкә нүсаллии үә нәсҗүдү үә иләйкә нәсгәә үә нәхфидү нәрҗүү рахмәтәкә үә нәхшәә гәҙәәбәкә иннә гәҙәәбәкә бил-күффәәри мүлхикъ

Мәгънәсе: «Йә Рабби, дөреслектә, без Синнән ярдәм сорыйбыз һәм гөнаһларыбызны ярлыкавыңны телибез. Шулай ук Сиңа инанабыз, тәвәккәл кылып,

һәрбер эшләребезне Сиңа тапшырабыз. Шулай ук Сине мактыйбыз. Сиңа шөкер кылабыз, көферлек кылмыйбыз. Сиңа карата гөнаһ кыла торган кешеләрне ташлыйбыз. Синең (ризалыгың) өчен генә гыйбадәт кылабыз. Синең өчен генә намаз укыйбыз, сәҗдә кылабыз һәм гыйбадәт кылып Сиңа якын булырга тырышабыз. Рәхмәтеңә өметләнәбез, газабыңнан куркабыз. Дөреслектә, Синең газабың имансыз кешеләр өчен генә булачак».

ИКЕ РӘКӘГАТЬЛЕ НАМАЗ УКУ РӘВЕШЕ

Ике рәкәгатьле намаз эчендә ике кыям, ике рөкүгъ, дүрт сәҗдә һәм бер кагъдә бар.

Кыям – аягүрә тору, рөкүгъ – бөгелү, сәҗдә – маңгайны намазлыкка тидерү, кагъдә – утыру дигәнне аңлата.

Ике рәкәгатьле намазны укырга җыенган кеше намазга керешкәндә башта ният кыла, аннан соң кулларын күтәреп, баш бармакларының битләрен колак йомшаклары артларына тидереп тәкбир әйтә. Кулларын баглап кендек астына куя, «Сәнә'» укый. Аннары «Әгүүзү» һәм «Бисмилләәһ» әйтеп «Фатиха» сүрәсен укый, ахырында «Әәмииин» дип әйтә. Аннары берәр сүрә укый һәм тәкбир әйтеп, рөкүгъкә иелә. Анда 3 мәртәбә тәсбих әйтә. Рөкүгътән тәсбих әйтеп, каумәгә тора[1]. Каумәдә (басып торганда) тәхмид әйтә, аннары тәкбир әйтеп сәҗдәгә китә. 3 мәртәбә тәсбих әйтеп сәҗдәдән тәкбир белән тора

[1] Каумә – аз гына аягүрә тору.

һәм җәлсәгә[1] утыра. Җәлсәдән тәкбир әйтеп янә сәҗдәгә китә. Икенче сәҗдәдә дә 3 мәртәбә тәсбих әйтә. Икенче сәҗдәдән тәкбир әйтеп икенче рәкәгатьнең кыямына тора.

Икенче рәкәгатьнең кыямында «Сәнә'» һәм «Әгүүзү» укымый, кулларын баглап «Бисмилләәһ», «Фатиха» сүрәсен укый һәм «Әәмииин» әйтеп берәр сүрә[2] укый. Янә беренче рәкәгатьтәге кебек рөкүгъ, каумә, һәм ике мәртәбә сәҗдә кыла.

Икенче сәҗдәдән соң тәкбир әйтеп кәгъдәгә утыра. Кәгъдәдә булганда башта «Тәшәһһүд», аннары «Салават», соңыннан «Дога» аятен (раббәнә) укый. Шуннан башта уң тарафка, соңыннан сул тарафка сәлам бирә һәм «Сәлам» догасын укып дога кыла.

Ике рәкәгатьле намаз: иртәнге намазның ике рәкәгать сөннәте һәм ике рәкәгать фарызы, өйлә, ахшам һәм ястү намазларының икешәр рәкәгать сөннәтләре – һәрберсе шул рәвешле укыла, аермалары ниятләрендә генә.

ДҮРТ РӘКӘГАТЬЛЕ НАМАЗ УКУ РӘВЕШЕ

Дүрт рәкәгатьле намаз эчендә дүрт кыям, дүрт рөкүгъ, сигез сәҗдә һәм ике кагъдә бар.

---

1 Җәлсә – ике сәҗдә арасында утырып тору

2 Мәсәлән, «Ихлас» сүрәсен укый.

Намазның әүвәлге кагъдәсе икенче рәкәгатьнең ахырында, икенче кагъдәсе дүртенче рәкәгатьнең ахырында була. Әүвәлге кагъдәдә «Тәшәһһүд» укыгач өченче рәкәгатьнең кыямына тора. Соңгы кагъдәдә «Тәшәһһүд»тән соң «Салават» һәм «Дога» укып сәлам бирә.

Әгәр дүрт рәкәгатьле намаз өйләнең дүрт рәкәгать сөннәте кебек сөннәт намаз булса, һәр рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсеннән соң берәр сүрә укыла.

Өйлә, икенде һәм ястү намазларының дүртәр рәкәгать фарызлары кебек фарыз намаз булса, «Фатиха» сүрәсеннән соң әүвәлге ике рәкәгатендә генә берәр сүрә укыла. Соңгы ике рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсен укыгач рөкүгъка китә (ул рәкәгатьләрдә «Фатиха»дан соң янә икенче сүрәләр укымый).

Өч рәкәгатьле намазда ике кагъдә була. Беренчесе – икенче рәкәгатьнең, икенчесе – өченче рәкәгатьнең ахырында.

Өч рәкәгатьле ахшам намазы фарызының баштагы ике рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсеннән соң берәр сүрә укыла, соңгы рәкәгатендә «Фатиха»дан соң бер сүрә дә укылмый.

Өч рәкәгать витр намазының һәр рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсеннән соң берәр сүрә укыла. Өченче рәкәгатендә сүрәләр укылганнан соң, рөкүгъ кылганчы, намазга керешкәндәге кебек кулларны күтәреп тәкбир әйтелә. Аннары янә кулларны баглап «Кунүт» догасы укыла. Шуннан соң рөкүгъ, сәҗдә һәм кагъдә белән витр намазы тәмамлана.

ХАТЫННАР НАМАЗЫ

Хатыннар намазы ирләр намазыннан 8 җирдә аерыла:

1) ирләр намазга керешкәндә тәкбир әйтеп кулларын колак йомшакларына, ә хатыннар иңбашлары турысына кадәр генә күтәрәләр;

2) намазга керешер өчен кул күтәргәндә ирләрнең куллары ачык була, ә хатыннарныкы җиңнәре эчендә каплаулы була;

3) ирләр кыямда кулларын баглап кендекләре астына, ә хатыннар исә күкрәкләре өстенә куялар;

4) рөкүгъта ирләр тезләрен бөкмиләр, ә хатыннар бөгебрәк торалар;

5) рөкүгъка иелеп тезләргә таянып торганда ирләрнең кул бармаклары арасы ачык була, ә хатыннарныкы ачык булмый;

6) сәҗдә вакытында ирләр корсакларын, ботларын һәм беләкләрен намазлыкка яки кабыргаларына тидермиләр, ә хатыннар кысылыбрак сәҗдә кылалар;

7) кагъдә вакытында ирләр уң аякларын бастырып бармакларын кыйблага таба каратып куялар, ә сул аякларын яткырып аның өстенә утыралар. Хатыннар ике аякларын да уң якка чыгарып аяк башларын кыйблага таба каратып куялар, сул як очлары белән җиргә утыралар;

8) ирләр фарыз намазларын азан, камәт әйтеп, имам һәм җәмәгать белән укыйлар. Хатыннар өчен азан һәм камәт тиеш түгел, чөнки хатыннарның имам булып намазны җәмәгать белән укытулары – мәкруһ.

Шушы 8 аерымлыктан башка, хатыннарның намазы ирләрнекеннән аерылмый.

ТӘСБИХ ҺӘМ ДОГА

Намазны тәмамлаганнан соң түбәндәге зикерләр укыла:

1) سُبْحَانَ اللهِ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ وَلَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَاللهُ اَكْبَرُ

Сөбъхәәнәл-лааһи үәл-хәмдү лилләәһи үә ләә иләәһә иллә-лааһү үәл-лааһү әкбәр

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә барлык кимчелекләрдән пакь. Барча мактаулар Аллаһы Тәгаләгә генә. Бер Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк. Аллаһы һәрнәрсәдән олуграк».

2) لَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللهِ الْعَلِيِّ الْعَظِيمِ

Ләә хәүлә үә ләә ку-үәтә илләә билләәһил-гәлиййил-гәҙыйм

Мәгънәсе: «Аллаһыда булган көч һәм куәт һичбер затта юк».

3) مَا شَاءَ اللّٰهُ كَانَ وَمَا لَمْ يَشَاءْ لَمْ يَكُنْ

Мә шәә' әллааһү кәәнә үә мәә ләм йәшәә' ләм йәкүн

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә теләгән һәрбер нәрсә булыр. Аллаһы Тәгалә теләмәгән нәрсә һич булмас».

4) Аятел Көрси

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللَّهُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ لاَ تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلاَ نَوْمٌ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الأَرْضِ مَن ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلاَّ بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ وَلاَ يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِّنْ عِلْمِهِ إِلاَّ بِمَا شَآءَ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمَاوَاتِ وَالأَرْضَ وَلاَ يَؤُودُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ

Әгүүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әллааһү ләә иләәһә иллә һү-үәл-хәййүл-каййүүм. Ләә тә'хуҙуһүү синәтү-үә ләә нәүүм. Ләһү мәә фис-сәмәәүәәти үә мәә фил-әрдъ. Мәң ҙәл-ләҙии йәшфәгү гиңдәһү илләә би'иҙниһ. Йәгләмү мәә бәйнә әйдииһим үә мәә хальфәһүм. Үә ләә йүхиитуунә бишәй'им-мин гилмиһии илләә бимәә шәәъ. Үәсигә күрсиййүһүс-

сәмәәүәәти үәл-әрд. Үә ләә йә'удуһү хифҙуһүмәә. Үә һүәл-гәлийййүл-гәҙыйм

Мәгънәсе: «Аллаһының Үзеннән башка Илаһи кодрәткә ия һәм тәңре булырдай һичберкем юк. Ул – Аллаһы (мәңге) тере, һаман халык белән идарә итеп торучы. Аның йоклау сыйфаты юк. Күкләрдәге һәм Җирдәге бөтен нәрсә Аныкы гына. Аллаһының рөхсәте булмаганда беркем дә шәфәгать (яклау) кыла алмый. Ул Үзе яралтканнарның алда ни күрәчәген, үткәндә ни күргәннәренең (кылганын, кылмаганын, кылачагын, белгәнен, белмәгәнен, яшергәнен, яшермәгәнен) барысын да белеп тора. Кешеләр аның гыйлеменнән башка үзбелдекләре белән берни эшли алмас. Аның көрсие Күкләрне һәм Җирне үз эченә алган. Аллаһыга Күкләрне, Җирне саклап тору һич тә кыен түгел. Аллаһы гаять бөек, галәмәт тә олуг» («Әл-Бәкара /Сыер/», 2:255).

Шушы зикерләр һәм аятьләр укылганнан соң 33 мәртәбә «Сөбханаллаһ», 33 мәртәбә «Әлхәмдүлилләһ» һәм 33 мәртәбә «Аллаһу әкбәр» дип әйтелә. Аннан кулларны күкрәккә кадәр күтәреп түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ تَقَبَّلْ مِنَّا صَلَاتَنَا وَصِيَامَنَا وَقِيَامَنَا وَقِرَأَتَنَا وَرُكُوعَنَا وَسُجُودَنَا وَقُعُودَنَا وَتَسْبِيحَنَا وَتَهْلِيلَنَا وَتَخَشُّعَنَا وَتَضَرُّعَنَا

اَللَّهُمَّ تَمِّمْ تَقْصِيرَنَا وَتَقَبَّلْ تَمَامَنَا وَاسْتَجِبْ دُعَائَنَا وَاغْفِرْ أَحْيَائَنَا وَارْحَمْ مَوْتَانَا يَا مَوْلَانَا

اَللَّهُمَّ احْفَظْنَا يَا فَيَّاضُ مِنْ جَمِيعِ الْبَلَايَا وَالْأَمْرَاضِ

اَللَّهُمَّ تَقَبَّلْ مِنَّا هَذِهِ الصَّلَاةُ (الفرض مع السنة) مَعَ جَمِيعِ نُقْصَانَاتِهَا بِفَضْلِكَ وَكَرَمِكَ وَلَا تَضْرِبْ بِهَا وُجُوهَنَا يَا إِلَهَ الْعَالَمِينَ وَيَا خَيْرُ النَّاصِرِينَ تَوَفَّنَا مُسْلِيمِينَ وَ اَلْحِقْنَا بِالصَّالِحِينَ

وَصَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَى خَيْرِ خَلْقِهِ مُحَمَّدٍ

وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ أَجْمَعِينَ

Әллаһүммә тәкаббәл миннә саләәтәнәә үә сийәәмәнәә үә кыйәәмәнәә үә кыйра’әәтәнәә үә рукүүгәнәә үә сүҗүүдәнә үә кугүүдәнәә үә тәсбиихәнәә үә тәхлииләнәә үә тәхашшүгәнәә үә тәдаррүгәнәә. Әллааһүммә тәммим тәкъсыйранәә үә тәкаббәл тәмәәмәнәә үәс-тәҗиб дугәә’әнәә үәгъфир әхйәә’әнәә үәрхәм мәүтәәнәә йәә мәүләәнәә. Әллааһүммәх-фәҙнәә йә әфәййәду мин җәмиигил-бәләәйә үәл-әмраадъ. Әллааһүммә тәкаббәл миннәә һәәҙиһис-саләәтү (әл-фәрда мәгәс-сүннәти) мәгә җәмииги нүкъсаанәәтиһәә бифәдъликә үә кәрамикә үә ләә тәдъриб биһәә вүҗүүһәнәә йәә иләәһәл-гәәләмиинә үә йәә хайран-нәәсыриин. Тәүәффәнәә мүслимиин үә әлхикънәә бис-саалихиин. Үә сал-лалЛааһү тәгәәлә гәләә хайри халкыһии Мүхәммәдин үә гәләә әәлиһии үә әсхәәбиһии әҗмәгиин

Мәгънәсе: «Йә Рабби, безнең намазларыбызны, уразаларыбызны, кыямыбызны, рөкүгебезне, сәҗдәбезне, кагъдәбезне, тәсбихебезне, тәһлилебезне, тыйнычлыгыбызны һәм ялваруыбызны кабул кыл. Йә Рабби, кимчелекләр белән кылынган гамәлләребезне камилләштер, тәмам булган гамәлләребезне, догабызны кабул кыл. Әй Хуҗабыз, тере булучыларны ярлыка һәм үлгәннәргә рәхмәтеңне ирештер. Әй рәхмәт кылучы Аллаһы, Үз камиллегең һәм юмартлыгың белән бездән ошбу намазыбызны һәрбер кимчелекләре белән кабул кыл. Ул намазларыбызны йөзләребезгә ыргытма. Әй бөтен галәмнәрнең Раббысы һәм ярдәм итүчеләрнең иң камилрәге, безне мөселман хәлебездә вафат кыл һәм изге кешеләр белән бергә ит. Мәхлукларның иң яхшырагы Мөхәммәд ﷺ гә, аның әһленә (гаиләсенә), барлык сәхабәләренә рәхмәтеңне бирсәң иде».

ЗӘГЫЙФЬ КЕШЕНЕН НАМАЗЫ

1) Авыру яки картлык сәбәпле аягүрә торып (кыямда торып) укырга көче җитмәгән кеше намазын утырып укый. Утырган килеш кулларын баглап «Фатиха» һәм аннан соң укыла торган сүрәне укыгач, рөкүгъне бераз иелеп, тезенә таянып кыла. Сәҗдәне сәламәт вакытындагы кебек кыла.

2) Әгәр гәүдәсе белән иелеп рөкүгъ һәм сәҗдә кыла алмаса, әлеге гамәлне ишарә белән кыла: башын рөкүгъ өчен азрак, сәҗдә өчен күбрәк ия.

3) Утырып торырга көче җитмәсә, аякларын кыйбла ягына сузып, чалкан ятып, рөкүгъ һәм сәҗдәсен башы белән ишарәләп уку да дөрес була.

4) Әгәр башын кузгатырга да көче җитмәсә, намазларын укымый, ә сәламәтләнгәч калган намазларын каза кылыр.

5) Бара торган көймәдә фарыз намазны сәламәт килеш тә утырып уку дөрес була, әмма туктаган көймәдә һәм җир өстендә сәламәт килеш намазны утырып уку дөрес түгел.

6) Сөннәт һәм нәфел намазларны һәр җирдә гозерсез дә утырып укырга ярый.

7) Сөннәт һәм нәфел намазларны атка атланган килеш тә уку дөрес була. Бик җитди сәбәп булмаганда фарыз намазларны ат өстендә уку дөрес саналмый. Ә дошманнан йә ерткыч хайваннан курку сәбәпле фарыз намазны ат өстендә уку дөрес була.

8) Коръән укый белмәгән надан кешегә намаз укыр өчен җитәрлек берничә сүрә өйрәнү фарыз булган кебек, Коръәннең кайбер хәрефләрен ялгыш әйтә торган сакау кешегә дә хәрефләрне дөрес әйтергә тырышу фарыз.

9) Тырышып та, намазда вәҗиб (тиешле) булган кадәр Коръәнне дөрес укый алмаган кешеләр намазның фарызларын имамга оеп укырга тиешләр. Ялгыз укыганда һәр рәкәгатьтә белгән аятьләрне кабатлап укырга кирәк.

10) Бик надан һәм бик сакау кешеләрнең намазда имам булулары дөрес түгел.

11) Бер тәүлек, ягъни 24 сәгать кадәр тилереп йә һушсыз булып яткан кешегә укылмый калган намазларын сәламәтләнгәч каза кылу фарыз була.

12) Бер тәүлектән артык һушсыз булып яткан кешегә шул вакытта калган намазларын каза кылу фарыз түгел.

НАМАЗНЫҢ ШАРТЛАРЫ

Намазның шартлары, ягъни тышындагы фарызлары сигез:

1) وضؤ вудү' – тәһарәтле булу;

2) طهرات بدن тәһарәт бәдән – тән пакь булу;

3) طهرات ثوب тәһарәт сәүб – кием пакь булу;

4) طهرات ثوب тәһарәт сәүб – кием пакь булу;

5) ستر عورت сәтр гаүрәт – гаурәт җирләре капланган булу;

6) دخول وقت духуль уакт – намазның вакыты керү;

7) استقبال قبلة истикъбәл кыйблә – кыйблага каршы карау;

8) نيت بالقلب ниййәт бил-кальб – күңел белән намазны ният кылу.

НАМАЗНЫҢ РӨКЕННӘРЕ

(ЭЧЕНДӘГЕ ФАРЫЗЛАРЫ)

Намазның рөкеннәре, ягъни эчендәге фарызлары да сигез:

1) تكبير **тәкбир** – намазга керешкәндә «Аллаһу әкбәр» дип әйтү;

2) قيام **кыям** – өч аять уку вакыты күләмендә аягүрә тору;

3) قيرائت **кыйра’әт** – кыямда өч аять чамасы Коръән уку;

4) ركوع **рөкүгъ** – кыямнан соң иелү (бөгелү), ягъни рөкугъ кылу;

5) سجود **сүҗүд** – маңгайны җиргә (намазлыкка) тидереп ике мәртәбә сәҗдә кылу;

6) قعود **кугүд** – намазның ахырында кагъдәгә утыру;

7) ترتيب **тәртиб** – намазның рөкеннәрен тәртип буенча үтәү;

8) خروج **хурүҗ** – намаздан үз ихтыярың белән чыгу.

НАМАЗНЫҢ ВӘҖИБЛӘРЕ

Намазның мәшһүр вәҗибләре унбиш:

1) قيرائت فاتحة **кыйра’әт фатиха** – фарыз намазларның әүвәлге ике рәкәгатендә, витр, сөннәт һәм нәфел намазларның һәр рәкәгатендә бер мәртәбә «Фатиха» сүрәсен уку;

2) ضم سورة дамм сүрәһ – алда әйтелгән рәкәгатьләрдә «Фатиха» сүрәсеннән соң бер сүрә йә өч аять кадәр Коръән уку;

3) طمانينة туманинәһ – рөкүгътә һәм сәҗдәдә бер тәсбих әйтерлек вакыт булу;

4) قومة каүмә – рөкүгътән торгач аяк өстендә туры тору;

5) جلسة җәлсә – ике сәҗдә арасында утырып тору;

6) قعدة أولى кагъдә үлә – өч-дүрт рәкәгатьле намазларда икенче рәкәгатьнең ахырында кагъдәгә утыру;

7) تشهد тәшәһһүд – һәр кагъдәдә «Тәшәһһүд» уку;

8) سلام сәлам – намаздан чыкканда сәлам бирү;

9) موالات муүәләт – намазның бер гамәле тәмамлангач, аның артыннан килә торган гамәлне тиз (кичектерми) үти башлау;

10) جهر җәһр – иртәнге, ахшам, ястү намазларының әүвәлге ике рәкәгатьләрендә имам булучыга сүрәләрне кычкырып уку;

11) إخفا ихфә – башка рәкәгатьләрдә имамга да, ялгыз укучыга да сүрәләрне эчтән уку;

12) إنصات инсат – имам сүрәләрне укыган вакытта моктәдигә (имамга оючыга) тик тору;

13) تكبيرات عيد тәкбират гыйд – гает (бәйрәм) намазларының һәр рәкәгатендә өчәр мәртәбә тәкбир әйтү;

14) قنوت кунүт – витр намазының өченче рәкәгатендә «Кунүт» догасын уку;

15) سجداء سهو сәҗдәи сәһү – ялгышканда (хата җибәргәндә) намазның ахырында сәҗдәи сәһү кылу.

НАМАЗНЫҢ СӨННӘТЛӘРЕ

Намазның мәшһүр сөннәтләре егерме биш:

1) جماعت җәмәгать – фарыз намазны җәмәгать белән уку;

2) أذان азан – фарыз намазлар өчен азан әйтү;

3) إقامت икамәт – фарыз намазларны укыр алдыннан камәт әйтү;

4) رفع يدين рафг йәдәйн – намазга керешкәндә тәкбир әйтеп кулларны күтәрү (ирләр колакларына, ә хатын-кызлар иңбашларына кадәр күтәрәләр);

5) ضم يدين дамм йәдәйн – кыям вакытында кулларны баглау;

6) ثناء сәнә' – әүвәлге рәкәгатьтә «Сәнә» уку;

7) تعوذ тәгәүүз – әүвәлге рәкәгатьтә «Әгүүзү» әйтү;

8) بسمله бәсмәлә – «Фатиха» сүрәсен укыганчы «Бисмилләәһ» әйтү;

9) تأمين тәъмин – «Фатиха» сүрәсен укыгач эчтән генә «Әәмииин» дип әйтү;

10) تكبيرات انتقالات тәкбират интикаләт – рөкүгъкә, сәждәгә киткәндә, сәждәдән торганда тәкбир әйтү;

11) ركوع مسنون рөкүгъ мәснүн – рөкүгъне сөннәт буенча башкару (рөкүгъ вакытында бармакларны ачып тезләргә таянып тору, тезләр бөгелмичә, баш арка белән тигез булырга тиеш);

12) سجود مسنون сүҗүд мәснүн – сәҗдәне сөннәт буенча башкару (сәҗдә вакытында аяклар, куллар, борын һәм маңгай җиргә тиеп, баш ике кулның арасында булырга, беләкләр җиргә дә, кабыргага да тимичә һәм корсак ботларга тимичә торырга тиеш);

13) قعود مسنون кугүд мәснүн – кагъдәне сөннәт буенча башкару (кагъдә вакытында сул аяк өстенә утыру, уң аяк бармакларын бастырып кую, кулларны ботларга кую);

14) تسبيح ركوع тәсбих рөкүгъ – рөкүгътә өч мәртәбә тәсбих әйтү;

15) تسبيح سجود тәсбих сүҗүд – сәҗдәдә өч мәртәбә тәсбих әйтү;

16) تسميع тәсмигъ – рөкүгътән торгач, имамга һәм ялгыз укучыга тәсмигъ әйтү;

17) تحميد тәхмид – каумә вакытында ялгыз укучыга һәм моктәдигә (имамга оючыга) тәхмид әйтү;

18) صلوات салауат – ахыргы кагъдәдә «Тәшәһһүд»тән соң «Салават» уку;

19) دعاء дуга' – ахыргы кагъдәдә «Салават»тан соң аятькә охшашлы бер дога уку;

20) تقرار سلام тәкрар сәлам – уң һәм сул якка сәлам бирү;

21) نيت سلام ниййәт сәлам – уң һәм сул якта булган фәрештәләргә һәм бергә намаз укучыларга сәлам бирүне ният кылу;

22) جهر أذكار җәһр әзкәр – имамга тәкбирне, тәсбихне һәм сәламне кычкырып әйтү;

23) إخفا أذكار ихфә әзкәр – башка зикерләрне эчтән әйтү (моктәди һәм ялгыз укучы һәрбер зикерне эчтән әйтә);

24) تقديم ركبة тәкъдим рүкбә – сәҗдәгә киткәндә тезләрне куллардан элегрәк кую;

25) مقارنة إمام мүкаранә имәм – моктәдигә һәр гамәлне имам белән бергәрәк башкарырга тырышу (имамнан алданрак башкарырга ярамый, имамнан күпкә соңга калу – мәкруһ).

НАМАЗНЫҢ МӨСТӘХӘБЛӘРЕ

Намазның мөстәхәбләре егерме:

1) намазга керешер өчен кул күтәргәндә бармак араларының ачыграк булуы;

2) баш бармакларның битләрен колак йомшакларына тидерү;

3) ирләрнең куллары җиңнәреннән чыккан булуы (хатыннарның куллары җиңнәре эчендә булу – мөстәхәб);

4) кыям вакытында үкчәләрнең дүрт бармак киңлегендә бер-берсеннән ерак булуы;

5) кул баглаганда, сул кулының беләзеген уң кулның баш һәм чәнчә бармаклары белән чорнап алып, уртадагы өч бармакны беләккә таба сузу;

6) намазда укылган сүрәләрне һәм зикерләрне тәҗвид белән дөрес итеп уку;

7) иртәнге намазда «Фатиха» сүрәсеннән соң озынрак, өйлә, икенде һәм ястү намазларында уртача, ахшам намазында кыска сүрәләрне уку[1];

8) әүвәлге рәкәгатьтә озынрак сүрә, соңгы рәкәгатьләрдә кыскарак сүрә уку;

9) сәҗдәдә баш бармакларның колаклар турысында булуы;

---

[1] Коръәни-Кәримдә «Буруҗ» («Йолдызлар») сүрәсенә кадәр булган сүрәләр озын, ә «Буруҗ» сүрәсеннән башлап «Бәләд» («Шәһәр») сүрәсенә кадәр булган сүрәләр уртача, ә аннан соңгы сүрәләр кыска булып санала *(Кәрмани)*.

10) сәҗдәдә кул бармакларының бер-берсенә тиеп торуы;

11) сәҗдәдә аяк башлары җиргә тиеп, үкчәләре югары торуы;

12) сәҗдәдә кул һәм аяк бармакларының кыйблага таба сузылып торуы;

13) кагъдәдә кул бармакларын бер-берсенә якынрак китереп ботларга кую;

14) рөкугъ һәм сәҗдә тәсбихләрен так итеп, өчтән артык әйтү (5, 7, 9);

15) өч һәм дүрт рәкәгатьле фарыз намазларның соңгы рәкәгатьләрендә «Фатиха» сүрәсен уку (сөннәт, вәҗиб, нәфел намазларының һәр рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсен һәм аннан соң янә бер сүрә уку вәҗиб);

16) кыямда сәҗдә урынына, рөкүгътә аяк башларына, сәҗдәдә борын очына, кагъдәдә үз алдыңа, сәлам биргәндә иңбашларга гына карап тору;

17) намаз эчендә йөткермәскә һәм иснәмәскә тырышу;

18) ихтыярсыз иснәгәндә авызны бер кул белән каплау;

19) намазны түбәнчелек һәм буйсынган кыяфәттә уку;

20) намаз ахырында сәлам биргәндә арттагы кешегә яңагы күренерлек кадәр башын бору.

НАМАЗНЫҢ МӘКРУҺЛАРЫ

Намазда мәкруһ булган эшләрнең мәшһүрләре сиксән:

1) үз ихтыярың белән намазда сөннәт булган бер гамәлне үтәмәү (вәҗиб гамәлне үтәмәү – хәрам, фарызны үтәми калдыру намазны боза);

2) намазда тәкәбберлек кыяфәте белән тору;

3) үз ихтыярың белән иснәү;

4) сәбәпсез йөткерү;

5) сәбәпсез тамак кыру;

6) сәбәпсез борын сеңгерү;

7) сәбәпсез төкерү, какыру;

8) сәбәпсез уфылдау;

9) сәбәпсез кикерү;

10) билгә таяну;

11) гәүдәне бер тарафка авыштырып кыек тору;

12) бер аякка салынып ял итү;

13) кул белән берәр нәрсә тотып тору;

14) кулны йә күлмәкне селкеп җилләнү;

15) бер кул белән башка бүрек йә чалма кию;

16) бүрекне салу (ике кул белән бер эшне кылу намазны боза);

17) сәҗдә урынындагы туфракны сөртү;

18) йөздәге тирне яки тузанны сөртү (авырттырырлык ташлар булганда маңгайны селкеп, бер-ике мәртәбә сыпырырга ярый);

19) бер-ике мәртәбә бер үк җирне кашу (өч мәртәбә кашу намазны боза);

20) сәбәпсез намаз укый торган урыннан бер-ике адым читкә күчү (берьюлы өч адым атлау намазны боза);

21) теш арасыннан чыккан ризык валчыгын йоту (борчак зурлыгындагы валчык йоту намазны боза);

22) йөзне кыйбладан авыштыру;

23) югарыга таба карау;

24) кыямга торып басканда җиргә (намазлыкка) таянып тору;

25) берәр нәрсәгә таянып тору;

26) рөкүгътә башны бик түбән иеп яки бик югары күтәреп тору;

27) сәҗдәдә аяк һәм кул бармакларын җирдән (намазлыктан) күтәрү;

28) сәҗдәдә беләкләрне җиргә йә кабыргаларга тидереп тору;

29) сәҗдәдә корсакны ботларга тидереп тору (сафта урын тыгыз булганда, бу эш мәкруһ саналмый);

30) кием йә кул белән уйнау;

31) намазны яланбаш уку;

32) җиңнәрне сызган килеш уку;

33) күкрәкләр йә аркалар ачык килеш уку;

34) киемне уртасыннан эләктермичә, җилләтеп, селкеп уку;

35) авызга нәрсә дә булса кабып уку;

36) үз ихтыярың белән нәрсәне дә булса иснәү;

37) бүреккә йә чалмага сәҗдә кылу (намаз укучы сәҗдә кылганда маңгае җиргә яисә намазлыкка тимәү);

38) чәчне төреп бәйләгән килеш уку;

39) киемдә, намазлыкта яки әйләнә-тирәдә хайван сурәте булу (әгәр сурәт артта йә чебен зурлыгы кадәр генә кечкенә яки башы бозылган булса – зарары юк);

40) намазны яна торган зур утка каршы уку;

41) башка кешенең йөзенә карап уку;

42) йөз күренерлек көзгегә карап уку;

43) нәҗес нәрсәгә карап уку;

44) кабергә карап уку (шәм, яктырткыч һәм лампа кебек утларга каршы торып уку мәкруһ түгел);

45) алда урын була торып, фарыз намазны арттагы сафта уку;

46) намазны күзләрне йомган килеш уку;

47) тәһарәте кысталган килеш намазга керешү;

48) намазны алъяпкыч кебек буялган кием белән уку;

49) кыямда ике үкчәне бер-берсенә дүрт бармак киңлегеннән дә якын китерү;

50) намазны бик ашыгып уку;

51) кагъдәдә куллар белән җиргә таянып тору;

52) кагъдәдә ике үкчә өстенә утыру;

53) кагъдәдә аякларны бөкләп утыру;

54) рөкүгъ һәм сәҗдәгә барганда киемне тоткалау;

55) тәкбир һәм зикерләрне яки сүрәләрне икешәр кат уку;

56) укыган зикерләрне бармак белән санау;

57) зикерләрне үз урыннарында укып бетермичә икенче урында уку;

58) бер сүрәне бер намазда ике мәртәбә уку;

59) соңгы рәкәгатьтә беренче рәкәгатьтә укыган сүрә алдындагы сүрәне уку;

60) икенче рәкәгатьтә беренче рәкәгатьтә укылган сүрәдән соң килгән сүрәне укымыйча, аннан соңгы сүрәне уку (әгәр арада ике сүрә калса мәкруһ түгел);

61) мәгънәсен уйлап бер аятьне ике кат уку;

62) бер аятьнең мәгънәсен уйлап туктап тору;

63) дөнья эшләрен искә төшереп елмаю;

64) дөнья эшләрен искә төшереп тавышсыз елау;

65) намазның бер гамәлен имамнан алдарак башкару;

66) имамның оючылардан югарырак йә түбәнрәк урында укуы;

67) имамның михрабның эченә тулысынча кереп укуы;

68) имамның намазны халык зарыгырлык озак укуы;

69) ир белән хатынның янәшә укуы;

70) имам булуы мәкруһ булган кешегә оеп уку;

71) тамак кырып йә ухылдап авыздан бер-ике аваз тавыш чыгару;

72) намаз вакытында чалманы салу яки баштан төшеп киткән очракта аны алып кию;

73) намаз вакытында күңел белән бер нәрсәнең санын хисаплау;

74) намаз сүзләреннән башка нәрсәләрне уку;

75) намаз вакытында бармак белән хәрәкәт ясау;

76) намаз вакытында бармак белән ничә рәкәгать укыганны күрсәтеп бару;

77) намаз вакытында баш йә каш белән ишарә итеп янындагы кешегә нәрсә дә булса аңлату;

78) ишарә белән бер сүзгә җавап бирү;

79) тамак кырып яисә чырайны бозып янындагы кешегә нәрсә дә булса аңлату;

80) бер-ике мәртәбә бармак шартлату.

НАМАЗНЫҢ МӨФСИДЛӘРЕ

(НАМАЗНЫ БОЗУЧЫ НӘРСӘЛӘР)

Намазны түбәндәге 20 төрле эш боза:

1) тамак кырып яки ухылдап авыздан өч авазлы тавыш чыгару;

2) мәгънәле бер сүз әйтү (намаздагы зикерләрдән башка);

3) бер кешегә сәлам бирү яки сәлам алу;

4) дөнья эшен сорап дога кылу;

5) дөнья эшен уйлап тавыш чыгарып көлү;

6) дөнья эшен уйлап тавыш чыгарып елау;

7) борчак зурлыгындагы нәрсәне дә булса йоту;

8) бер тамчы чамасы су йоту;

9) гадәттә ике кул белән башкарыла торган берәр гамәлне башкару (мәсәлән, киемне кию яки салу, ниндидер зур нәрсәне күтәрү һ. б.);

10) нинди дә булса гамәлне берьюлы өч мәртәбә башкару (мәсәлән, 3 мәртәбә битне сөртү, 3 мәртәбә бер җирне кашу, 3 мәртәбә мыекны төзәтү, 3 мәртәбә бармак

шартлату, 3 мәртәбә төймәне эләктерү йә ычкындыру, берьюлы 3 адым атлау, 3 мәртәбә бер нәрсәне чәйнәү, бер авазны 3 мәртәбә әйтү һ. б.);

11) сүрәләрне Коръәнгә карап уку;

12) Коръән сүрәсенең мәгънәсе бозылырлык итеп хата белән уку;

13) моктәдинең (имамга оючы) имамнан алдарак торуы;

14) җәмәгать намазында ир белән хатынның бер сафта булуы;

15) иртәнге намазны укыганда кояш чыга башлау;

16) гаурәтнең дүрттән бер өлеше ачылып китү;

17) намазда фарыз булган бер гамәлне үтәми калдыру;

18) күкрәкнең кыйбла тарафыннан авышуы;

19) тәннең, киемнең йә намазлыкның нәҗесләнүе;

20) үз ихтыярың белән тәһарәтне бозу.

НАМАЗДА МӨБАХ БУЛГАН (РӨХСӘТ ИТЕЛГӘН) ЭШЛӘР

1) Ирексездән йөткерү һәм төчкерү вакытында авыздан берничә аваз чыгу, нәҗескә тиюдән куркып яки башка катгый сәбәп аркасында өч адым атлау һәм икенде укыган вакытта кояш баю аркасында намаз бозылмый.

2) Намаз укыган вакытта елан чагу ихтималы булса, намазны бозмыйча, аны үтерү рөхсәт ителә. Урыннан кузгалып еланны юк итү өчен таяк алып килгәндә, күкрәк кыйбла тарафыннан авышса да, намаз бозылмый. Еланны үтергәч, туктап калган урыннан намазны дәвам итеп укып бетерергә кирәк.

3) Намаз укучы алдыннан, аның күзе төшәрлек җирдән узып китү – мәкруһ. Намаз укучы алдыннан берәү узып китә башласа, аңа намазда икәнлекне белдерү өчен бер мәртәбә тамак кыру яки бер тапкыр «Сөбханаллаһ» дип әйтү рөхсәт ителә.

4) Намаз укучы алдыннан узучылар гөнаһлы булмасыннар өчен пәрдә кору – сөннәт. Бер аршын озынлыгы һәм бер бармак киңлеге булган таяк та пәрдә өчен ярый, аннан ким булса – ярамый. Намаз укытучы имам алдында пәрдә булса, аңа оеп укучылар өчен пәрдә кую кирәкми.

5) Имам намазда ялгыша башласа, аңа оеп укучылар тамак кырып яки «Сөбханаллаһ» дип әйтеп, ялгышканлыгын имамга аңлатырга тиешләр.

6) Намаз укыганда ихтыярсыз тәһарәте бозылган кешегә, намазын бозмыйча, тәһарәт яңарту тиешле, ләкин бу вакытта сөйләшергә һәм нинди дә булса эш башкарырга ярамый. Тәһарәт алу өчен су янына баруыннан, кыйбла тарафыннан авышуыннан аның намазы бозылмый. Тәһарәт алгач, намаз укыган җиргә кире килеп яки тәһарәт алган урында кыйблага карап, намазның калган өлешен укып бетерергә кирәк.

7) Имам булган кешенең тәһәрате бозылган очракта, аңа артында оеп укый торган бер кешене янына тартып

китерергә һәм үзе урынына имам булып укытырга ишарә итәргә кирәк. Шуннан соң гына ул тәһарәт яңартырга чыгып китә ала. Имамны алыштырган кеше калган рөкеннәрне укытып намазны тәмамлый. Әүвәлге имам тәһарәт яңарткач намазын ялгыз гына (бер үзе укыгандагы кебек) тәмамлый.

Намазның башка хөкемнәре һәм төрле намазларның уку рәвешләре бу бүлектән соңгы «Җәмәгать» исемле бүлектә тәфсилләп аңлатылачак.

Шушы урында хөрмәтле Әхмәдһади Максуди хезмәтенең «Намаз» бүлеге тәмамлана.

ҖӘМӘГАТЬ

Хәдис-шәриф

صَلَاةُ الْجَمَاعَةِ أَفْضَلُ مِنْ صَلَاةِ الْفَذِّ بِسَبْعٍ وَعِشْرِينَ دَرَجَةً

Саләәтүл-җәмәәгәти әфдалү мин саләәтил-фәҙҙи бисәбгиү-үә гишриинә дәраҗәһ

Мәгънәсе: «Намазны имам һәм җәмәгать белән уку ялгыз укудан егерме җиде дәрәҗәгә артыграк».

1) Фарыз намазларны имам һәм моктәди (имамга оючы) булып җәмәгать белән уку – сөннәт.

2) Җәмәгать намазында имам баш булып укыта. Моктәди имамга оеп, ягъни ияреп укый, намазның һәр өлешен имам артыннан гына үти, һичбер гамәлне аннан алда башкармый.

3) Кыямда торганда моктәди «Сәнә» генә укый, «Әгүүзү», «Бисмилләәһ»не әйтми һәм сүрәләрне укымый. Имам укыганны көтеп һәм тыңлап тик тора. Рөкүгътән тураеп торганда имам тәсмигъ әйтә, тәхмид әйтми, ә моктәди тәхмид әйтә, тәсмигъ әйтми. Башка зикерләрнең һәрберсен имам да, моктәди дә укый.

4) Имам тәкбирләрне, тәсмигъне һәм сәламне кычкырып әйтә. Моктәди һәр зикерне эчтән генә укый. «Фатиха» сүрәсе кычкырып укылса, моктәди сүрәдән соң эчтән генә «Әмин» ди.

5) Оючы бер генә кеше булса, моктәди имамның уң ягыннан бер карыш кадәр генә арттарак баса. Ике йә өч

кеше булганда, оючылар барысы да имамнан арттагы сафта (рәт) укыйлар. Сафны тигез итү һәм арада кеше сыярлык буш урын калдырмыйча тезелү – сөннәт.

6) Ир кешегә сабый балага һәм хатын-кызга оеп намаз уку дөрес түгел. Сабыйларның һәм хатыннарның ир имамга оеп укулары дөрес.

7) Имамга ирләр, сабыйлар һәм хатыннар бергә оесалар, беренче сафта ирләр, икенчесендә – сабыйлар һәм өченчесендә – хатыннар тезелеп укырга тиеш.

8) Арадан берсе имам булып җәмәгать белән уку сабыйларга ярый, хатын-кызларга ярамый.

9) Гозерсез кешегә «сахибе гозер»гә[1], икенде намазын укучының өйләне каза кылучыга, нәфел намазын укучының фарыз намазын укучыга оюы дөрес түгел.

10) Нәфел намазын укучының өйлә һәм ястү намазларын укучыга оеп укуы – дөрес; иртәнге, икенде һәм ахшам намазларын укучыга оеп укуы – мәкруһ.

11) Берничә кеше бер намазны җәмәгать белән укырга теләсә, арада галимрәге имам була. Галимлекләре бер дәрәҗәдә булса, кыйраәте дөресрәге имам була, кыйраәтләре бер дәрәҗәдә булса, тәкъварагы имам була. Тәкъвалыклары дә бер дәрәҗәдә булса, иң олы яшьтәгесе имам була. Яшьләре дә тигез булса, яхшырак холыклысы имам була. Холыклары да бер дәрәҗәдә булса, күркәмрәк кыяфәтлесе имам була.

12) Бик надан, фасикъ (начар юлда йөргән, азгын), ике күзе дә сукыр һәм сакау кешенең имам булуы – мәкруһ.

---

[1] «Сахибе гозер» турында «Тәһарәт» бүлегендә аңлатылды.

13) Имам иртәнге намазның һәр ике рәкәгатендә, ахшам һәм ястү намазларының беренче ике рәкәгатендә сүрәләрне кычкырып укый, башка намазларда эчтән генә укый.

14) Ялгыз укучы һәр рәкәгатьтә сүрәләрне эчтән генә укый. Ялгыз укыганда, имам кычкырып укый торган рәкәгатьләрне кычкырып укырга да ярый.

МӨДРИК ҺӘМ МӘСБҮК

(ҖӘМӘГАТЬ НАМАЗЫНА ВАКЫТЫНДА ӨЛГЕРҮЧЕ ҺӘМ СОҢГА КАЛУЧЫ)

1) Имам намазны укый башлаган булса, соңга калып килүченең тиз арада имамга оеп, намазга керешеп китүе – вәҗиб. Хәтта имам ахыргы кагъдәдә булса да, аңа оеп калу – саваплы.

2) Имам кыямда кычкырып сүрә укыган вакытта килеп оеган кеше «Сәнә»не укымый, эчтән укыган вакытта килеп оеган кеше генә укый. Кыямнан башка гамәл вакытында оеган кеше дә «Сәнә»не укымый.

3) Имам бер рәкәгатьнең рөкүгендә булган вакытта килеп оеп, имам торганчы рөкүгъкә иелеп өлгергән кеше, шул рәкәгатькә җитешкән булып санала. Имам рөкүгътән торгач, кыямда, сәҗдәдә яки кагъдә вакытында оеган кеше ул рәкәгатькә өлгергән булып саналмый.

4) Имамның әүвәлге рәкәгатенә өлгергән кеше «мөдрик» дип атала. Беренче рәкәгатенә җитешмәгән кеше «мәсбүк» дип атала.

5) Мәсбук ахыргы кагъдәдә «Тәшәһһүд» укый, «Салават» һәм «Дога» укымый. Имам ике тарафка да сәлам биргәнче көтеп тик тора, имам сәлам биргәч, кыямга торып, «Сәнә», «Әгүүзү», «Бисмилләәһ» һәм сүрәләр укып, калган рәкәгатьләрне каза кыла.

6) Беренче рәкәгатькә өлгермәгән кеше имамнан соң бер рәкәгать каза кыла. Дүрт рәкәгатьле намазның ике рәкәгатенә өлгермәгән кеше имамнан соң ике рәкәгать каза кыла. Беренче рәкәгатендә кагъдәгә утырмый, һәр ике рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсеннән соң берәр сүрә укый.

7) Дүрт рәкәгатьле намазның өч рәкәгатенә өлгермичә, соңгысына гына өлгереп җәмәгатькә килеп кушылган кеше имамга оеп, аның белән бергә соңгы рәкәгатьне укый. Кәгъдәгә утыргач «Тәшәһһүд»не генә укый («Салават»ны укымый). Имам сул тарафына сәлам бирә башлаганнан соң ул кеше сәлам бирмичә аягурә тора һәм калган өч рәкәгать намазын ялгызы гына укуын дәвам итә. Торып баскач беренче рәкәгатендә «Сәнә» догасын, «Әл-Фатиха» сүрәсен һәм аннан соң бер сүрә укый да янә кәгъдәгә утыра. Аннан соң калган ике рәкәгатен тоташтан укыгач, ахыргы кәгъдәгә утырып, «Тәшәһһүд», «Салават», «Дога» укый һәм сәлам биреп намазын тәмамлый. Имамнан соң ялгызы укып дәвам иткән беренче ике рәкәгатендә «Әл-Фатиха» сүрәсеннән соң берәр сүрә укый. Соңгы рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсен генә укый.

8) Ахшам кебек өч рәкәгатьле намазның ахыргы рәкәгатенә генә өлгергән кеше имамнан соң каза кылган ике рәкәгатенең һәр икесендә дә кагъдәгә утыра. Һәр ике рәкәгатендә дә «Фатиха» сүрәсеннән соң берәр сүрә укый.

9) Имамның һичбер рәкәгатенә өлгермичә намазның ахырына гына оеп калган кеше имамнан соң намазын ялгыз укыган кеше кебек укый.

МӘЧЕТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ

Фарыз намазларны мәчеттә җәмәгать белән уку – сөннәт. Өйдә җәмәгать булып укылган намазда җәмәгать савабы бар, мәчет савабы юк.

Мәчеткә кергәндә уң аяктан атлап керү һәм түбәндәге доганы уку мөстәхәб:

اَللَّهُمَّ افْتَحْ لِي أَبْوَابَ رَحْمَتِكَ وَانْشُرْ عَلَيَّ خَزَائِنَ رَحْمَتِكَ

Әллааһүммә-фтәх лии әб-үәәбә рахмәтикә үән-шүр гәләййә хазәәинә рахмәтик

Мәгънәсе: «Йә Рабби, миңа Рәхмәт ишекләреңне ач һәм Рәхмәт хәзинәләреңне чәч».

Мәчеттән чыкканда сул аяктан атлап чыгу һәм түбәндәге доганы уку мөстәхәб:

اَللَّهُمَّ إِنِّي أَسْئَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ الْعَظِيمِ

Әллааһүммә инниии әс’әлүкә мин фәдъликәл-гәҙыйм

Мәгънәсе: «Йә Рабби, дөреслектә, мин Синнән олуг фазыйләт һәм Рәхмәтеңне сорыйм».

Мәчеткә кергәч, сөннәт намаз укылмаса, ике рәкәгать намаз (тәхиййәтүл мәсҗид) уку – мөстәхәб.

Мәчет эчендә әдәпле, тыйнак утыру, зикер, тәсбих әйтү, тәүбә, истигъфар, дога кылу белән шөгыльләнү; Коръән йә китап укып утыру, вәгазь сөйләү яки тыңлау, гыйлем өйрәнеп яки башкаларга өйрәтеп утыру – мөстәхәб.

Суган, сарымсак һәм торма ашаган килеш мәчеткә керү һәм анда дөнья эшләрен башкарып, кирәкмәгән сүзләр сөйләп, көлешеп утыру – мәкруһ.

Иртәнге намазга дип мәчеткә барып кергәндә имам фарыз намазны укырга керешкән булса, ике хөкем бар: әгәр тиз генә ике рәкәгать сөннәтне укыганнан соң фарыз намазның ахыргы рәкәгатенә имамга оеп калырлык булса, әүвәл мәчетнең икенче бүлмәсендә яки аулак урында ике рәкәгать сөннәт намазын укырга, аннары имамга мәсбук булып оерга; әгәр сөннәт намазын укыган очракта фарыз намазының һичбер рәкәгатенә өлгермәслек булса, сөннәт намазын укымыйча, кергәч тә имамга оерга кирәк. Калдырылган ике рәкәгать сөннәт намазы фарыз намазы укылганнан соң каза кылынмый.

Әгәр иртәнге намазның сөннәтен укырга керешкәч, камәт әйтелеп, имам фарыз намазына керешсә, тиз генә сөннәт намазын тәмамлап, имамга оерга кирәк.

Өйлә намазын укыр өчен мәчеткә кергәндә имам өйләнең фарызын укырга керешкән булса, дүрт рәкәгать сөннәт намазын укымыйча, тиз генә имамга оерга кирәк. Фарыз намаз тәмамлаганнан соң башта дүрт рәкәгать сөннәт намазы каза кылына, аннары ике рәкәгать сөннәт намазы укыла.

Мәчеткә кереп өйләнең дүрт рәкәгать сөннәтен укырга керешкәч, камәт төшерелеп, имам фарыз намазын укый башласа, башлаган намазны ике рәкәгать нәфел намазы итеп тәмамлап тиз генә имамга оерга кирәк. Фарыз намазы тәмамлангач башта дүрт рәкәгать сөннәт намазы, аннан тагы ике рәкәгать сөннәт намазы укыла.

Әгәр дүрт рәкәгать сөннәт намазының өченче рәкәгате укый башлаган булса, аны тәмамларга һәм укып бетергәч имамга оерга кирәк.

Хатын-кызларга намазны мәчеткә барып уку – мәкруһ. Карчыкларның иртәнге, ахшам һәм ястү намазларын мәчеттә укулары мәкруһ түгел[1].

НАМАЗНЫҢ КАЗАСЫ

(ВАКЫТЫНДА УКЫЛМАГАН НАМАЗЛАРНЫ ҮТӘҮ)

Биш вакыт намазны вакытында әда[2] кылу – фарыз. Намазны сәбәпсез калдырырга ярамый.

Әгәр бер намаз үз вакытында укылмаса, аны ахырдан каза[3] кылу – фарыз.

Иртәнге намаз кояш чыкканчы укылмый калып, өйлә вакыты җиткәнче каза кылынса, сөннәте дә, фарызы да каза кылына. Әгәр өйлә вакыты җиткән булса фарызы гына каза кылына.

---

1 Җәмгыятьнең дини вазгыяте үзгәрү сәбәпле хәзерге вакытта бу фикергә караш башкача

2 Әда – гамәлне вакытында үтәү

3 Каза – гамәлне вакыты чыкканнан соң үтәү

Иртәнге намазыннан кала башка намазларның фарызлары гына каза кылына. Сөннәт намазлары каза кылынмый.

Вакытында укылмый калса, ястү намазы белән бергә витр намазы да каза кылына.

Җомга намазын укый алмаган кеше, шул көнне өйлә намазы укый.

Гает (бәйрәм) һәм тәравих намазлары үз вакытларында укылмый калсалар, соңыннан каза кылынмыйлар.

Әгәр намаз җәмәгать белән каза кылынса, кычкырып укыла торган рәкәгатьләрдә имамга кыйра'этне кычкырып уку – вәҗиб. Әгәр ялгыз каза кылынса, һәр рәкәгатьтә кыйра'этне эчтән уку – вәҗиб.

Казага калган намазларның тәртипләре билгеле булса, алар шул тәртип буенча каза кылыналар. Мәсәлән, бер көннең биш вакыт намазы да укылмый калган булса, иртәнге намаздан башлап ястү һәм витр намазына кадәр тәртип буенча каза кылыналар.

Берәүнең үз гомерендә дүрт-биш кенә намазы казага калган булса, ул кешегә вакыты кергән намазны укымыйча, иң беренче казага калган намазын уку, вакыты кергән намазны казадан соң уку – фарыз. Мәсәлән, өйлә намазы казага калган булса, икенде вакыты кергәч, башта өйлә намазы каза кылына, аннан икенде укыла.

Әгәр гомерендә берәүнең алты намазы казага калган булса, ул ихтыярлы: теләсә әүвәл казага калган намазын укый, теләсә башта вакыты кергән намазны укый.

Намазны каза кылу алдыннан азан һәм камәт әйтү – сөннәт. Әгәр өч намаз бер вакытта каза кылынса, барысына да бер азан җитә, ә камәт һәрбер намаз өчен аерым әйтелә.

Казага калган намазга түбәндәгечә ният кылалар: «Ният кылдым фәлән көндә, фәлән вакытта укылмаган иртәнге намазымның ике рәкәгать фарызын үтәмәккә, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр».

Үз гомерендә бик күп намазлары казага калган кеше, картайгач шуларны үтәмәкче булса, шушы рәвешле ният кыла: «Ният кылдым вакытында укылмаган иртәнге намазларымның иң соңгысын каза кылмакка, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр». Башка намазлар да шул рәвешчә ниятләнә.

СӘҖДӘИ СӘҺҮ

(НАМАЗДАГЫ ЯЛГЫШЛЫКЛАРНЫ ТӨЗӘТҮ)

Әгәр намазның бер фарызы кешенең ихтыяры белән яки онытып үтәлмәсә, намаз дөрес булмый. Ул кешегә намазын яңадан уку – фарыз.

Әгәр берәү үз ихтыяры белән намазның бер вәҗибен калдырса, намазы бозылмый, ләкин үзе гөнаһлы була.

Әгәр берәү намазның бер вәҗибен онытып яки ялгышып калдырса, аңа намазның ахырында сәҗдәи сәһү кылу – вәҗиб. Ул түбәндәгечә башкарыла: әгәр ул ялгыз укучы булса, ахыргы кагъдәсендә «Тәшәһһүд»не укыганнан соң «Салават» һәм «Дога»ны укымыйча, ике якка сәлам биреп, ике тапкыр сәҗдә кыла. Һәр сәҗдәдә өчәр мәртәбә

тәсбих әйтә, аннан соң янә кагъдәгә утырып «Тәшәһһүд», «Салават» һәм «Дога»ны укып сәлам бирә. Шуннан соң намазын тәмамлый.

Әгәр ул кеше имам булса, оеп укучылар торып китмәсеннәр өчен, сәҗдәи сәһүгә кадәр уң якка гына сәлам биреп, аннан соң сәҗдәи сәһү кыла.

Имам үзенең ялгышы өчен сәҗдәи сәһү кылса, аңа ияреп оючыларга да, мәсбукка[1] да сәҗдәи сәһү кылу – вәҗиб. Әгәр оючы ялгышса, һичкемгә сәҗдәи сәһү кылу вәҗиб булмый.

Әгәр берәү намазда ялгышып, түбәндәге 17 төрле гамәлне кылса, аңа сәҗдәи сәһү кылу вәҗиб була:

1) намазның әүвәлге ике рәкәгатенең берсендә «Фатиха» сүрәсе урынына башка бер аять укыса;

2) әүвәлге ике рәкәгатенең берсендә «Фатиха»дан соң сүрә укымаса;

3) өч һәм дүрт рәкәгатьле намазда әүвәлге кагъдәдә утырмаса;

4) бер кагъдәдә «Тәшәһһүд» укымаса;

5) әүвәлге кагъдәдә «Тәшәһһүд»тән соң «Салават» укыса;

6) әүвәлге кагъдәдә ялгышып сәлам бирсә;

7) кычкырып укыла торган рәкәгатьтә имам кыйра'әтне эчтән укыса;

8) эчтән укыла торган рәкәгатьтә имам кыйра'әтне кычкырып укыса;

[1] Мәсбук – әүвәлге рәкәгатькә җитешмәгән кеше

9) витр намазында «Кунүт» догасын укымаса;

10) кыйра’әт укудан алдарак рөкүгъка китсә;

11) тәкбир әйтеп намазга керешкәннән соң янә бер тәкбир әйтсә;

12) «Фатиха» сүрәсен ике мәртәбә укыса;

13) рөкүгъне ике мәртәбә кылса;

14) сәҗдәне өч мәртәбә кылса;

15) ахыргы кагъдәдә «Тәшәһһүд»тән соң кыямга торса;

16) ахыргы кагъдәдә утырмыйча гына кыямга торса;

17) ничәнче рәкәгатьтә икәнен уйлап торып, аять яки «Тәшәһһүд» кебек бер зикерне тиешсез урында укып, намазның бер гамәлен кичектерсә.

Фарыз намазының сүрә кушылмый торган ахыргы рәкәгатьләрендә «Фатиха» сүрәсенә башка бер сүрә кушу, намазда сөннәт яисә мөстәхәб булган гамәлләрнең берсен үтәми калдыру сәбәпле сәҗдәи сәһү кылу вәҗиб булмый.

Ялгышып сәҗдәи сәһү вәҗиб булырлык ике-өч төрле гамәл эшләнсә дә, сәҗдәи сәһү бер генә тапкыр үтәлә.

Намазда ялгышкан кеше онытылып ахырдан сәҗдәи сәһү кылмаса, намазына кимчелек килми, аның өчен намаздан соң һичбер гамәл кылырга кирәкми.

НАМАЗДА САТАШУ

Берәү дүрт рәкәгатьле намазда ялгышып, беренче кагъдәгә утырмыйча, кыямга тора башлаганда гына ялгышканлыгы исенә төшсә, ике хөкем бар:

1) әгәр тезләре турыланып җитмәгән булса, кире кагъдәгә утыра һәм «Тәшәһһүд» укый, ахырдан сәҗдәи сәһү кылмый;

2) әгәр дә тезләре турыланып кыямга якынлашкан булса, кыямга тора һәм өченче рәкәгатьне укый башлый, әүвәлге кагъдә үтәлми кала. Намаз ахырында сәҗдәи сәһү кыла.

Бер кеше дүрт рәкәгатьле намазда[1] ахыргы кагъдәгә утыргач, «Тәшәһһүд»не укыганнан соң, әүвәлге кагъдә дип белеп бишенче рәкәгатьне укый башласа, янә ике хөкем бар:

1) әгәр бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен кылганчы ялгышканын исенә төшерсә, тиз генә кагъдәгә утырып сәлам биреп, сәҗдәи сәһү кыла;

2) әгәр дә ялгышканын бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен кылгач кына исенә төшерсә, янә бер рәкәгать укып, намазын алты рәкәгать итә дә, ахырда сәҗдәи сәһү кылып намазын тәмамлый. Артык укылган ике рәкәгате нәфел намазы булып кала.

Әгәр бер кеше ахыргы кагъдәгә һич утырмыйча бишенче рәкәгатьнең кыямына торса, шулай ук ике хөкем бар:

---

[1] Өч рәкәгатьле намазда ялгышуның хөкемнәрен дүрт рәкәгатьле намазда ялгышучы охшатып белер.

1) әгәр бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен кылганчы ялгышканын исенә төшерсә, кагъдәгә тиз генә утыра һәм «Тәшәһһүд» укып сәлам бирә дә, сәҗдәи сәһү кыла.

2) әгәр дә ялгышканын бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен кылгач кына исенә төшерсә, намазы фарызлыктан чыгып нәфелгә әйләнә. Янә бер рәкәгать укып, намазын алты рәкәгать нәфел итеп тәмамлый да, фарызын яңадан укый башлый.

Бер кеше намаз эчендә ничә рәкәгать укыганын онытып, үзенең ничәнче рәкәгатьтә икәнен белмәсә, намазын бозып[1] яңадан укый. Әгәр дә ике-өч мәртәбә шул рәвешчә үзенең ничә рәкәгать укыганын онытса, намазын бозмый, күңеле ничә рәкәгать укыганын хуп күрсә, үзен шулкадәр укыганга санап, намазын тәмамлый. Әгәр дә ничә рәкәгать укыганын һич аңламаса, үзен аз укыган итеп санар. Мәсәлән: «Бу укый торган рәкәгатем беренче рәкәгатемме икән, икенче рәкәгатемме икән?» – дип икеләнсә, беренче рәкәгатькә санар... «Өченче рәкәгатемме икән, дүртенче рәкәгатемме икән?» – дип уйласа, өченче рәкәгатькә санар.

Намаз ахырында рәкәгатьләрнең саны турында шөбһәләнсә, ахыргы рәкәгать икәне ихтимал булган рәкәгатьтә кагъдәгә утыру зарур, чөнки ахыргы рәкәгатьтә кагъдәгә утыру – фарыз.

Бер кеше дүрт рәкәгатьле намазга керешеп, ике рәкәгать укыгач, әүвәлге кагъдәдә ялгышып сәлам бирсә, ике хөкем бар:

---

[1] Намазны бозачак кеше нинди гамәл (кыям, җәлсәдә, кагъдә) үтәвенә дә карамастан ике тарафка сәлам биреп намаздан чыга.

1) әгәр сәлам биргәннән соң намазын бозарлык гамәл кылмаса, кыямга торып, калган рәкәгатьләрен укып намазын тәмамлый да, ахырда сәҗдәи сәһү кыла;

2) әгәр дә намазын бозарлык берәр гамәл кылса, намазын кабат укый.

СӘҖДӘИ ТИЛӘВӘТ

(КОРЪӘН УКЫГАНДА СӘҖДӘ КЫЛУ)

Коръәни-Кәримнең 14 урынында сәҗдә аяте бар: «Әгъраф», «Рагъд» «Нәхел», «Исра», «Мәрьям», «Хаҗ», «Фуркан», «Нәмел», «Сәҗдә», «Сад», «Фуссиләт», «Нәҗем», «Иншикак», «Галәк» сүрәләрендә.

Шушы сәҗдә аятьләренең берсен укыган кешегә дә, ишеткән кешегә дә сәҗдәи тиләвәт кылу – вәҗиб.

Сәҗдәи тиләвәт түбәндәгечә башкарыла: тәһарәтле килеш кыйблага каршы басып: «Ният кылдым сәҗдәи тиләвәт кылуга», – дип ният кыла да, тәкбир әйтеп сәҗдәгә китә. Анда өч мәртәбә сәҗдә тәсбихен әйтә, аннары тәкбир әйтеп торып, кагъдәгә утыра. Соңыннан түбәндәге сүзләрне укып дога кыла:

سَجَدْتُ لِلرَّحْمٰنِ وَآمَنْتُ بِالرَّحْمٰنِ فَاغْفِرْ لِي ذُنُوبِي يَا رَحْمٰنُ

سَمِعْنَا وَاَطَعْنَا غُفْرَانَكَ رَبَّنَا وَإِلَيْكَ الْمَصِيرُ

Сәҗәдтү лир-рахмәәни үә әәмәнтү бир-рахмәәни фәгфирлии ҙүнүүби йәә рахмәәнү сәмигнәә үә әтагнәә гуфраанәкә раббәнәә үә иләйкәл-мәсыйр

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә өчен сәҗдә кылдым һәм Аңа иман китердем. Әй Рәхмәтле Аллаһы, гөнаһларымны ярлыка. Әй Раббыбыз, без Синең гафуыңны ишеттек һәм Сиңа итагать кылдык. Без ахырда Синең хөкемеңә кайтачакбыз».

Сәҗдәи тиләвәт өчен намаздагы кебек тәһарәтле булу; тәннең, киемнең, намазлыкның пакь, гаурәт җирләренең капланган булуы һәм кыйблага каршы тору шарт. Сәҗдәи тиләвәтнең махсус вакыты юк. Намаз уку мәкруһ булган вакыттан башка теләсә кайчан кылына ала.

Сәҗдәи тиләвәттә намазга керешкәндәге кебек тәкбир белән кулларны колак турысына кадәр күтәрү, кыям һәм рөкүгъ юк. Сәҗдәсе дә бер генә. Намаз эчендә сәҗдә аятьләрен укыган кеше аятьне укып бетереп, намазны бозмыйча, тәкбир әйтеп сәҗдәгә китә. Бер сәҗдә кылгач, тәкбир әйтеп кыямга тора да, берничә аять укып рөкүгъка бөгелә.

Әгәр сәҗдә аятен укыгач та рөкүгъка китсә, сәҗдәи тиләвәт кылу вәҗиб булмый, рөкүгы сәҗдәи тиләвәт урынына була.

Әгәр имам намаз эчендә сәҗдәи тиләвәт кылса, аңа ияреп моктәдиләргә дә сәҗдә кылу – вәҗиб.

Берәү мәҗлестә ике сәҗдә аятен укыса яки ишетсә, һәр аять өчен берәр сәҗдәи тиләвәт кылырга тиеш. Әгәр дә бер мәҗлестә бер сәҗдә аятен ике мәртәбә укыса яисә ишетсә, бер генә сәҗдәи тиләвәт кыла.

Әгәр бер сәҗдә аятен ике мәҗлестә укыса яки ишетсә, ике мәртәбә сәҗдәи тиләвәт кыла.

Утырган җирдән торып китү, бер бүлмәдән икенчесенә чыгу, бер сүз беткәннән соң икенче сүзгә яисә икенче эшкә керешү белән мәҗлес үзгәрә.

Кеше ишетерлек урында сәҗдә аятен кычкырып уку, сәҗдә аятен үзен генә атап уку һәм Коръән укыганда сәҗдә аятен укымый калдыру – мәкруһ.

Сабый бала, акылга зәгыйфь кеше, хәезле һәм нифаслы хатыннар сәҗдә аятен укысалар да, ишетсәләр дә, аларга сәҗдәи тиләвәт кылу вәҗиб түгел, ә аларның укыганын ишеткән кешеләргә вәҗиб.

Бер кеше җөнеб (госелсез) вакытында йә исерек чакта сәҗдә аятен укыса яки ишетсә, аңа соңыннан сәҗдә кылу – вәҗиб.

МОКЫЙМ ҺӘМ МОСАФИР

Үз өендә даими торучы кешегә мокыйм дип әйтәләр. 100 чакрым чамасы (уртача йөреш белән өч тәүлек барырлык) бер җиргә бару нияте белән юлга чыккан кешегә мосафир диләр.

Сәфәргә чыгучы, үз шәһәренең (авылының) йорты яныннан башлап кабат шул җирлеккә кайтканчы яки башка бер шәһәрдә 15 көнгә кадәр торуны ният кылса, мосафир хөкемендә була.

Әгәр мосафир бер шәһәрдә 15 көн торуны ният кылса, шул вакыттан алып ул мокыйм хөкемендә була, әгәр дә 15 көн тулганчы тагын сәфәргә чыкса, мосафир хөкемендә була.

Мосафирның бер шәһәрдә 15 көн тору нияте булмыйча, эшләре чыгу сәбәпле яки берәр хәбәр көтү сәбәпле 15 көнгә кадәр шул шәһәрдә калса да, ул барыбер мосафир хөкемендә була.

Ике шәһәрдә йорты булган кеше шул шәһәрләрнең кайсына гына барса да, мосафир булмый. Әгәр дә ул шәһәрләрнең арасы йөз чакрым чамасы кадәр булса, бер йортыннан икенчесенә барганда гына мосафир хөкемендә була.

Мосафирның өч өстенлеге бар:

1) аңа өйлә, икенде һәм ястү намазларының фарызларын икешәр генә рәкәгать итеп кыскартып уку – вәҗиб;

2) читекләренә өч тәүлек тулганчы мәсех тарту дөрес була;

3) сәфәр вакытында, Рамазан ае туры килсә, уразаны тотмыйча казага калдыруы да дөрес була.

Мосафир дүрт рәкәгатьле сөннәт намазларын, өч рәкәгатьле ахшам һәм витр намазларын кыскартырга тиеш түгел.

Дүрт рәкәгатьле намазда мосафир мокыймга имам булса, башта мокыймга үзенең мосафир икәнлеген аңлата һәм ике рәкәгать укыгач, сәлам биреп намазын тәмамлый. Мокыйм сәлам бирмичә, торып басып намазының калган ике рәкәгатен дәвам итеп, ялгызы гына укып тәмамлый.

Әгәр дүрт рәкәгатьле намазда мосафир мокыймга ойгән булса, имамга ияреп, ул да дүрт рәкәгать укый.

Мосафир үзенең мокыйм вакытында укымый калган дүрт рәкәгатьле намазын сәфәрдә каза кылырга уйласа, кыскартмыйча дүрт рәкәгать итеп каза кыла. Мосафир вакытында укымый калган намазын мокыйм булгач каза кылса, ике рәкәгать итеп каза кыла.

ҖОМГА НАМАЗЫ

Балигъ һәм акылы булган ир кешегә җомга көнне өйлә намазы урынына җомга намазын уку – фарыз.

Җомга намазы фарыз булуның 8 шарты бар:

1) ذكورت зүкүрат – ир кеше булу;

2) بلوغ бүлүг – балигъ булу;

3) عقل гакл – камил акыллы булу;

4) حريت хүррийәт – ирекле булу;

5) إقامت икамәт – мокыйм булу;

6) صحت сыйххәт – сәламәт булу;

7) سلامت عين сәламәт гәйн – күзләрнең сәламәт булуы;

8) سلامت رجل сәламәт риҗл – аякларның сәламәт булуы.

Хатыннарга, сабыйларга, акылы зәгыйфь кешеләргә, төрмәдә утыручыларга, мосафирларга, авыруларга, ике күзе дә сукыр булганнарга, аксакларга җомга намазы фарыз түгел, чөнки сәбәбе бар. Алар җомга намазы урынына

өйлә намазын укыйлар. Шулай ук мәчеткә барып, җомга намазын укысалар да дөрес санала.

Җомга намазын укыр өчен алты шарт бар:

1) مصر миср – бер зур шәһәрдә йә зур авылда мәчетнең булуы;

2) إمام имәм – падишаһ йә мөфти тарафыннан билгеләнгән имамның булуы;

3) جماعت җәмәгать – имамнан башка намаз укырлык акыллы өч кешенең булуы;

4) إذن عام изнугәм – җомга намазы укыла торган мәчетнең һәркем өчен ачык булуы;

5) وقت ظهر уакту зуһр – өйлә вакытында укылуы;

6) خطبة хутбәһ – җомга намазының фарызыннан әүвәл имамның хөтбә укуы.

Шушы алты шартның һәрберсе үтәлергә тиеш. Берсе генә үтәлмәсә дә, җомга намазы укылмый, өйлә намазы гына укыла.

Җомга намазы 10 рәкәгатьтән тора: әүвәл 4 рәкәгать сөннәт, аннан соң 2 рәкәгать фарыз, аннан соң янә 4 рәкәгать сөннәт укыла.

Җомга намазы укыла торган мәчеткә баргач, башта ике рәкәгать тәхийәтел мәсҗид намазы укыла. Соңгы дүрт рәкәгать сөннәт намазыннан соң 4 рәкәгать ахыргы өйлә намазы укыла, аннан соң, җомга вакытын хөрмәтләп, ике рәкәгать вакыт сөннәте намазы укыла[1].

Җомга вакытында укыла торган намазларны түбәндәгечә ниятлиләр:

1) Ният кылдым җомга намазының дүрт рәкәгать сөннәтен үтәмәккә, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

2) Ният кылдым җомга намазының ике рәкәгать фарызын үтәмәккә, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

3) Ният кылдым җомга намазының дүрт рәкәгать сөннәтен үтәмәккә, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр.

Җомга намазының фарызын башлаганчы имам ике хөтбә укый. Араларында аз гына утырып тора. Ул хөтбәләрдә Аллаһы Тәгаләгә хәмед, кәлимәи шәһәдәт, Мөхәммәд ﷺ гә һәм аның сәхабәләренә салават һәм мактау сүзләрен әйтә, бераз вәгазь аятьләрен укый. Мәчеттәге кешеләргә гыйбрәтле вәгазьләр сөйли. Әһле Ислам (бөтен мөселманнарга) һәм ил башлыкларына хәерле дога кыла.

---

[1] Соңгы 4 рәкәгать ахыргы өйлә намазы һәм аннан соң, җомга вакытын хөрмәтләп, ике рәкәгать вакыт сөннәте намазы, мәчетнең җәмигъ, ягъни җомга укыла алырлык булуына шик булганда укыла. Мәсәлән: билгеләнгән мәчеттә җомга укырга рөхсәт бирерлек мөселманнарның солтаны (мөфтие) булмаса. Яки ул мәчет бары тик аерым бер категория кешеләр өчен генә булып, башка кешеләргә керергә рөхсәт ителмәсә һ.б.

Имам хөтбә укыр алдыннан мәзин **«Ускуту рахимәкүмуллаһу»** дип әйтә. Аның мәгънәсе: «Әй җәмәгать, тыңлап торыгыз, Аллаһы Тәгалә сезгә Үз рәхмәтен бирсә иде». Аннан соң имамның каршында азан әйтә.

Имам хөтбә укыган вакытта мәчеттә булган кешеләргә һичбер сүз сөйләшмичә һәм һичнинди эш башкармыйча, чын ихластан тыңлау – вәҗиб. Бу вакытта сөннәт һәм нәфел намазларын уку, зикер, тәсбихләр әйтү дөрес түгел.

Имам хөтбә укыган вакытта мәчеткә килеп кергән кеше тәхиййәтүл мәсҗид намазын да, җомганың дүрт рәкәгать сөннәтен дә укымый, тын гына хөтбәне тыңлап утыра. Җомга намазының фарызы укылганнан соң, дүртәр рәкәгать ике сөннәт намаз укып, фарызга кадәр булган сөннәтне дә каза кыла, тәхиййәтүл мәсҗид намазы укылмаган килеш кала.

Берәү мәчеткә кереп, тәхиййәтүл мәсҗид яки дүрт рәкәгать сөннәт намазын укырга керешкәч, имам хөтбә укый башласа, ул кеше башлаган намазын бозмыйча укып бетерергә тиеш.

Җомганың фарызына имам сәлам биргәнче оеп калган кеше мәсбук булып, калган рәкәгатьләрен имамнан соң каза кыла. Имам сәлам биргәнче оеп кала алмаган кеше өйлә намазын укый.

Җомга көн – мөселманнарның догалары һәм изге гамәлләре кабул була торган мөбарәк бәйрәм. Һәр мөселманга, җомга көнен олылап, гөнаһлы эшләрдән тыелырга, игелекле гамәлләр кылырга, фәкыйрьләргә сәдакалар бирергә, әти-әни һәм туганнар белән күрешеп аларның хәлләрен белергә, зиратка барып яки өйдә

Коръән укып савабын мәетләрнең рухларына багышларга, буш вакытларда Коръән укырга, зикер әйтергә һәм догалар кылырга кирәк.

Бик фәкыйрь булмаган кешегә җомга көнне дөнья эшләрен күп эшләмәскә, гыйлем, гыйбадәт, вәгазь мәҗлесләрендә булырга, дуслар һәм туган-тумачалар белән күрешеп, бәйрәм итеп, шатлык белән үткәрергә кирәк.

ГАЕТ (БӘЙРӘМ) НАМАЗЛАРЫ

Җомга намазы фарыз булган кешеләргә гает намазларын уку – вәҗиб. Хатыннар һәм сабыйлар кебек җомга намазы фарыз булмаган кешеләргә гает намазлары да вәҗиб түгел.

Гает намазларын уку өчен биш нәрсә шарт: Мисыр (җирле идарә органы һәм җомга намазы укылырлык мәчете булган шәһәрчек, зур авыл яки поселок), изнугам (мәчетнең җомга намазы укыр өчен һәртөрле дәрәҗәдәге кешеләргә ачык булуы, керергә мөмкинлек булуы), имам, җәмәгать, вакыт[1].

Гает намазларының вакыты – кояш чыгып, өч аршин кадәр күтәрелгәннән башлап, өйлә вакыты кергәнче.

Бер сәбәп аркасында Гает Фитыр (Ураза бәйрәме) намазы Шәүвәл аеның беренче көнендә укылмый кал-

---

1 Җомгада хөтбә шарт булып торса, гает намазларында шарт түгел, ә сөннәт. Җомга хөтбәсе фарыз намазга хәтле укыла. Гает хөтбәләре намаздан соң укыла.

са, Шәүвәлнең икенче көнендә уку дөрес була, өченче көнендә уку дөрес булмый.

Гает Корбан (Корбан бәйрәме) намазы зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә укылмый калса, зөлхиҗҗәнең уникенче көненә кадәр кичектереп уку дөрес була.

Ике гает намазы да икешәр рәкәгатьтән тора. Азан һәм камәттән башка һәрвакыт җәмәгать белән укыла. Намаз вакыты җиткәнен мәзин манарага менеп, берничә мәртәбә «Әс-салят» дип кычкырып, мәхәллә халкына белгертә.

Ураза гаете намазын түбәндәгечә ниятлиләр: «Ният кылдым ике рәкәгать гает фитыр намазын үтәмәккә, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр».

Корбан гаете намазын түбәндәге рәвештә ниятлиләр: «Ният кылдым ике рәкәгать Корбан гаете намазын үтәмәккә, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр».

Гает намазларының һәр икесе түбәндәге рәвештә укыла: ният кылып, тәкбир әйтеп намазга керешкәннән соң, имам да, моктәдиләр дә (имамга оючылар) «Сәнә» укыйлар, аннан соң һәрберсе намазга керешкәндәге кебек өч мәртәбә кулларын колакка кадәр күтәреп, өч мәртәбә тәкбир әйтәләр, тәкбирләрнең арасында кулларын бagламыйча төшереп торалар. Аннан соң имам башка намазлардагы кебек сүрәләрне кычкырып укый. Рөкүгъ һәм сәҗдә кылып, икенче рәкәгатьнең кыямына торганнан соң, имам янә кычкырып сүрәләр укый. Рөкүгъ кылыр алдыннан, беренче рәкәгатьтәге кебек янә өч мәртәбә кулларын колакка кадәр күтәреп тәкбир әйтә дә, дүртенче тәкбир белән рөкүгъкә иелә. Рөкүгъ һәм сәҗдә кылганнан

соң, кагъдә һәм сәлам белән башка намазлардагы кебек тәмамлый.

Гает намазына соңга калып килгән кеше имам сәлам биргәнче оеп калса, мәсбук булып калган рәкәгатьләрен имамнан соң каза кыла. Әгәр имам сәлам биргәнче оерга җитешә алмаса, шул рәвешле кала, ягъни гает намазлары каза кылынмый.

Гает намазларын укыганнан соң, имамга ике мәртәбә хөтбә укып, халыкка вәгазь сөйләү, фитыр һәм Корбан хөкемнәрен өйрәтү, гает көннәрендә сөннәт булган эшләр турында сөйләү – сөннәт.

ТӘРАВИХ НАМАЗЫ

Рамазан аенда көн саен ястү намазыннан соң витр намазына кадәр тәравих намазын уку ирләргә дә, хатыннарга да сөннәт.

Тәравих намазы 20 рәкәгатьтән тора. Икешәр рәкәгать ун намаз итеп яки дүртәр рәкәгать биш намаз итеп укыла. Бу намаз ялгыз да укыла, әмма җәмәгать белән мәчеттә уку сөннәт санала.

Тәравих намазын җәмәгать белән укыганнан соң витр намазы да җәмәгать белән укыла. Имам тәравих намазының да, витрның да кыйра’әтләрен кычкырып укый.

Тәравих намазын түбәндәгечә ниятлиләр: «Ният кылдым ике рәкәгать тәравих намазын үтәмәккә, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр».

Тәравих намазлары арасында дүрт рәкәгать укыган саен, дүрт рәкәгатьле намаз укыган кадәр вакыт туктап тәравихә кылу, ягъни ял итеп тору – сөннәт.

«Тәравихә» вакытында тәсбих, тәһлил әйтеп яки әйтелгәнне тыңлап утыру – мөстәхәб.

Без яши торган төбәктә «тәравихә» вакытында түбәндәге тәсбих әйтелә:

سُبْحَانَ ذِى الْمُلْكِ وَالْمَلَكُوتِ

سُبْحَانَ ذِى الْعِزَّةِ وَالْعَظَمَةِ وَالْقُدْرَةِ وَالْكِبْرِيَاءِ وَالْجَبَرُوتِ

سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْحَيِّ الَّذِى لَا يَمُوتُ

سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّ الْمَلَآئِكَةِ وَالرُّوحِ

لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ نَسْتَغْفِرُ اللّٰهَ

نَسْئَلُكَ الْجَنَّةَ وَنَعُوذُ بِكَ مِنَ النَّارِ

Сөбхәәнә ҙил-мүлки үәл-мәләкүүт. Сөбхәәнә ҙил-гиззәти үәл-гәҙамәти үәл-кудурати үәл-кибрийәәә’и үәл-җәбәруут. Сөбхәәнәл-мәликил-хәййил-ләҙии ләә йәмүүт. Сөббуухүн куддүүсүр-раббүл-мәләәә’икәти үәр-руух. Ләә иләәһә ил-ләллааһү нәстәгъфирул-лааһ. Нәс’әлүкәл-җәннәтә үә нәгүүҙү бикә минән-нәәр

Мәгънәсе: «Җирдәге һәм күктәге мәхлукатның хуҗасы булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Көч, кодрәт һәм бик олуглык иясе булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Барлык галәмнең патшасы һәм беркайчан үлмәячәк, һәрвакыт терек булучы Аллаһы Тәгаләне данлыймын.

Ул Аллаһы Тәгалә барлык кимчелекләрдән бик пакь һәм мөкаддәс Зат, бөтен фәрештәләрнең һәм Җәбраил фәрештәнең Раббысы. Бер Аллаһы Тәгаләдән башка илаһи зат юк. Без гөнаһларыбызның ярлыкавын сорыйбыз. Йә Рабби, без Синнән җәннәтне сорыйбыз һәм тәмугътан Сиңа сыгынабыз».

Тәравих намазлары тәмам булып, бишенче тәсбих әйтелгәннән соң, түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ وَسَلِّمْ

اَللَّهُمَّ زَيِّنَا بِزِينَةِ الْإِيمَانِ وَشَرِّفْنَا بِشَرَافَةِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرِمْنَا بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ وَارْزُقْنَا الْجَنَّةَ وَالْغُفْرَانَ وَتَقَبَّلْ مِنَّا تَرَاوِيحَنَا يَا سُبْحَانْ وَاسْتَجِبْ دُعَاءَنَا يَا حَنَّانْ. بِفَضْلِكَ وَجُودِكَ يَا مَنَّانْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ

Әллааһүммә салли гәләә Мүхәммәдин үә гәләә әәли Мүхәммәдин үә сәллим. Әллааһүммә зәййиннәә бизиинәтил-иимәән. Үә шәррифнәә бишәраафәтил-

һидәәйәти үәл-гирфәән. Үә әкримнәә бисыйәәми шәһри рамәдаан. Үәр-зүкънәл-җәннәтә үәл-гүфраан. Үә тәкаббәл миннәә тәраауиихәнәә йәә сүбъхән. Үәс-тәҗибъ дугаа'әнәә йәә хәннәән. Бифәдъликә үә җүүдикә йәә мәннәән. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин

Мәгънәсе: «Йә Рабби, Мөхәммәд ﷺ гә, аның әһленә (гаиләсенә), рәхмәтеңне һәм сәләмеңне бир. Йә Рабби, безне иман зиннәте белән зиннәтлә, гыйлем һәм тәүфыйк белән кадерлә һәм Рамазан ае уразасы белән хөрмәтле ит. Безгә җәннәтне һәм ярлыкауны насыйп ит. Әй пакь булучы Аллаһ, безнең тәравих намазларыбызны кабул кыл, әй Рәхмәтле Раббыбыз һәм сорамыйча бирүче Аллаһ, фазыйләтең һәм юмартлыгың белән безнең догаларыбызны кабул кыл. Әй камил рәвештә Рәхмәтеңне бирүче Аллаһ, һәрнәрсә Синең рәхмәтең белән генә була».

Тәравих намазының һәр рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсеннән соң бер кыска сүрә укыла. Коръәннең башыннан алып, һәр рәкәгатендә куша-куша, берничә тәравихтә Коръәнне ахырына кадәр укып чыгу, ягъни хәтем кылу (тулысынча уку) – олуг сөннәт.

Тәравих намазын ястү намазын укыганнан соң уку – сөннәт. Әгәр тәравих намазы укыла башланган булса, иң әүвәл ялгыз гына ястү намазының дүрт рәкәгать фарызын укырга, ә аннан соң тәравих намазын ниятләп, имамга оерга кирәк.

Намазга соңарган кеше тәравихның калган рәкәгатьләрен имамнан соң ялгыз укый. Әгәр имам вит-

рны укып бетергәнче тәравихны тәмамласа, имамга мәсбук булып ойый. Әгәр дә тәравихны тәмамлаганчы имам витрны укып бетерсә, витрны да ялгыз укый.

ЖЕНАЗА НАМАЗЫ

Мәеткә дога кылу максаты белән җеназа намазын уку – фарыз кифая. Шуңа күрә мәетнең үлгәнен белүчеләр арасыннан берничә кеше бу намазны укыса, ул башкаларның өстеннән төшә. Әгәр һәрберсе укыса, һәркайсы саваплы була. Әгәр дә һичберсе укымаса, һәркайсы гөнаһлы була.

Җеназа намазының сигез шарты бар:

1) وضوء вудүъ – тәһарәтле булу;

2) طهرات بدن тәһарәт бәдән – тәннең пакь булуы;

3) طهرت ثوب тәһарәт сәүб – киемнең пакь булуы;

4) طهرات مكان тәһарәт мәкән – аяк баскан урынның пакь булуы;

5) ستر عورت сәтр гаурәт – гаурәт җирләренең капланган булуы;

6) استقبال قبلة истикъбәл кыйблә – кыйблага каршы булу;

7) نيت ният – ният кылу;

8) مغسولية ميت мәгъсүлийәт мәййит – мәетнең юылган булуы.

Әгәр мәет шәһит киткән булса, ягъни золымлык белән үтерелгән булса, юылмый. Шулай булса да, аның өчен җеназа намазы укыла.

Җеназа намазында кыйра'әт, рөкүгъ, сәҗдә һәм кагъдә юк, ул кыям хәлендә дүрт тәкбир һәм ике сәлам белән тәмамлана.

Җеназа намазын укыячак кеше башта: «Ният кылдым ошбу мәет өчен җеназа намазын укымакка, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгаләә», – дип ният кыла, аннан соң намазга керешкәндәге кебек кулларын күтәреп, тәкбир әйтә дә, кулларын баглап «Сәнә» укый, аннары кулларын күтәрмичә икенче тәкбирне әйтә һәм «Тәшәһһүд»тән соң укыла торган «Салават»ны укый. Соңыннан өченче тәкбирне әйтә.

Аннары түбәндәге доганы укый:

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَمَيِّتِنَا وَشَاهِدِنَا وَغَائِبِنَا وَصَغِيرِنَا
وَكَبِيرِنَا وَذَكَرِنَا وَأُنْثَانَا

اَللَّهُمَّ مَنْ أَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَأَحْيِهِ عَلَى الْإِسْلَامِ وَمَنْ تَوَفَّيْتَهُ
مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَى الْإِيمَانِ

اَللَّهُمَّ إِنْ كَانَ هَذَا الْمَيِّتُ مُحْسِنًا فَزِدْ فِي إِحْسَانِهِ وَإِنْ كَانَ
مُسِيئًا فَتَجَاوَزْ عَنْهُ

Әллааһүммә-гфир лихәййинәә үә мәййитинәә үә шәәһидинәә үә гаа'ибинә үә сагииринәә үә кәбииринәә үә ҙәкәринәә үә үнҫәәнәә. Әллааһүммә мән әхйәйтәһүү миннәә фә'әхйиһии гәләл-исләәми үә мән тәүәффәйтәһүү миннәә фәтәүәффәһүү гәләл-имәән. Әллааһүммә ин кәәнә һәәҙәл-мәййитү мүхсинән фәзид фии ихсәәниһи үә ин кәәнә мүси'ән фәтәҗәәүәз гәнһ

Мәгънәсе: «Йә Рабби, тереләребезне һәм үлгәннәребезне дә, монда булучыларны һәм монда булмаучыларны да, кечкенәләребезне һәм олыларыбызны да, ирләребезне һәм хатыннарыбызны да ярлыка. Йә Рабби, тере булганнарыбызга Ислам дине буенча яшәргә насыйп ит, ахирәткә китүчеләргә иман белән вафат булырга насыйп ит. Йә Рабби, әгәр ошбу мәет изге кеше булса, изгелеген арттыр, әгәр гөнаһлы кеше булса, гөнаһларын гафу кыл».

Әгәр мәет сабый йә акылга зәгыйфь кеше булса, өченче тәкбирдән соң, ошбу дога укыла:

اَللَّهُمَّ اجْعَلْ هَذَا الْمَيِّتَ لَنَا فَرَطًا وَذُخْرًا وَاجْعَلْهُ لَنَا

شَافِعًا مُشَفَّعًا

Әллааһүммә-җгәл һәәҙәл-мәййитә ләнәә фәратан үә ҙүхран үәҗгәлһүү ләнәә шәәфигән мүшәффәгәә

Мәгънәсе: «Йә Рабби, бу мәеткә безне җәннәттә каршы алучы булырга насыйп ит. Йә Аллаһ, бу мәетне безнең өчен шәфәгатьче кыл һәм шәфәгатеннән Үзең разый бул».

Аннан соң дүртенче тәкбир әйтелә дә, ике тарафка сәлам биреп, намаз тәмамлана.

Җеназа намазы тәмам булганнан соң ошбу дога укыла:

رَبِّ اغْفِرْ لَنَا وَلِهَذَا الْمَيِّتِ وَافْسَحْ لَهُ فِي قَبْرِهِ اَللَّهُمَّ زِدْ أَجْرَهُ وَلَا تُضِلَّنَا بَعْدَهُ

Рабби-гъфир ләнәә үә лиһәәҙәл-мәййити үәфсәх ләһүү фии кабриһ. Әллааһүммә зид әҗраһүү үә ләә түдыйлләнәә бәгдәһ

Мәгънәсе: «Йә Раббым, безнең гөнаһларыбызны да, бу мәетнең гөнаһларын да ярлыка һәм аңа кабердә җиңеллек бир. Йә Рабби, бу мәетнең әҗерен арттыр һәм аның үлеменнән соң безне адаштырма».

Җеназа укылган вакытта мәет башы көнбатышка һәм аягы көнчыгышка юнәлгән килеш чалкан ятырга тиеш. Имам үзенә оеган кешеләрдән алдарак булып, мәетнең күкрәге турысында басып тора.

Җеназа намазына имам ике тәкбирне әйткәч килеп оеган кеше мәсбук булып, калган тәкбирләрен мәет урыныннан алынганчы, имамнан соң каза кыла. Ашыгыч булганда мәсбук «Сәнә», «Салават» һәм «Дога»ны укымаса да дөрес була, соңгы өч тәкбирне әйтә дә сәлам бирә.

Тәһарәт алу сәбәпле, өлгерә алмау ихтималы булган кешегә, җеназа намазын тәяммүм белән дә укырга ярый.

НӘФЕЛ НАМАЗЛАРЫ

(САВАПЛЫ ӨСТӘМӘ НАМАЗЛАР)

Икенде һәм ястү намазлары алдыннан дүртәр рәкәгать нәфел намазын уку, шулай ук өйлә һәм ястү намазларының соңгы икешәр рәкәгать сөннәтләрен дүртешәр рәкәгать итеп уку – сөннәт дәрәҗәсендә булган бик саваплы мөстәхәб гамәл.

Намаз мәкруһ булмаган вакытларда ике, дүрт, алты яки сигез рәкәгать нәфел намазлары уку – мөстәхәб.

Дүрт, алты, сигез рәкәгатьле нәфел намазларының һәр кагъдәсендә «Салават» һәм «Раббәнә» укырга кирәк.

Ният кылып керешелгән нәфел намазын укып тәмамлау – вәҗиб, бозу – хәрам. Әгәр намазын бозса, соңыннан каза кылу – вәҗиб.

Ат өстендә барганда, атка атланган килеш нәфел намазын укып бару – дөрес. Ул вакытта кыйблага каршы уку фарыз булмый, юлы кая таба барса, шул якка таба карап укып барырга ярый.

Мәшһүр нәфел намазлары түбәндәгеләр:

1) хаҗәт намазы;

2) истиска намазы;

3) тәүбә намазы;

4) хәвеф намазы;

5) көсуф намазы;

6) хөсуф намазы;

7) сәфәр намазы;

8) шөкер намазы;

9) ишракъ намазы;

10) доха намазы;

11) әүвәбин намазы;

12) тәһәҗҗүд намазы;

13) һәвел намазы;

14) мәсҗид намазы;

15) истихарә намазы.

Хаҗәт намазы – Аллаһы Тәгаләдән берәр хаҗәтне сорап дога кылыр алдыннан укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы.

Истиска намазы – корылык сәбәпле игеннәргә һәм хайваннарга зарар килгәндә, Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сорап дога кылу өчен укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы. Бу намаз ачык җирдә укыла. Барлык мөселманнар бергә җыелып кырга чыгалар. Бала-чагаларын һәм йорт хайваннарын да үзләре белән алалар. Һәркем тәһарәтле килеш, түбәнчелекле кыяфәт белән җәяү бара. Кырга җиткәч һәрбер кеше кыйблага таба борылып баса. Имам җыелган кешеләргә бик күп вәгазьләр сөйли. Җыелган мөселманнарга кылган гөнаһлары өчен тәүбә һәм истигъфар кылырга һәм үзара дошман булганнарга берберсеннән гафу үтенергә куша. Халык тәүбә-истигъфар

кыла, бер-берсен гафу итә. Аннан соң һәркем ялгызы гына икешәр рәкәгать намаз укый.

Истиска намазыннан соң түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ اَسْقِ عِبَادَكَ وَارْحَمْ بَهَائِمَكَ اَللَّهُمَّ أَمَرْتَنَا بِدُعَائِكَ وَوَعَدْتَنَا بِإِجَابَتِكَ فَقَدْ دَعَوْنَاكَ كَمَا أَمَرْتَنَا فَاَجِبْنَا كَمَا وَعَدْتَنَا

اَللَّهُمَّ إِنْ لَمْ تَرْحَمْ لِأَنْفُسِنَا لِكَثْرَةِ ذُنُوبِنَا فَارْحَمْ صِبْيَانَنَا وَبَهَائِمَكَ

Әллааһүммә әскы гибәәдәкә үәрхәм бәһәә'имәк. Әллааһүммә әмәртәнәә бидугәә'икә үә үәгадтәнәә би'иҗәәбәтикә фәкадъдәгәүнәәкә кәмәә әмәртәнәә фә әҗибнәә кәмәә үәгәдтәнәә. Әллааһүммә ин ләм тәрхәм лиәнфүсинәә ликәҫрати ҙүнуубинәә фәрхәм сыбйәәнәнәә үә бәһәә'имәк

Мәгънәсе: «Йә Рабби, колларыңны эчерт, хайваннарыңа Үз рәхмәтеңне ирештер. Йә Рабби, Син безгә дога кылырга боердың һәм догаларны кабул кылырмын дип вәгъдә бирдең. Без Сиңа Үзең боерганча дога кылабыз, Син биргән вәгъдәң буенча безнең догабызны кабул итеп ал. Йә Рабби, әгәр гөнаһларыбызның күплеге сәбәпле безгә рәхмәтеңне ирештермәсәң, гөнаһсыз сабыйларыбызга һәм хайваннарга рәхмәтеңне бир».

Әгәр беренче көнне истиска намазын укып дога кылганнан соң яңгыр яумаса, янә ике көн шул рәвешле истиска намазы укыла. Әгәр кырда истиска намазы укыганда яңгыр ява башласа, башларны яңгырга чылатып, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылына.

Тәүбә намазы – гөнаһлар өчен үкенеп, тәүбә һәм истигъфар кылыр өчен укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы. Тәүбә намазы тәмамланганнан соң түбәндәге истигъфар укыла:

أَسْتَغْفِرُ اللّٰهَ أَسْتَغْفِرُ اللّٰهَ أَسْتَغْفِرُ اللّٰهَ تَعَالَى مِنْ كُلِّ ذَنْبٍ أَذْنَبْتُهُ عَمْدًا أَوْ خَطَاءً سِرًّا أَوْ عَلَانِيَةً وَأَتُوبُ إِلَيْهِ مِنَ الذَّنْبِ الَّذِى أَعْلَمُ وَمِنَ الذَّنْبِ الَّذِى لَا أَعْلَمُ إِنَّكَ أَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ

Әстәгфируллааһ, әстәгфируллааһ, әстәгфируллааһ тәгәәлә мин күлли ҙәнбин әҙнәбтүһү гәмдән әү хата’ән сирран әү гәләәнийәтән үә әтуубү иләйһи минәҙ-ҙәнбил-ләҙии әгләмү үә минәҙ-ҙәнбил-ләҙии ләә әгләмү иннәкә әнтә гәлләәмүл-гүйүүб

Мәгънәсе: «Мин Аллаһыдан һәрбер гөнаһымның ярлыкавын сорыйм, ялгышлык белән кылган гөнаһларым һәм хаталык белән кылган гөнаһларым өчен дә, яшерен кылган гөнаһларым һәм яшермичә кылган гөнаһларым өчен дә, шулай ук белеп кылган һәм белмичә кылган гөнаһларым өчен дә тәүбә итәм, бик үкенәм. Йә Аллаһ, Син яшеренне дә белүче».

Хәвеф намазы – бәла һәм афәттән курыккан вакытта, берәр зарар ирешмәсә иде дип, дога кылыр алдыннан укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы. Каты җил һәм давыллар булганда, күк күкрәп, яшеннәр яшьнәгәндә, яңгыр һәм боз яуганда, су ташу вакытында, җир тетри башлаганда, бик эссе һәм суык булганда укыла.

Көсуф намазы – кояш тотылган вакытта имам һәм җәмәгать белән мәчеттә укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы. Бу намазның кыйра'әтендә имам бик озын сүрәләр укый, әмма кычкырып укымый. Кояшның нуры күренгәнче һәркем мәхлукатның гаҗәп хәлләре белән гыйбрәтләнеп, Аллаһы Тәгаләгә хәмед (мактау сүзләре) һәм тәсбих әйтә.

Хөсуф намазы – ай тотылган вакытта укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы. Бу намаз өйдә ялгыз укыла.

Сәфәр намазы – сәфәргә чыгар алдыннан, сәфәр уңышлы булса иде дип дога кылу өчен укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы.

Шөкер намазы – ниндидер олуг нигъмәткә, дәрәҗәгә яки максатка ирешкәч, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылу нияте белән укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы.

Ишракъ намазы – кояш тәмам чыгып күтәрелә башлагач укыла торган нәфел намазы (ике, дүрт, алты яки сигез рәкәгать итеп укыла).

Доха намазы – кояшның чыккан вакыты белән өйлә вакытының уртасында укыла торган намаз. Мәсәлән, кояш иртәнге сәгать 4тә чыккан көннәрдә, сәгать 8дә укыла. Кояш сәгать иртәнге 8дә чыккан көннәрдә, сәгать 10да укыла. Бу намазны 2, 4, 6, 8, 10 яки 12 рәкәгать итеп укырга мөмкин.

Әүвәбин намазы – ахшам намазын укып бетергәннән соң укыла торган нәфел намазы (2, 4 яки 6 рәкәгать итеп укыла).

Тәһәҗҗүд намазы – төнлә, таң атканчы укыла торган нәфел намазы (2, 4, 6, 8, 10 яки 12 рәкәгать итеп укыла).

Һәвел намазы – ниндидер мөселманның вафат булганын ишеткәч, ахшамнан соң укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы (аның савабы шул мәетнең рухына багышлана).

Мәсҗид намазы – мәчеткә кергәннән соң укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы (тәхиййәтүл мәсҗид дип атала). Әгәр мәчеткә кергәч башка бер намаз укырга кирәк булса, мәчет намазы укылмый. Мәчет намазы мәчеткә биш вакыт намазны уку өчен кергәндә укылмый, ә җомга намазын укырга дип кергәндә укыла. Мәчет эчен карап чыгу нияте белән кергән кеше бу намазны укырга тиеш.

Истихарә намазы – ниндидер олуг эшне башлар алдыннан, шуның хәерле булуын теләп укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы.

Истихарә намазын тәмамлаганнан соң, түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ إِنِّى اَسْتَخِيرُكَ بِعِلْمِكَ وَاسْتَقْدِرُكَ بِقُدْرَتِكَ

وَأَسْئَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ الْعَظِمِ فَإِنَّكَ تَقْدِرُ وَلَا أَقْدِرُ وَتَعْلَمُ وَلَا

أَعْلَمُ وَأَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ اَللَّهُمَّ إِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الْأَمْرَ

خَيْرٌ لِى فِى دِينِى وَمَعَاشِى وَعَاقِبَةِ أَمْرِى فَاقْدِرْهُ لِى وَيَسِّرْهُ لِى

ثُمَّ بَارِكْ لِى فِيهِ وَإِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الْأَمْرَ شَرٌّ لِى فِى دِينِى

وَمَعَاشِى وَعَاقِبَةِ أَمْرِى فَاصْرِفْهُ عَلَى وَاصْرِفْنِى عَنْهُ وَاقْدِرْ لِى

الْخَيْرَ أَيْنَمَا كُنْتُ إِنَّكَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ

Әллааһүммә иннии әстәхыйрүкә бигильмикә үә әстәкъдирукә бикудратикә үә әс'әлүкә мин фәдликәл-гәҙыйми фә'иннәкә тәкъдиру үә ләә әкъдиру үә тәгләмү үә ләә әгләмү үә әнтә гәлләәмүл-гуйүүб. Әллааһүммә ин күнтә тәгләмү әннә һәәҙәәл-әмра хайрун лии фии диинии үә мәгәәшии үә гәәкибәти әмрии фәкдирһү лии үә йәссирһү лии ҫүммә бәәрик лии фииһ. Үә ин күнтә тәгләмү әннә һәәҙәәл-әмра шәррун лии фии диинии үә мәгәәшии үә гәәкыйбәти әмрии фәсрифһү гәләә үәсрифнии гәнһү үәкъдир лил-хайра әйнәмәә күнту. Иннәкә гәләә күлли шәй'ин кадиир

Мәгънәсе: «Йә Рабби, дөреслектә, мин Синнән Үз гыйлемең белән ярдәм итүеңне, кодрәтең белән миңа көч бирүеңне һәм Синең олуг рәхмәтеңне сорыйм. Дөреслектә, Синең кодрәтең бар нәрсәгә җитә, мин үзем генә (Синең кодрәтең булмаса) һичбер нәрсә эшли алмыйм. Син һәрнәрсәне беләсең, ә мин белмим. Дөреслектә, Син һәрбер яшерен нәрсәләрне беләсең. Йә Аллаһы, әгәр бу эшемне динем, дөньям һәм ахирәтем өчен хәерле дип белсәң, аны миңа насыйп ит һәм ул эшне минем өчен мөбарәк кыл. Әгәр дә бу эшемне динем, дөньям һәм ахирәтем өчен зарарлы һәм яман дип белсәң, ул эшне миннән һәм мине ул эштән азат ит. Кайда булсам да, миңа хәерле эшләрне насыйп ит. Дөреслектә, Синең көчең һәрнәрсәгә җитә».

Шушы доганы укыганнан соң әлеге эшкә күңеле тартса, хәерле булуына өмет итеп, аны башлар. Әгәр дә аның күңеле тартылмаса, үз ихтыярында калыр. Ниндидер бер хәерле эшне башлаган вакытта да, рәсми мәҗлесләрдә дә шушы доганы укырга мөмкин.

Шушы урында мөхтәрәм галим Әхмәдһади Максуди хезмәтенең дүртенче – «Җәмәгать» бүлеге тәмамлана.

Ураза, игътикаф, зәкят, гошер, фитыр, фидия, сәдака, корбан һәм хаҗ хөкемнәре «Гыйбадәте Исламия» китабының «Ураза, зәкят, хаҗ» дип аталган соңгы бүлегендә, Ин шә Аллаһ, аңлатылыр.

УРАЗА, ЗӘКЯТ ҺӘМ ХАЖ

Коръән аяте:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ

كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِنْ قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү күтибә гәләйкүмүс-сыяямү кәмәә күтибә гәләл-ләҙиинә миң кабликүм ләгәлләкүм тәттәкуун

Мәгънәсе: «Әй, иман китергән кешеләр, сездән алдагы кавемнәргә фарыз булган кебек, сезгә дә ураза фарыз булды, уразаларыгызны тотыгыз, шаять тәкъвалылардан булырсыз» *(«Бәкара /Сыер/», 2:183).*

Хәдис-шәриф

لِكُلِّ شَيْءٍ زَكَاتٌ وَزَكَاتُ الْجَسَدِ الصِّيَامُ

Ликүлли шәй'ин зәкәәтүн үә зәкәәтүл-җәсәдис-сыяям

Мәгънәсе: «Һәрнәрсәнең зәкяте, ягъни пакьләүчесе була. Тәннең зәкяте – ураза».

УРАЗА

Рамазан аенда көн саен ураза тоту, ягъни таң яктылыгы җәелгән вакыттан башлап, кояш батканчыга кадәр ашамый, эчми һәм якынлык кылмый тору – балигъ һәм акылы булган һәрбер мөэмин кешегә фарыз.

Уразаның фарызлары өч:

1) ният кылу;

2) ашау-эчүдән тыелу;

3) якынлык кылудан тыелу.

Сәхәр ашаганнан соң ураза өчен таң атканчы ният кылу – мөстәхәб. Өйләгә кадәр бер сәгать чамасы вакыт калганчы ният кылынса да ярый.

Ураза тоту өчен күңел белән ният кылу да җитә. Тел белән һичбер сүз әйтмичә, күңелдән иртәгә ураза тотачакмын дип уйлау да дөрес.

Ураза тотар алдыннан түбәндәге сүзләрне (гарәпчә) укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ صَوْمَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ

خَالِصًا لِلّٰهِ تَعَالَى

Нәүәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамадаанә минәлфәҗри иләл-мәгриби хаалисан лилләәһи тәгәәләә

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә өчен, ихласлык белән таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр Рамазан уразасын тотарга ният кылдым».

Кояш баткач ниндидер ризык, тоз яки су белән ифтар кылу, ягъни авыз ачу – сөннәт. Хөрмә кебек татлы җимешләр белән ифтар кылу – мөстәхәб.

Ифтардан соң (авыз ачканнан соң) түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ أَمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ
أَفْطَرْتُ فَاغْفِرْ لِي يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

Әллааһуммә ләкә сумтү үә бикә әмәнтү үә гәләйкә тәүәккәлтү үә гәләә ризкыйкә әфтартү фәгфирлии йәә гаффәәрү мә каддәмтү үә мәә әххартү

Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризалыгың белән авыз ачам. Әй гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».

Ураза токтан кешегә түбәндәге эшләр сөннәт санала:

1) таң атканчы төнлә торып сәхәр ашау;

2) ураза тотып нәфесне гөнаһлы эшләрдән тыюны ният кылу;

3) кәсептән бушаган вакытларда дини китаплар уку;

4) кояш баегач, ахшам намазын укыганчы авыз ачу.

Уразада көндезен түбәндәге 10 төрле эшне кылу мәкруһ санала:

1) файдасыз сүзләр сөйләү;

2) әдәпсез сүзләр сөйләү;

3) мунчага кереп озак утыру;

4) суга чумып коену;

5) ризык һәм сагыз чәйнәү;

6) берәр азыкка телне тидереп татып карау;

7) авыздан үбү;

8) ифтар кылмыйча ике көн рәттән ураза тоту;

9) нинди дә булса бер гөнаһлы гамәл кылу;

10) авыруыңның артачагын белә торып ураза тоту.

Ураза тоткан кешегә түбәндәге 10 төрле эшне башкару дөрес санала:

1) сатып алыначак малны татып карау;

2) балага ризык чәйнәп бирү;

3) күзгә сөрмә тарту;

4) мыек һәм иренне майлау;

5) тешләрне пакьләү;

6) кан алдыру;

7) сөлек салдыру;

8) комган белән госел коену;

9) мунчага кереп аягүрә тирләп чыгу;

10) сабын белән юыну.

Түбәндәге өч төрле эш уразаны боза:

1) борчак кадәр генә булса да берәр ризык яки дару йоту;

2) бер тамчы кадәр генә булса да су яки дару йоту;

3) якынлык кылу.

Рамазан уразасын үз ихтыяры белән бозган кешегә һәркөн урынына бер көн каза кылу һәм бозган өчен кәффарәт[1] кылу фарыз була.

Ураза кәффарәте өчен дөньяда коллар бетеп җитмәгән булса, берәр колны азат итеп, колларны бетерергә тиеш була. Әгәр кол табылмаса яки аны сатып алырга байлык җитмәсә, 60 көн тоташтан ураза тоту тиеш була. Әгәр дә зәгыйфьлек сәбәпле 60 көн ураза тотарга куәт җитмәсә, 60 фәкыйрьне туярлык итеп ашату кирәк була.

Ураза тоткан кеше хаталык белән бераз аш яки су йотса, бугазына кар яки яңгыр тамчылары керсә, ихтыяры белән авызын тутырып косса; таң аткан булса да, таң атмаган дип белеп сәхәр ашаса, кояш батмаган булса да, кояш баткан дип белеп авыз ачса яки якынлыктан башка җөнеб (госелсез) булса, уразасы бозыла. Андый кешегә Рамазан ае үткәннән соң уразасын каза кылу тиешле була, ә кәффарәт тиеш түгел.

---

[1] Кәффарәт – гөнаһтан арыну өмете белән кылынган яки кылынырга тиешле эш

Уразасы көндез бозылган кеше, кояш батканчы, уразалы кебек ашамый-эчми торырга тиеш.

Бер кешенең бугазына тузан, туфрак, йон, төтен керсә; бер кеше төкреген, какрыгын яки теш арасында калган ризык кисәген йотса; уразалы икәнен онытып ашап-эчсә яки якынлык кылса, ул кешенең уразасы бозылмый.

Хәез һәм нифас белән гозерле булган хатыннарга ураза тоту дөрес түгел. Алар Рамазан аенда тотылмый калган уразаларын Рамазаннан соң каза кылырга тиешләр.

Ураза тотарга көче җитмәгән бик зәгыйфь, карт кеше ураза тотмаса, һәркөннең уразасы урынына бер фәкыйрьне туярлык итеп ашатырга яки ризык алырга җитәрлек акча бирергә тиеш була. Әгәр Рамазан аеннан соң шул карт сәламәтләнсә, калган уразаларын каза кылырга тиеш.

Йөкле яки бала имезә торган хатыннар, ураза тоткан вакытта, үзләренә яки балаларына зыян килүдән һәм хаста кешеләр үзләренең авырулары көчәюдән курыксалар, ураза тотмасалар да дөрес була. Аларның һәркайсы калган уразаларын Рамазаннан соң каза кылырга тиеш була.

Рамазан аенда мосафир булган кешегә дә ураза тотмау рөхсәт ителә. Сәфәреннән кайткач, аңа да калган уразаларын каза кылырга кирәк.

Таң атканнан соң сәфәргә чыккан кешегә мосафир булдым дип, уразасын бозу ярамый. Әгәр бозса, каза кылырга тиеш була.

Ураза тотмаган килеш көндез өенә кайтып кергән мосафирга кояш батканчы уразалы кеше кебек ашамый-эчми тору – мөстәхәб.

Тотылмый калган уразаларын сәламәт вакытта каза кылып бетермәгән кеше авырып китсә, аның тотмый калган уразалары өчен фидия бирүне варисларына васыять итеп әйтүе – вәҗиб.

Әгәр шундый васыять әйткән кеше вафат булса, варисларына калган малының өчтән бер өлешеннән фидия бирү – вәҗиб.

Пәнҗешәмбе һәм дүшәмбе көннәрендә; гашура, рәгаиб, бәраәт һәм гарәфә көннәрендә; зөлхиҗҗә һәм мөхәррәм айларының беренче атнасы көннәрендә һәм һәр яңа туган айның беренче өч көнендә ураза тоту бик саваплы мөстәхәб гамәл булып санала.

Нәфел уразаны да сәбәпсез бозу ярамый. Әгәр бозылса, каза кылу – вәҗиб. Кунак килү яки ашка чакырылу сәбәпле нәфел уразаны өйләгә кадәр бозу рөхсәт ителә, өйләдән соң бозарга ярамый.

Ике гает һәм 3 тәшрикъ көннәрендә ураза тоту, шулай ук җомга яки шимбә көнендә аерым бер көн генә ураза тоту – мәкруһ.

Шәгъбан аеның 30 нчы көнендә ахшам намазыннан соң ай күренмәсә, 30 нчы көнендә ай күрү хәбәрен көтеп, өйлә вакытларына кадәр ураза тоту – мөстәхәб.

Әгәр ай күрү хәбәре килсә, ниятләп уразага керергә кирәк. Ай күрү хәбәре килмәсә, уразаны бозарга кирәк.

Шәгъбан аеның 29 нчы көнендә ай күренмәгән булса, 30 нчы көнендә Рамазан аеннан хисаплап ураза тоту – мәкруһ. Ул көндә нәфел нияте белән ураза тоту дөрес санала.

Кояш баеган вакытта ай күренә торган урында болыт яки тузан булмаса, Рамазан ае башы өчен дә, Шәүвәл ае башы өчен дә күктәге айны күп кешенең күрүе тиешле була, ике-өч кешенең күрүе генә кабул ителми.

Әгәр дә ай күренә торган урында болыт, пар яки тузан булса, Рамазан ае башлануы өчен бер гадел кешенең айны күрүе дә дөрес санала һәм иртәгәсе көндә уразага керелә. Ул кеше ир-ат яки хатын-кыз булса да ярый.

Шәүвәл аеның беренче көне өчен ике гадел ир кешенең йә бер гадел ир һәм гадел бер хатынның айны күрүләре кабул ителә, иртәгесе көндә гайдел-фитыр (Ураза бәйрәме) намазы укыла.

Балигъ һәм акылы булган, зур гөнаһлардан сакланган камил мөселман гадел кешегә хисаплана.

ИГЪТИКЯФ

Рамазан аеның ахыргы ун көнендә ир-атларга бер тәүлек булса да мәчеттә кунып, ә хатын-кызларга өйләрендәге намаз укый торган җирләрендә игътикяф[1] кылу – сөннәт.

Игътикяф кылучы ирләр мәчеттә ашыйлар, эчәләр һәм йоклыйлар. Аларга бәдрәфкә бару, тәһарәт алу кебек мәчеттә үтәү мөмкин булмаган эшләр һәм аш-су алып килү өчен генә мәчеттән чыгу рөхсәт ителә.

Әгәр сәбәпсез дөнья эше өчен мәчеттән чыгып, алты сәгать вакытын читтә үткәрсә, игътикяф бозыла. Игътикяфтагы ирләргә хатыннарының тәннәренә кул тидерү

[1] Игътикяф сүзе берәр изге саналган урыннан (мәчеттән) чыкмый күпмедер вакыт гыйбадәт кылу дигәнне аңлата

хәрам санала. Әгәр алар мәчеттән чыккан вакытларында якынлык кылсалар, игътикяфлары бозыла.

Игътикяфтагы кешеләр мәчеттә намаз, Коръән укыйлар, гыйлем өйрәтәләр һәм өйрәнәләр, зикер, тәсбихләр әйтәләр, китаплар укып, дини мәсьәләләр турында сөйләшеп утыралар. Аларга мәчеттә дөнья эшләрен башкару һәм дөнья мәшәкатьләре турында сөйләшү мәкруһ санала.

ЗӘКЯТ

Хәдис-шәриф

إِنَّ اللهَ افْتَرَضَ عَلَيْهِمْ (أَىْ الْمُؤْمِنِينَ) صَدَقَةً فِي أَمْوَالِهِمْ

تُؤْخَذُ مِنْ أَغْنِيَائِهِمْ وَتُرَدُّ إِلَى فُقَرَائِهِمْ

Иннәллааһә-фтәрада гәләйһим (әй әл-мү’миниинә) садәкатән фии әмүәәлиһим тү’хаҙү мин әгнияя’иһим үә түраддү иләә фүкараа’иһим

Мәгънәсе: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә мөэминнәргә малларыннан зәкят сәдакасын бирүне фарыз кылды. Шул зәкят бай мөэминнәрдән алынып, фәкыйрьләргә таратылыр».

Ислам динендә балигъ һәм акылы булган мөэмин кешегә фарыз булган олуг гыйбадәтләрнең дүртенчесе – һәр елны бер мәртәбә малдан зәкят бирү.

Зәкят фарыз булсын өчен, ул кешенең зәкят чыгара торган малы нисабка тулып аңа (зәкят чыгарлык микъдарга) бер ел хуҗа булуы шарт. Шундый малга хуҗа булганнан соң бер ел узгач, ул кешегә һәр елны бер тапкыр үзенең малыннан зәкят чыгару фарыз була.

ЗӘКЯТ МАЛЛАРЫ

Зәкят микъдары 3 төрле малдан чыгарыла:

1) акчадан;

2) хайваннардан;

3) сәүдә малыннан.

Шушы өч төрле малдан башка, ягъни йортыннан, киемнәреннән, китапларыннан, савыт-сабаларыннан һәм башка төрле көндәлек тормышта кулланыла торган әйберләрдән, шулай ук башка кешегә кулланылышка биреп торган йортлардан; иген, печән һәм урман җирләреннән зәкят бирү фарыз түгел.

Бурычлы кешенең кулындагы малының бурычыннан арткан өлеше генә үзенеке. Бурычын капларга дигән малыннан зәкят бирү фарыз булмый.

Бурычка бирелгән мал – кешенең үз малы. Әгәр ул ышанычлы кешедә булып, сәнәд[1] белән алу мөмкин булса, хуҗасы аннан да зәкят бирергә тиеш.

[1] Сәнәд – вексель кебек бер документ.

Алтын һәм көмеш акча да мал хисабына керә. Тәңкә итеп сугылган яки сугылмаган, бер зиннәтле әйбер итеп эшләнгән яки үзеннән кимрәк бакыр белән катышкан булса да, алтын һәм көмештән зәкят бирү фарыз.

Алтын һәм көмеш урынына кулланылу сәбәпле, бакыр акчадан һәм хәзинәдә саклана торган акчаның сәнәде булганы өчен, кәгазь акчадан да зәкят чыгарылырга тиеш.

Зәкят чыгарылырга тиеш булган хайваннар: куй, сарык, кәҗә, сыер, дөя, ат кебек йорт хайваннары. Җәй көне кырда даими ашап йөри торганнарыннан зәкят чыгарыла. Йорт хезмәтендә булган хайваннардан зәкят чыгарылмый. Ишәк, качыр, болан һәм кыр кәҗәсе кебек хайваннардан зәкят чыгарылмый.

Сәүдә малы – сатарга дип ният кылынган нинди дә булса хәләл мал.

НИСАБ (ЗӘКЯТ МАЛЫНЫҢ КҮЛӘМЕ)

Нindидер малдан зәкят бирү фарыз булсын өчен, аның күләме нисаб кадәр булуы шарт, шушы күләмдә булмаган малдан зәкят бирү фарыз түгел.

Зәкят чыгарыла торган малларның нисаблары төрле. Мәсәлән, алтынның нисабы – 20 мыскал[1], көмешнең нисабы – 140 мыскал. Куй, сарык һәм кәҗәнең нисабы – 40 баш. Сыерның нисабы – 30 баш. Дөянең нисабы – 5 баш. Атның нисабы – (берсе байтал булу шарты белән) 2 баш.

---

[1] Мыскал – үлчәү системасы кертелгәнгә кадәр якынча 4,26 граммга тигез булган авырлык үлчәү берәмлеге (кадакның 1/98 өлеше)

Сәүдә малының нисабы – аның көмеш нисабы кадәр булуы.

Малның зәкяткә бирелә торган өлеше – барлык малның кырыктан бер өлеше чамасы. Мәсәлән, 20 мыскал алтыннан ярты мыскал кадәр зәкят бирелергә тиеш. 140 мыскал көмештән өч мыскал ярым кадәр бирелә. Бакыр акча, кәгазь акча һәм сәүдә малы көмеш бәясе белән хисапланыла.

Әгәр кешенең алтыны нисабка тулмаса, көмеш, бакыр, кәгазь акчалар һәм сәүдә маллары бергә кушылып хисапланыла. Әгәр бөтен малының бәясе көмеш нисабына тулса, бәяләренең кырыктан бер өлешен зәкяткә бирергә тиеш.

Кырык сумлык малдан зәкяткә бер сум, 100 сумнан – 2 сум 50 тиен, 1000 сумнан – 25 сум бирелә.

Кырык куй, сарык һәм кәҗә өчен бер куй бирелә. Кырыктан артык булганда һәр йөз куй өчен бер куй бирелә.

Утыз сыер өчен бер яшьлек бер бозау, 40 сыер өчен ике яшьлек бер бозау, 30дан һәм 40тан артканнарының һәрберсе өчен бер яшьлек бозау бәясенең 30дан бер өлеше бирелә. Мәсәлән, бер яшьлек бозауның бәясе 15 сум чамасы булганлыктан, нисабтан арткан сыерларның һәрберсе өчен 50 тиен чамасы бирелергә тиеш.

Баш саны егерме дүрткә җиткәнче, һәр биш дөя өчен бер куй, 25 дөя өчен бер яшьлек дөя баласы бирелә.

Атларның һәрберсенең бәясеннән кырыктан бер өлеше зәкяткә бирелә.

Зәкят өчен тиешле булган куй, бозау һәм дөя баласы урынына зәкяткә тиешлесенең бәясе хәтле акча бирү дә дөрес була.

Ел башында нисаб кадәр малга хуҗа булган кешенең ел тулганчы шул малы артса (күбәйсә), ул кешегә барлык малыннан зәкят бирү фарыз була. Соңыннан арткан маллары өчен, ел тулмаса да, зәкят бирергә тиеш.

ЗӘКЯТ БИРЕЛӘ ТОРГАН КЕШЕЛӘР

Зәкятне кулында нисаб күләме кадәр малы булмаган фәкыйрь һәм мескен кешеләргә бирергә кирәк.

Йортында малы булуга да карамастан, мосафирга һәм кулында нисаб күләме кадәр малы булып та, бурычы зур булган кешегә, бурычын түләргә ярдәм йөзеннән, зәкят бирелә.

Зәкят сәдакасы зәкят җыярга дип билгеләнгән кешегә дә бирелә. Ул җыйган зәкят акчасын фәкыйрьләргә тиешле булган казнадагы акчага куша. Хезмәт хакы буларак, әлеге кеше бай булса да, зәкят җыючыга җыелган малдан бер өлеш бирелә.

Зәкятне үз ата-анаңа, әби-бабаңа, балаларыңа, оныкларыңа, иреңә яки хатыныңа, шулай ук кулында нисаб күләме кадәр малы булган бай кешегә һәм бай кешенең яшь баласына бирергә ярамый. Бирелгән очракта ул зәкяттән китми, ә бүләк хөкемендә генә кала.

Зәкятне фәкыйрь кардәшләреңә, ярлы шәкертләргә, мохтаҗ тол хатыннарга, кәсепсез зәгыйфь кешеләргә бирү

хәерле. Дин һәм гыйлем юлында (гыйлем өйрәнүчеләр) булып, кәсептән мәхрүм булган кешеләргә, гәрчә кулларында нисаб күләме кадәр маллары күренсә дә, зәкят бирү дөрес була, чөнки алар хезмәтләрен ташлап кәсепкә тотынганчы, фәкыйрь кеше хөкемендә саналалар.

Малны зәкят итеп бирүне ният кылу һәм алучының кулына тулысынча тапшыру зарур. Зәкят нияте белән тапшырылмаган мал зәкят булып саналмый.

Әгәр мал зәкяткә дип алдан билгеләнгән булса, биргән вакытта зәкяттән дип ният кылынмаса да, зәкяттән хисаплана.

Зәкят суммасын аерым җыеп, фәкыйрьләрнең үз кулларына тапшыра торган Җәмгыяте Хәйрияләргә (Хәйрия оешмаларына) дә зәкят бирү дөрес. Бу очракта Җәмгыятьнең казначысы зәкят бирүченең вәкиле хөкемендә була.

ГОШЕР

(ЖЫЕЛГАН УНЫШНЫҢ САЛЫМЫ)

Яңгыр яки елга суы белән үскән ашлыклардан, җимешләрдән, печәннән һәм балдан бирелә торган зәкят гошер дип атала. Шул нигъмәтләргә ия булган кешегә, елга бер мәртәбә, аның уннан бер өлешен казна хәзинәсенә яки фәкыйрьләргә бирү – фарыз.

Гошер малларының нисабы юк: никадәр булса, шулкадәренең уннан бер өлеше гошер итеп бирелә. Игү, уру һәм чәчүлекне карау чыгымнары исәпләнми.

Гошер бирү өчен балигъ, акыллы һәм бай булу шарт түгел. Сабый, акылга зәгыйфь һәм фәкыйрь кешеләрнең ашлыкларыннан да гошер чыгарыла.

Утын һәм камыш кебек нәрсәләрдән гошер чыгарылмый.

Яңгыр күп яумый торган җирләрдә, чыгыр һәм чиләк белән сугарылган ашлыклардан камил гошер бирелми, ә гошернең яртысы гына, ягъни егермедән бер өлеше генә бирелә.

Гошер дә зәкят бирелә торган фәкыйрь кешеләргә генә тапшырыла.

ФИТЫР

Көндәлек тормышта кулланыла торган әйберләрдән тыш көмеш нисабы кадәр малы булган кешегә Рамазан аеннан соң, Гайдел-фитыр (Ураза гаете) көнендә үзе һәм сабый балалары өчен фитыр сәдакасын бирү – вәҗиб.

Ирнең хатыны һәм балигъ булган балалары бай булса, фитыр аларның үзләренә вәҗиб була, әгәр фәкыйрь булсалар, һичкемгә вәҗиб булмый.

Әгәр берәү хатыны, олы балалары һәм хезмәтчеләре өчен фитыр сәдакасын үзе бирсә, саваплы була.

Авырлык белән яши торган фәкыйрь кешеләргә фитыр сәдакасын бирү вәҗиб түгел. Әгәр бирергә теләсәләр, үзләреннән дә фәкыйрьрәк кешеләргә бирергә тиеш булалар.

Фитыр сәдакасын Гайдел-фитыр көнендә таң атканнан соң Гает намазы укылганчы бирү саваплырак, чөнки

бәйрәмне тояр өчен акчасы булмаган фәкыйрьләрне бәйрәм башланганчы шатландыру хәерлерәк. Фитыр сәдакасын Рамазан ае барышында ук биреп куяргa да мөмкин. Гает укылганчы бирә алмый калган кеше соңыннан бирергә тиеш була.

Зәкят һәм гошер кебек, Фитыр сәдакасы да фәкыйрь кешеләргә генә бирелә.

Фитыр сәдакасы өчен (һәр кеше исәбеннән) байлыгы уртача булган кеше 4 кадак чамасы бодай яки 8 кадак чамасы арпа бирергә, ә баерак кеше 4 кадак чамасы хөрмә яки 8 кадак чамасы йөзем бирергә тиеш. Бодай, арпа, хөрмә, йөзем урынына аларның бәяләре кадәр акча бирергә дә мөмкин.

ФИДИЯ

Казага калып та, соңыннан үтәлмәгән уразалары булган кешегә, үзеннән калачак малыннан (тотылмаган уразалары өчен) фидия бирергә варисларына әйтү – вәҗиб.

Әгәр шундый васыять әйткән кеше вафат булса, калган малының өчтән бер өлешен, каза кылынмый калган уразалары өчен дип, фидия итеп бирү варисларына вәҗиб була.

Фидиянең микъдары – һәркөн тотмый калган ураза, биш вакыт намазның һәрберсе һәм витр намазы өчен бер фитыр сәдакасы кадәр.

Вакытында тоткан уразалар, укылган намазлар, соңыннан каза кылынган уразалар һәм намазлар өчен фидия бирелми. Шулай да шикләнмәс өчен бирүнең зарары юк. Күп кенә варислар, мәетнең балигъ булган чорын-

нан башлап, үлгән вакытына кадәр фарыз булган ураза һәм намазларын хисаплап, һәммәсе өчен фидия бирәләр.

СӘДАКА

Зәкят, гошер, фитыр, фидия һәм кәффарәт сәдакалары – фәкыйрьләр хакы булган фарыз һәм вәҗиб сәдакалар булып санала. Аларны мөэмин һәм фәкыйрь булмаган кешегә бирү, шулай ук юл төзәтү, күпер эшләтү, кое һәм чишмәләр ясату, мәчет-мәдрәсәләр салдыру кебек халык файдасы өчен булган гомуми эшләргә тотарга ярамый.

Алда әйтелгәннәрдән башка сәдакалар һәм халык файдасы өчен тотылган акчалар нәфел сәдакалары булып санала. Нәфел сәдакалары бирү бик саваплы мөстәхәб гамәл.

Сәдаканы күп бирү гөнаһларның гафу ителүенә, бәла һәм афәтләрдән имин булуга сәбәп була.

Фәкыйрь һәм мохтаҗ булу сәбәпле сәдака сораучыга каты сүз әйтеп рәнҗетү – хәрам. Аз булса да, берәр нәрсә бирергә яки яхшы сүз белән җавап кайтарырга кирәк.

Күпмедер көн яшәргә ризыгы яки акчасы булган кешегә сәдака сорау – хәрам, әмма кием-салым кебек зарур булган нәрсәне сорау – хәрам түгел.

Мохтаҗ булмаган кешегә сәдака биреп, аны теләнчелеккә гадәтләндерү – мәкруһ.

Сәдака алынганнан соң, бирүчегә хәер теләп, түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ احْفَظْ صَاحِبَ هَذِهِ الصَّدَقَةِ عَنِ الْأَفَاتِ وَالْبَلَيَاتِ

وَاغْفِرْ ذُنُوبَهُ وَأَكِّدْ إِيمَانَهُ وَاَكْثِرْ أَمْوَالَهُ وَوَفِّقْهُ عَلَى خَيْرِ مَقَاصِدِهِ

Әл-лааһүммәхфәҙ саахибә һәҙиһис-садәкати гәнил-әфәәти үәл-бәләййәәти үәгъфир ҙүнүүбәтән үә әккид иимәәнәһү үә әкҫир әмүәәләһүү үә үәффикъһү гәләә хайри мәкаасыйдиһ

Мәгънәсе: «Йә Рабби, ошбу сәдака бирүчене афәтләрдән һәм бәлаләрдән сакла һәм шулай ук аның гөнаһларын гафу ит. Аның иманын куәтлә, малын арттыр һәм аңа хәерле максатларына ирешергә насыйп ит».

КОРБАН

Көндәлек тормышта кирәк булган әйберләрдән тыш, көмеш нисабы кадәр малы булган кешегә, зөлхиҗҗә аеның 10нчы көнендә Корбан гаете намазыннан соң, үзенең исеменнән корбан[1] чалып, гаиләсен һәм фәкыйрьләрне хөрмәтләү – вәҗиб.

Зөлхиҗҗә аеның 10нчы көнендә Корбан чалынмый калса, аны 11нче һәм 12нче зөлхиҗҗәдә чалырга рөхсәт ителә, әмма 12нче зөлхиҗҗәдә кояш батканнан соң чалу дөрес булмый.

---

[1] Корбан сүзе гарәпчәдән «якынаю», «якын булу» дип тәрҗемә ителә. Бу мөбарәк бәйрәм көнендә Гает намазлары укып, Аллаһы ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылып Аллаһының рәхмәтенә якынаябыз

Вакытында чалынмаган корбанлык яки аның бәясе фәкыйрьләргә сәдака итеп бирелергә тиеш.

Кич белән яки төнлә корбан чалу – мәкруһ.

Корбанга куй, сарык, кәҗә, сыер, дөя кебек пар тояклы хайваннар гына чалына. Ат кебек хайваннар, тавык, каз ише кошлар корбанга ярамый.

Куй, сарык һәм кәҗә – һәрберсе берәр генә кеше исеменнән корбан ителә, ә сыер яки дөяне җиде кеше исеменнән корбан чалу рөхсәт ителә.

Корбанга дигән куй, сарык яки кәҗәгә бер яшь, сыерга ике яшь һәм дөягә биш яшь тулган булырга тиеш.

Корбанлык мал зур һәм симез булса, алты айлык куй һәм сарыкны корбан итеп чалырга да мөмкин, әмма бер яше тулмаган кәҗәне корбанга чалу ярамый.

Җиде кеше исеменнән сыер яки дөяне корбан итеп чалганда, ул кешеләрнең һәркайсы Корбан гамәлен күңеле белән ниятләргә тиеш.

Әгәр араларыннан берсе корбанлыкны ит өчен генә дип ниятләсә, һичкемнең өлеше корбаннан саналмый.

Җиде кешенең берсе бала булса да, хайванны корбан чалу дөрес була. Мәет исеменнән чалынган корбан өлешен сәламәт кешеләрнең корбан өлешенә катыштыру шөбһәле санала.

Савабын бер мәет исеменә багышлау нияте белән аның исеменнән корбан чалу дөрес була.

Җиде кеше исеменнән хайван корбан чалынганда аның итен үлчәп бүләргә кирәк, кисәкләп бүлү дөрес саналмый.

Бай кешегә корбан итен өч кисәккә бүлеп, бер өлешен фәкыйрьләргә өләшү, икенче өлеше белән кунакларны сыйлау һәм өченче өлеше белән гаиләсен хөрмәтләү (шатландыру) – мөстәхәб.

Бай булмаган кеше корбан ите белән үз гаиләсен генә тукландырырга да мөмкин.

Корбанның тиресен яки шул тиренең бәясен фәкыйрь кешегә сәдака итеп бирү – мөстәхәб. Корбанның тиресен сатып, акчасын үз кирәгенә тоту ярамый, әмма сатмыйча күн яки тун тегү рөхсәт ителә.

Ир кешегә корбанлыгын үзе чалу – мөстәхәб. Шулай ук башка бер мөселманга тапшыру да рөхсәт ителә.

Хайванны чалыр алдыннан, корбанлыкның иясе яки суючы яткан хайванга карап, түбәндәге доганы укый:

اَللَّهُمَّ إِنَّ صَلَاتِى وَنُسُكِى وَمَحْيَاىَ وَمَمَاتِى لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

لَا شَرِيكَ لَهُ اَللَّهُمَّ تَقَبَّلْ هَذِهِ الْأُضْحِيَّةَ

(مِنْ فُلَانِ بْنِ فُلَانْ) أَوْ (مِنْ فُلَانَةِ بِنْتِ فُلَانْ)

Әллааһүммә иннә саләәтии үә нүсүкии үә мәхйәәйә үә мәмәәтии лил-лääһи раббил-гәәләминә ләә шәриикә ләһ. Әллааһүммә тәкаббәл һәәҙиһил-удхиййәтә (мин фүләәни ибни фүләән) әү (мин фүләәнәтә бинти фүләән)

Мәгънәсе: «Йә Рабби, дөреслектә, минем намазым һәм гыйбадәтләрем, тереклегем һәм үлемем барча галәмнәрнең хуҗасы Аллаһы Тәгалә өчен, Аның һичбер

тиңдәше юк. Йә Рабби, ошбу корбанны фәлән-фәлән улыннан яки фәлән-фәлән кызыннан кабул ит».

Корбан чалачак кешегә, хаҗиларга охшау өчен, зөлхиҗҗә ае кергәннән соң чәчен алдырмыйча һәм тырнакларын кисмичә тору – мөстәхәб.

Корбанлык өчен ак яки күк төсендәге, бөтен әгъзалары камил, сәламәт, зур мөгезле симез тәкә хәерлерәк санала.

Тилергән, корчаңгы, тумыштан мөгезсез яки печтерелгән хайваннар да корбанлыкка ярый.

Бик ябык, йөри алмаслык аксак; бер колагының, бер мөгезенең яки койрыгының өчтән бер өлеше киселгән; бер күзе сукыр, колаксыз яки койрыксыз хайваннар корбанлыкка ярамый.

ХАЖ

Хәдис-шәриф

بُنِيَ الْإِسْلَامُ عَلَى خَمْسٍ: شَهَادَةُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ

وَأَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللهِ وَإِقَامِ الصَّلَاةِ وَإِيتَاءِ الزَّكَاتِ وَصَوْمِ رَمَضَانَ

وَحَجِّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلًا

Бүниял-исләәмү гәләә хамсин: шәһәәдәтү ән-ләә иләәһә илләллааһү үә әннә Мухәммәдәр-расүүлүл-

лааһи үә икаамис-саләәти үә иитәә'из-зәкәәти үә сауми рамадаанә үә хәҗҗил-бәйти мәни-стәтаагә иләйһи сәбииләә

Мәгънәсе: «Ислам дине биш терәккә нигезләнгән: Аллаһы Тәгаләнең берлегенә һәм Мөхәммәд ﷺ Аның пәйгамбәре булуына күңелдән гуаһлык бирү, намаз уку, малдан зәкят бирү, Рамазан аенда ураза тоту һәм мөмкинлеге булган кешегә Кәгъбәтулланы зыярәт итеп хаҗ кылу».

Ислам динендә балигъ һәм акылы булган мөэмин кешегә фарыз булган олуг гыйбадәтләрнең бишенчесе – гомерендә бер мәртәбә Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып, хаҗ гамәлен кылу.

Сәламәт булып, Мәккәи Мөкәррәмәгә барып кайтырлык мөмкинлеге һәм үзе кайтканчы өендә калган гаиләсенә җитәрлек малы булган бай кешегә генә хаҗ гыйбадәте фарыз.

Ире яки мәхрәм кардәше[1] белән бергә барса, бай һәм сәламәт хатыннарга да хаҗ фарыз була.

Авыру, сукыр һәм фәкыйрь кешеләргә хаҗ гамәле фарыз түгел. Әгәр мондый кешеләр Мәккәи Мөкәррәмәгә ниндидер сәбәп белән барсалар яки Мәккә якларында тору сәбәпле хаҗ кылырга көчләре җитәрлек булса, аларга да хаҗ гамәле фарыз була.

Хаҗ сәфәренә чыкканда, барыр юлларының урлаучы-талаучылардан, төрле йогышлы авырулардан имин булуы

[1] Мәхрәм кардәш – өйләнешергә тыелган якын кардәш

шарт. Әгәр юллар тынычсыз булса, хаҗ кылу фарыз түгел. Юллар тынычланганчы, бай кешеләр дә хаҗ сәфәрен кичектереп тора алалар. Фарыз булганнан соң, гозерсез килеш хаҗ гамәлен кичектерергә ярамый.

Хаҗның фарызлары өч:

1) ихрам, ягъни Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып кергәнче, «Микат» дип атала торган урыннарның берсендә хаҗ нияте белән ихрамга керү;

2) вәкыф, ягъни Гарәфә көнне өйләдән соң Гарәфәт тавында басып тору;

3) тәваф, ягъни Корбан гаете көнендә яки аның 2нче йә 3нче көнендә Кәгъбәтулланы билгеле рәвештә 7 мәртәбә әйләнеп чыгу.

Хаҗның вәҗибләре биш:

1) Корбан гаете көнендә иртәнге намаздан соң «Мөздәлифә» исемле урында булу;

2) Сафа һәм Мәрвә таулары арасында йөреп 7 мәртәбә сәгыя кылу;

3) таш атыла торган урыннарда, билгеле бер көннәрдә 7 шәр таш ату;

4) өйгә кайту нияте белән Мәккәи Мөкәррәмә шәһәреннән чыгар алдыннан Кәгъбәтулланы янә тәваф кылу;

5) Корбан гаете көнендә фарыз тәвафны кылганнан соң чәчне алдыру (кыру) яки кыскарту.

Хаҗның болардан башка гамәлләре дә күп: аларның кайберләре – сөннәт, ә кайберләре – мөстәхәб.

ХАЖ ГАМӘЛЛӘРЕ

Хаҗилар Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып җиткәнче, «Микат» дип атала торган җирләрнең берсендә туктап, мыекларын кыскарталар, тырнакларын кисәләр, тәннәрендәге артык төкләрен кыралар, гадәттәге киемнәрен салалар, аннары госел коенып, ихрам[1] киемнәрен кияләр.

Ике рәкәгать нәфел намазын укыгач:

اَللَّهُمَّ إِنِّى أُرِيدُ الْحَجَّ فَيَسِّرْهُ لِى وَتَقَبَّلْهُ مِنِّى

«Әллааһүммә инниии үриидүл-хәҗҗә фәйәссирһү лии үә тәкаббәлһү минниии»,

– дип хаҗ гамәленә ният кылалар.

Мәгънәсе: «Йә Рабби, дөреслектә, мин хаҗ кылуны ният кылам, миңа хаҗ кылуны җиңеләйт һәм хаҗ гыйбадәтемне кабул ит».

Хаҗ гамәленә ният кылганнан соң, кычкырып түбәндәге «Тәлбия»не әйтәләр:

---

1 Ихрам киеме изар дип аталган киң алъяпкыч белән рида исемле киң җаймәдән гыйбарәт. Хаҗилар изарны кендектән билләренә багълап гаурәтләрен каплыйлар. Риданы иңбашларына һәм аркаларына салалар.

لَبَّيْكَ اللَّهُمَّ لَبَّيْكَ لَبَّيْكَ لَا شَرِيكَ لَكَ لَبَّيْكَ

إِنَّ الْحَمْدَ وَالنِّعْمَةَ لَكَ وَالْمُلْكَ لَا شَرِيكَ لَكَ

Ләббәйкәл-лааһүммә ләббәйкә, ләббәйкә ләә шәриикә ләкә ләббәйәкә, иннәл-хәмдә үән-нигмәтә ләкә үәл-мүлкә, ләә шәриикә ләк

Мәгънәсе: «Йә Рабби, мин Синең каршыңда, мин Синең каршыңда, Синең һичбер тиңдәшең юк. Дөреслектә, барча мактау һәм нигъмәт Сиңа хас һәм хуҗалык та Сиңа хас. Синең бернинди тиңдәшең юк».

Шушы «Тәлбия»не укыганнан соң, хаҗилар «мохрим», ягъни «ихрамлы» дип аталалар. Алар ихрамлы хәлдә Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә китәләр, Корбан гаете көнендә чәчләрен алдырып (кыскартып), фарыз булган тәвафны кылганчы ихрамда йөриләр.

Ихрамда вакытта хаҗиларга әдәпсез сүзләр сөйләү, якынлык кылу, хатыннарының тәннәренә һәвәслек белән кул тидерү, гөнаһлы эшләр кылу, кеше белән бәхәсләшү, киек хайваннарны үтерү, аучыларга ярдәм итү, энә белән тегелгән киемнәр кию, башка чалма, бүрек йә фәс кию, башны яки йөзне нәрсә белән булса да каплау, хуш исле майлар сөртү, баштагы чәчне кисү, тәндәге төкләрне кыру һәм тарау, тырнак кисү, сакалны майлау, башны сабынлап юу тыела.

Олуг китапларда аңлатылганча, әгәр хаҗилар шул эшләрнең берәрсен башкарсалар, аларга корбан чалу яки сәдака бирү мәҗбүри була.

Һәрбер хаҗи Корбан гаете көннәрендә ихрам халәте тәмамланганчы яланаяк, яланбаш килеш ак ихрам киемнәрен чорнап, дәрвиш сыман йөрергә һәм «Тәлбия» укыла торган урыннарда кычкырып «Тәлбия» укырга тиеш.

Югарыда язылган хөкемнәр ир-ат хаҗиларга карата иде. Хаҗ кылучы хатыннар (хаҗҗәләр) хаҗ бурычларын үтәгәндә алты төрле гамәлдә ирләрдән аерылалар:

1) ихрам киемнәрен кимичә үз киемнәре белән йөриләр;

2) энә белән тегелгән киемнәрне дә кияләр;

3) башларын ачык йөртмиләр;

4) «Тәлбия»не кычкырып укымыйлар;

5) ихрам халәтеннән чыкканда чәчләрен кыскартмыйлар;

6) хәез сәбәпле гозерле булсалар, фарыз тәвафны казага калдыралар.

Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып кергәч хаҗилар иң беренче «Кәгъбәи Мөгаззәмә» (Хәрам) мәчетенә юнәләләр. Кәгъбәне күргәч тәкбир һәм тәһлил әйтәләр, аннары максатларын сорап дога кылалар.

Мәчеткә кергәннән соң, Кәгъбәнең диварындагы «Хәҗәре Әсвәд» исемле мөбарәк ташны күргәч, намаздагы кебек кулларын колаклар турысына күтәреп, янә тәкбир һәм тәһлил әйтәләр (мөмкин булса, ул ташны үбәләр).

Җиде мәртәбә Кәгъбә тирәли әйләнеп, сөннәт булган тәвафны кылалар, аннары «Мәкам Ибраһим» дигән җирдә Кәгъбәгә карап, ике рәкәгать намаз укыйлар, соңыннан шул мәчет эчендәге «Зәм-зәм» коесы янына килеп, аның суын эчәләр, йөзләренә һәм башларына сибәләр.

Мәчеттән чыккач, Сафа һәм Мәрвә исемле ике кечкенә тау арасында йөреп, сәгыя кылалар.

Зөлхиҗҗә аеның 8 нче көненә кадәр Мәккә шәһәрендә торалар, теләгән кадәр тәваф һәм сәгыя кылалар, изге урыннарны зыярәт итәләр.

Зөлхиҗҗә аеның 8 нче көнендә иртә таңнан хаҗиларның һәрберсе Мәккәи Мөкәррәмә шәһәреннән чыгып, Мина исемле бер авыл янындагы мәчет тирәсенә баралар.

Мина мәчете янында бер кич кунганнан соң, зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көнендә иртәнге намазны укыгач, Гарәфәт тавына китәләр, өйлә вакыты кергәч, җәмәгать булып, башта өйлә намазын, аннан соң шул вакытта ук икенде намазын да укыйлар.

Госел коенып, Гарәфәт тавына басып, кыйблага каршы торып зикер әйтәләр һәм максатларын сорап дога кылалар.

Кояш баеганнан соң, ахшам намазын укымыйча гына, «Мөздәлифә» исемле җиргә китәләр. Ястү вакыты кергәч, «Мөздәлифә»дә җәмәгать булып, әүвәл ахшам намазын, аның артыннан ук ястүне укыйлар.

Кичне «Мөздәлифә»дә үткәреп, иртәнге намазны укыганнан соң, анда янә басып торалар.

Таң яктырганнан соң, янә Минага кайтып, андагы махсус урында җиде мәртәбә таш аталар (һәр ташны атканда тәкбир әйтәләр), аннан соң ите исраф кылынмаса, Минада корбан чалып, сәдака бирәләр.

Ир-атлар чәчләрен алдыралар яки кыскарталар.

Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы, 11 нче яки 12 нче көннәрендә Мәккәи Мөкәррәмәгә кайтып, фарыз булган тәвафны кылып, ихрам халәтеннән чыгалар.

Ихрам халәтеннән чыканнан соң, алар ихрамлы вакытларында рөхсәт ителмәгән гөнаһсыз эшләрне үтәргә мөмкиннәр.

Мосафир булган хаҗиларга Гает намазын уку вәҗиб түгел, шуның өчен хаҗиларның күбесе Гает намазын укымыйлар. Әгәр Гает намазына өлгерсәләр, Мәккә шәһәрендә яки Минада укыйлар.

Хаҗилар, Мәккәи Мөкәррәмәдән чыгып, өйләренә кайтканчы Кәгъбә мәчетенә барып, янә тәваф кылалар, Кәгъбә ишегенең бусагасын үбәләр, Кәгъбәнең «Мөлтәзәм» исемле җиренә һәм аның пәрдәсенә йөзләрен

тидерәләр, зәм-зәм суын эчәләр, «Кәгъбәи Мөгаззәмә»дән һәм мөбарәк җирләрдән аерылачакларын күз алдына китереп елыйлар, дөнья һәм ахирәт максатларын сорап догалар кылалар, мәчеттән чыкканда йөзләре белән Кәгъбә ягына карап, артка таба чигенеп чыгалар.

Хаҗиларга, Мәдинәи Мөнәвәрәгә барып, пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең шәрифле кабере булган Рәүзаи Мотаһһәрәне зыярәт кылу – олы мөстәхәб.

Мәккәи Мөкәррәмәдә дә, Мәдинәи Мөнәвәрәдә дә зыярәт кыла торган җирләр һәм мөбарәк урыннар бик күп. Аларны зыярәт иткәндә игътибарга алырга кирәк булган махсус кагыйдәләр дә бар.

Алда әйтелгән ике шәһәрнең һәрберсендә хаҗиларга хаҗ гамәлләрен өйрәтү һәм зыярәт итәргә мөмкин булган мөбарәк урыннарны күрсәтү өчен ачык дәлилләр бар. Белемсез хаҗилар үзләре белмәгән гамәлләрне әйтелгән дәлилләрдән өйрәнергә тиеш.

Зәм-зәм суын кыйблага каршы торып, аягүрә өчәр йотым ясап эчү мөбарәк санала.

Зәм-зәм суын эчкәннән соң түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ إِنِّى أَسْئَلُكَ رِزْقًا وَاسِعًا وَعِلْمًا نَافِعًا وَشِفَاءً مِنْ كُلِّ دَاءٍ

Әллааһүммә иннии әс’әлүкә ризкан үәәсигән үә гильмән нәәфигән үә шифәә’ән мин күлли дәә’ин

Мәгънәсе: «Йә Рабби, дөреслектә, мин Синнән киң ризыкны, файдалы гыйлемне һәм һәрбер авырудан шифаны сорыймын».

ТӨРЛЕ ДОГАЛАР

1) Әгәр берәү бала туган хәбәрне ишетсә, түбәндәге доганы укырга тиеш:

اَللَّهُمَّ اجْعَلْهُ بَرًّا وَاَنْبِتْهُ فِى الْإِسْلَامِ نَبَاتًا حَسَنًا

وَاجْعَلْهُ مَسْعُودًا فِى الدُّنْيَا وَالْأَخِرَةِ

Әллаһүммә-җгәлһү бәрран үә әнбитһү фил-исләәми нәбәәтән хәсәнән үәҗгәлһү мәсгүүдән фид-дүн'йә үәл-әәхыраһ

Мәгънәсе: «Йә Рабби, бу баланы изгеләрдән кыл һәм аңа күркәмлек белән Ислам динендә үсәргә насыйп ит, аңа бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле булырга насыйп ит».

2) Бер кешенең үлгәне турында ишеткәндә, түбәндәге аять һәм дога укыла:

إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ اَللَّهُمَّ إِنْ كَانَ هَذَا الْمَيِّتُ

مُحْسِنًا فَزِدْ فِى إِحْسَانِهِ وَإِنْ كَانَ مُسِيئًا فَتَجَاوَزْ عَنْهُ

Иннәә лилләәһи үә иннәә иләйһи рааҗигун. Әллааһүммә ин кәәнә һәәҙәл-мәййиту мүхсинән фәзид фии ихсәәниһи үә ин кәәнә мүсии'ән фәтәҗәәүәз гәнһ

Мәгънәсе: «Дөреслектә, һәркайсыбыз Аллаһы Тәгаләнеке һәм һәркайсыбыз Аллаһы Раббыбызга кайтачакбыз. Йә Рабби, әгәр ошбу мәет изге кеше булса, изгелеген арттыр, әгәр гөнаһлы кеше булса, гөнаһларын гафу кыл».

3) Җеназа узып барганда, аягүрә торып, түбәндәге дога укыла:

اَللهُ أَكْبَرُ أَشْهَدُ أَنَّ اللهَ يُحْيِي وَيُمِيتُ وَهُوَ حَيٌّ لَا يَمُوتُ هَذَا مَا وَعَدَنَا اللهُ وَرَسُولُهُ وَصَدَقَ اللهُ وَرَسُولُهُ اَللَّهُمَّ زِدْنَا إِيمَانًا وَتَسْلِيمًا

Әллааһү әкбәр (3 мәртәбә). Әшһәдү әннәл-лааһә йүхйии үә йүмиитү үә һүә хәййүн ләә йәмүүт. Һәәҙәә мәә үәгәдәнәл-лааһү үә расүүлүһ. Үә садәкал-лааһү үә расүүлүһ. Әллааһүммә зиднәә иимәәнән-үә тәслиимәә

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәдән олуграк. Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, тереклек тә, үлем дә Аллаһы Тәгаләнеке. Аллаһы Үзе тере, һичкайчан үлмәячәк. Бу үлем безгә Аллаһы Тәгаләнең һәм Аның расүленең вәгъдәсе. Аллаһы Тәгалә һәм Аның расүле дөресен әйттеләр. Йә Рабби, иманыбызны һәм итагатьлегебезне арттыр».

4) Зиратка кергәндә һәм каберләр яныннан узганда түбәндәге дога укыла:

عَلَيْكُمُ السَّلَامُ يَا أَهْلَ الدِّيَارِ رَحِمَ اللهُ الْمُسْتَقْدِمِينَ

مِنَّا وَالْمُسْتَأْخِرِينَ مِنْكُمْ أَنْتُمْ لَنَا سَلَفٌ وَنَحْنُ لَكُمْ خَلَفٌ

وَإِنَّا إِنْ شَاءَ اللهُ بِكُمْ لَاحِقُونَ نَسْئَلُ اللهَ تَعَالَى لَنَا وَلَكُمُ الْعَافِيَةَ

Галәйкүмүс-сәләәмү йәә әһләд-дияяри рахимәл-лааһүл-мүстәкъдимиинә миннәә үәл-мүстә’хыриинә минкүм. Әнтүм ләнәә сәләфүн үә нәхнү ләкүм халәф. Үә иннәә ин-шәә’-әллааһү бикүм ләәхикуун. Нәс’әлул-лааһә тәгәәләә ләнәә үә ләкүмүл-гәәфийәһ

Мәгънәсе: «Әй бу йортларның әһелләре (кабердә ятучылар), сезгә Аллаһы Тәгаләнең сәламе булсын. Аллаһы Тәгалә сезгә дә һәм безгә дә Үз рәхмәтен ирештерсен. Сез безгә кадәр булган кешеләр, без сездән соң калган кешеләр. Ин шә Аллаһ (Аллаһ теләсә), әлбәттә, без дә сезгә тоташачакбыз. Үзебез өчен дә, сезнең өчен дә Аллаһы Тәгаләдән сәламәтлек сорыйбыз».

5) Коръән укып, савабын әрвахларга багышлаганда, түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ بَلِّغْ ثَوَابَ مَا قُرِئَ فِي هَذِهِ السَّاعَةِ الشَّرِيفَةِ مِنْ كِتَابِكَ

الْكَرِيمِ إِلَى أَرْوَاحِ جَمِيعِ الْأَمْوَاتِ الْمُسْلِمِينَ كَافَّةً وَعَامَّةً

خُصُوصًا مِنْهُمْ إِلَى أَرْوَاحِ أَقْرِبَائِى الَّذِينَ أَذْكُرُهُمْ بِلِسَانِى

Әллааһүммә бәллигъ ҫәүаабә мәәкүри'ә фии һәәҙиһис-сәәгәтиш-шәриифәти мин китәәбикәл-кәриими иләә әрүаахи җәмиигил-әмүәәтил-мүслимиинә кәәффәтән үә гәәммәтән хусуусан минһүм иләә әрүәәхи әкрибәә'иял-ләҙиинә әҙкүрүһүм билисәәнии

Мәгънәсе: «Йә Рабби, шушы кадерле сәгатьтә укылган хөрмәтле Китабыңнан хасил булган савабын һәрбер мөселман мәетләрнең җаннарына ирештер, бигрәк тә (аеруча) хәзер телем белән санап үтәчәк якын мәетләремнең җаннарына да ирештер».

Бу сүзләрдән соң Коръән укучы үзенең вафат булган якын кешеләренең исемнәрен, аталарының исемнәре белән берәм-берәм әйтеп чыга. Мәсәлән, түбәндәгечә:

«Йә Рабби, хәзер укылган Коръән аятьләреннән хасил булган савапларны атам фәлән-фәлән улының, анам фәлән-фәлән кызының, абыем фәлән-фәлән улының һәм дустым фәлән-фәлән улының рухларына ирештер».

6) Ашау-эчү тәмамланганнан соң, түбәндәге дога укыла:

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِى أَطْعَمَنِى وَسَقَانِى وَجَعَلَنِى مِنَ الْمُسْلِمِينَ

Әлхәмдү лилләәһил-ләҙи әтъгәмәнии үә сәкаании үә җәгәләнии минәл-мүслимиин

Мәгънәсе: «Әлһәмдүлилләһ (Аллаһыга мактау булсын), Аллаһ мине ашатты һәм эчертте, мөселманнардан кылды».

7) Бер кеше белән күрешкәч, түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ اجْمَعْ بَيْنَنَا بِالْخَيْرِ وَالسَّلَامِ وَأَلِّفْ بَيْنَنَا بِأَحْسَنِ الْكَلَامِ

Әллааһүммә-җмәг бәйнәнәә бил-хайри үәс-сәләәми үә әллиф бәйнәнәә би-әхсәнил-кәләәм

Мәгънәсе: «Йә Рабби, безне изгелек һәм сәламәтлек белән күрештер һәм күркәм сүзләр белән тоташтыр».

8) Берәр хәерле җиргә барып кергәч яки берәр мәҗлескә килгәннән соң түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ اَنْزِلْنِي مُنْزَلًا مُبَارَكًا وَأَنْتَ خَيْرُ الْمُنْزِلِينَ

Әллааһүммә әнзилнии мүнзәлән мүбәәракән үә әнтә хайрүл-мүнзилиин

Мәгънәсе: «Йә Рабби, мине мөбарәк җиргә иңдер. Син иң хәерле иңдерүче».

9) Берәр зарар яисә зыян килсә, түбәндәге дога укыла:

عَسَى رَبُّنَا أَنْ يُبْدِلَنَا خَيْرًا مِنْهَا إِنَّا إِلَى رَبِّنَا رَاغِبُونَ

Гәсәә раббүнәәән йүбдиләнәә хайран минһәә инәә иләә раббинәә раагибүүн

Мәгънәсе: «Шаять Раббыбыз Аллаһ безнең хәлебезне яхшы якка үзгәртер. Дөреслектә, без Раббыбыз Аллаһыга омтылабыз».

10) Кешегә кайгы ирешкәндә түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ إِنِّي عَبْدُكَ وَابْنُ عَبْدِكَ رَضِيتُ حُكْمَكَ وَقَضَائَكَ

أَسْئَلُكَ أَنْ تُذْهِبَ عَنِّي غَمِّي وَحَزَنِي وَأَنْ تَرْزُقَنِي يُسْرَ عُسْرِي

Әллааһүммә иннии гәбдүкә үәбнү гәбдикә радыйтү хүкмәкә үә кадаа'әк. Әс'әлүкәән түҙһибә гәннии гаммии үә хәзәнии үәән тәрзүкании йүсра гүсрии

Мәгънәсе: «Йә Рабби, дөреслектә, мин Синең колың һәм колыңның улы. Синең хөкемеңә һәм тәкдиреңә разыймын. Күңелемдәге кайгыны һәм көенечне бетереүңне Синнән сорыймын. Кайгы артыннан шатлык насыйп ит».

11) Яңа ай туганны күргәндә түбәндәге дога укыла:

اَللهُ أَكْبَرُ اَللَّهُمَّ أَهِلَّهُ عَلَيْنَا بِالْأَمْنِ وَالْإِيمَانِ وَالسَّلَامَةِ وَالْإِسْلَامِ

اَللَّهُمَّ اجْعَلْهُ لَنَا هِلَالَ خَيْرٍ وَرُشْدٍ

Әллааһү әкбәр (3 мәртәбә). Әллааһүммә әһилләһү гәләйнәә бил-әмни үәл-имәәни үәс-сәләәмәти үәл-исләәм. Әллааһүммә-җгәлһү ләнәә һиләәлә хайрин үә рушд

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәдән олуграк. Йә Рабби, бу айны безгә иминлек һәм иман, сәламәтлек һәм мөселманлык белән тудыр. Шулай ук аны безгә изгелек һәм тугрылык ае итеп кыл».

12) Күк күкрәгәндә һәм яшен яшьнәгәндә түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ لَا تَقْتُلْنَا بِغَضَبِكَ وَلَا تُهْلِكْنَا بِعَذَابِكَ وَعَافِنَا بِرَحْمَتِكَ

Әллааһүммә ләә тәкътүлнәә бигадабикә үә ләә түһликнәә бигәҙәәбикә үә гәәфинәә бирахмәтик

Мәгънәсе: «Йә Рабби, безне ачуың һәм газабың белән һәлак итмә, рәхмәтең белән безгә исәнлек-саулык бир».

13) Яңгыр яуганда түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ سَقْيًا هَنِيئًا وَصِيبًا نَافِعًا اَللَّهُمَّ اجْعَلْهُ صِيبَ رَحْمَةٍ وَلَا تَجْعَلْهُ صِيبَ عَذَابٍ

Әллааһүммә сәкйән һәнии'ән үә сыйбән нәәфигәә. Әллааһүммә-җгәлһү сыыйбә рахмәтин үә ләә тәҗгәлһү сыыйбә гәҙәәб

Мәгънәсе: «Йә Рабби, бу яңгырны безнең өчен рәхәт һәм файдалы ит. Йә Рабби, бу яңгырны рәхмәт яңгыры кыл, газап яңгыры кылма».

14) Дәрес башланыр алдыннан укыла торган дога:

اَللَّهُمَّ ارْزُقْنَا عِلْمًا نَافِعًا وَحِفْظًا كَامِلًا وَذِهْنًا شَامِلًا وَفَهْمًا ذَكِيًّا وَتَوْفِيقًا لِتَحْصِيلِ الْعُلُومِ اَللَّهُمَّ اَخْرِجْنَا مِنْ ظُلُمَاتِ الْجَهْلِ

وَالْوَهْمِ وَأَكْرِمْنَا بِنُورِ الْعِلْمِ وَالْفَهْمِ اَللَّهُمَّ افْتَحْ لَنَا أَبْوَابَ عِلْمِكَ

وَانْشُرْ عَلَيْنَا خَزَائِنَ رَحْمَتِكَ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ

Әллааһүммә-рзүкнәә гильмән нәәфигән үә хифҙан кәәмилән үә ҙиһнән шәәмилән үә фәһмән ҙәкийййән үә тәүфиикан литәхсыыйлил-гүлүүм. Әллааһүммә әхриҗнәә мин ҙулүмәәтил-җәһли үәл-үәһми үә әкримнәә бинүурил-гильми үәл-фәһм. Әллааһүммә-фтәх ләнәә әбүәәбә гильмикә үәншүр гәләйнәә хазәә’инә рахмәтик. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин

Мәгънәсе: «Йә Рабби, файдалы гыйлем, яхшы истә калдыру, камил зиһен һәм дөрес аңлауны насыйп ит. Йә Рабби, безне наданлыктан һәм күңел караңгылыгыннан чыгарып, гыйлем һәм аңлау нуры белән хөрмәтлә. Йә Рабби, безгә гыйлем ишекләрен һәм Үз рәхмәт хәзинәләреңне ач. Әй рәхмәтле Аллаһ, һәрбер нәрсә Синең рәхмәтең белән була».

15) Дәрес тәмамланганнан соң укыла торган дога:

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى أَخْرَجَنَا مِنْ ظُلُمَاتِ الْجَهْلِ وَالْوَهْمِ وَنَوَّرَ قُلُوبَنَا

بِنُورِ الْعِلْمِ وَالْفَهْمِ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لَنَا وَلِوَالِدَيْنَا وَلِأُسْتَاذِنَا وَسَلِّمْ دِينَنَا

وَاجْعَلْ مَلِكَنَا سَالِمًا وَرَؤُفًا لَنَا بِحَقِّ نَبِيِّنَا

مُحَمَّدٍ الْمُصْطَفَى صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ

Әлхәмдү лилләәһил-ләҙии әхраҗнәә мин ҙулүмәәтил-җәһли үәл-үәһм. Үә нәүүәра кулүүбәнәә бинуурил-гильми үәл-фәһм. Әллааһүммә-гфир ләнәә үә лиүәәлидәйнәә үә лиүстәәҙинә үә сәллим диинәнәә үәҗгәл мәликәнәә сәәлимән үә раүү'фән ләнәә бихәкки нәбиййинәә Мүхәммәдинил-мүстафәә саллаллааһу гәләйһи үә сәлләм

Мәгънәсе: «Һәрбер мактау Аллаһы Тәгаләгә генә хас. Аллаһы Тәгалә безне наданлык һәм аңламаулык караңгылыгыннан чыгарды һәм безнең күңелләребезне гыйлем һәм аңлау нуры белән нурландырды. Йә Рабби, Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ хакына (хөрмәтенә) безнең гөнаһларыбызны, әти-әни һәм остазларыбызның гөнаһларын ярлыка, безнең динебезне дә, дөньябызны да төзек һәм сәламәт кыл. Шулай ук җитәкчебезне сәламәт һәм безгә шәфкатьле һәм мәрхәмәтле кыл».

16) Һәрвакыт һәм һәр урында укырга мөмкин булган дога һәм зикер:

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ عَلَى كُلِّ حَالٍ فَإِنَّهُ مُحَوِّلُ الْأَحْوَالِ رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الْآخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ

Әлхәмдү лилләәһи гәләә күлли хәәлин фәиннәһүү мүхәүүилүл-әхүәәл. Раббәнәә әәтинәә фид-дүнйәә хәсәнәтән үә фил-әәхырати хәсәнәтән үә кыйнәә гәҙәәбән-нәәр. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин

Мәгънәсе: «Һәр хәл өчен Аллаһы Тәгаләне мактыйбыз, чөнки хәлләрне үзгәртүче Ул. Йә Рабби, безгә дөньяда да, ахирәттә дә изге хәлләрне насыйп ит. Шулай ук безне җәһәннәм газабыннан сакла, Әй Рәхмәтле Аллаһ, бөтен нәрсә Синең рәхмәтеңдә».

МӨСЕЛМАН ЕЛЫ (АЙЛАРЫ)

Мөселманнар еллар исәбен хәзрәти Расүл ﷺ нең Мәккәи Мөкәррәмә шәһәреннән Мәдинәи Мөнәвәрәгә күчкән вакытыннан башлап хисаплыйлар. Бу вакыйга миладе ел исәбе буенча 622 елның 17 нче августында булган.

Мөселманнар елны ай йөреше белән исәплиләр. Кояш баеганнан соң, күктәге ай бик нәзек алтын урак кебек булып күренгән вакыт ай башы булып санала. 29 яки 30 көн үткәннән соң икенче ай күренгәч, яңа ай башлана. 12 ай бер елга хисаплана.

Ай исемнәре гарәп телендә түбәндәгечә була: мөхәррәм, сәфәр, рабигыль-әүвәл, рабигыль-ахир, җөмадиәл-әүвәл, җөмәдиәл-ахир, рәҗәб, шәгъбан, Рамазан, шәүвәл, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә.

Ел башы мөхәррәм аеннан башлана. Мөхәррәм ае күбесенчә 30 көннән, сәфәр – 29, рабигыль-әүвәл – 30, рабигыль-ахир – 29, җөмадиәл-әүвәл – 30, җөмадиәл-ахир – 29, рәҗәб – 30, шәгъбан – 29, Рамазан – 30, шәүвәл – 29, зөлкагъдә 30 көннән, зөлхиҗҗә ае кайсы елларда 29, кайсыларында 30 көннән килә.

Ай хисабында тәүлекнең башы кояш баеганнан соң башлана. Һәр көннең кичәсе үзеннән элегрәк була. Яңа айның беренче кичәсе – иске айның ахыргы көненнән соңгы кичә, икенче кичәсе – беренче көненнән соңгы кичә.

БӘЙРӘМ КӨННӘР ҺӘМ КИЧӘЛӘР

Бер ел эчендә мөселманнарның мөбарәк көннәре һәм кичәләре барлыгы ундүрт: ел башы көне, гашура көне, һиҗрәт кичәсе, мәүлид кичәсе, рәгаиб кичәсе, мигъраҗ кичәсе, бәраәт кичәсе, фәтех Мәккә көне, кадер кичәсе, гайдел-фитыр көне, гайдел-Корбан көне, тәшрикъ көннәре.

Ел башы көне – мөхәррәм аеның беренче көне. Ай хисабынча яңа ел башланган көн.

Гашура көне – мөхәррәм аеның 10нчы көне. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ һәм сәхабәләр ул көнне мөбарәк санап ураза тотканнар. Күп пәйгамбәрләр бу көнне зур афәт һәм бәлаләрдән котылганнар.

Һиҗрәт кичәсе – сәфәр аеның 27 нче кичәсе. Ул кичәдә хәзрәти Расүл ﷺ хәзрәти Әбүбәкер ؓ белән бергә, Мәккәи Мөкәррәмә шәһәреннән чыгып, рабигыль-әүвәлнең 12 нче көнендә Мәдинәи Мөнәвәрә шәһәренә барып җитәләр. Бу сәфәрдән соң Ислам дине һәр тарафка тарала башлый, шуның өчен мөселман елы шушы елның мөхәррәм аеннан башлап хисаплана.

Мәүлид кичәсе – рабигыль-әүвәл аеның 12 нче кичәсе. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ 570нче елның 27 нче апрелендә – 12 нче рабигыль-әүвәлдә дөньяга килгән. Бу көн барлык мөселманнар өчен бик мөбарәк, чөнки

Пәйгамбәребез ﷺ нең туусы дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирешүебезгә сәбәпче булган.

Рәгаиб кичәсе – рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кичә. Бу кичәдә хәзрәти Расүл ﷺ нең атасы хәзрәти Габдулла белән анасы хәзрәти Әминәнең никахлары һәм беренче очрашулары булган.

Мигъраҗ кичәсе – рәҗәб аеның 27 нче кичәсе. Бу кичәдә хәзрәти Расүл ﷺ күкләргә ашкан. Биш вакыт намаз уку шушы кичәдә фарыз кылынган.

Бәраәт кичәсе – шәгъбан аеның 15 нче кичәсе. Риваятьләр буенча кешеләрнең берьеллык язмышлары, бәхете һәм сәгадәте шушы кичәдә билгеләнә, шуның өчен ул изге кичәләрдән санала.

Фәтех Мәккә көне – Рамазан аеның 21 нче көне. Бу көндә Аллаһының Расүле ﷺ үзенең 12 мең сугышчыдан торган гаскәре белән Мәккәи Мөкәррәмә шәһәрен дингә ышанмаган мәҗүсиләр, кяферләр кулыннан азат итә һәм мөселманнарның кыйбласы булган Кәгъбәтулладан табыну өчен хезмәт иткән таш сыннарны чыгарттыра.

Кадер кичәсе – Рамазан аеның 27 нче кичәсе. Бу кичәнең кайсы көнгә туры килүе төгәл билгеле булмаса да, риваятьләр буенча, Рамазанның 27 нче кичәсенә туры килүе ихтимал. Бу кичәдә изге гамәлләренең савабы башка кичәләргә караганда бик күпкә артыграк.

Гайдел-фитыр көне (Ураза бәйрәме) – шәүвәл аеның беренче көне. Рамазан уразасы тәмамлангач, бәйрәм ителә торган көн. Бу көндә гает (бәйрәм) намазын уку һәр мөселманга – вәҗиб. Бай кешеләргә гает намазына кадәр фәкыйрьләргә фитыр сәдакасы бирү дә вәҗиб.

Корбан гаете көне – зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне. Бу көндә дә гает намазын уку – вәҗиб. Гает намазыннан соң корбан чалып, гаиләләрен, кардәшләрен һәм фәкыйрьләрне хөрмәтләү – бай кешеләргә вәҗиб. Гает алды көне «Гарәфә көне» дип атала. Ул көн дә мөбарәк көннәрдән санала. Хаҗ гамәлләре шул вакытта үтәлә. Һәр елны, дөньяның барлык илләреннән җыелган берничә йөз мең хаҗи Гарәфә көнендә Гарәфәт тавында (үзәнлегендә) дога һәм гыйбадәт кыла.

Тәшрикъ көннәре – зөлхиҗҗә аеның 11 нче, 12 нче һәм 13 нче көннәре. Алар бәйрәм көннәре булып санала. Гарәфә көненең иртәнге намазыннан башлап, өченче тәшрикъ көненең икенде намазына кадәр җәмәгать намазларыннан соң мөселманнар, һәр тарафта кычкырып, «Тәкбир-тәшрикъ»[1] әйтәләр.

Һәр җомга көн – барча мөселманнар өчен олуг бәйрәм. Алда әйтелгән барлык бәйрәмнәрне мөселманнар фәкыйрьләргә ярдәм итеп, догалар укып, тәүбәләр һәм башка изге гамәлләр кылып үткәрергә тиешләр.

Тәмам.

---

[1] Тәкбир-тәшрикъ: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләһә илләллааһу үәллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр үә лилләәһил хәмде» дигән сүзләр

ЭЧТӘЛЕК

ӘҺМӘДҺАДИ МАКСУДИ 4

ГАКЫЙДӘ 6

ИСЛАМ ДИНЕ 6

ГАМӘЛ 7

БАЛИГЪЛЫК ҺӘМ АКЫЛ 8

ГЫЙБАДӘТ 9

ИМАН ҺӘМ ИКЪРАР 10

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ 11

ФӘРЕШТӘЛӘР 14

ПӘЙГАМБӘРЛӘР 15

КИТАПЛАР 16

ТӘКЪДИР 16

АХЫРЗАМАН ҺӘМ КЫЯМӘТ 17

ҖӘННӘТ ҺӘМ ҖӘҺӘННӘМ 18

МӨХӘММӘД ﷺ 19

СӘХАБӘЛӘР 21

ТӘҺАРӘТ 23

ТӘҺАРӘТ 24

ТӘҺАРӘТНЕҢ ФАРЫЗ, СӨННӘТ ҺӘМ МӨСТӘХӘБЛӘРЕ . 25

ТӘҺАРӘТНЕҢ МӘКРУҺ ҺӘМ МӨФСИДЛӘРЕ 27

ЧИТЕКЛӘРГӘ МӘСЕХ КЫЛУ 28

БӘЙЛӘВЕЧ (ПОВЯЗКА) 29

ГОСЕЛ 30

ГОСЕЛНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ 31
ГОСЕЛНЕҢ СӨННӘТЛӘРЕ 32
ГОСЕЛНЕҢ СӘБӘПЛӘРЕ 32
САХИБЕ ГОЗЕР 33
ТӘЯММҮМ 34
ТӘЯММҮМНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ, СӨННӘТЛӘРЕ
ҺӘМ МӨФСИДЛӘРЕ 36
НӘҖЕСЛӘР 37
НӘҖЕСЛӘРДӘН ПАКЬЛӘҮ 38
ПАКЬЛӘНҮ 39
ПАКЬ СУЛАР 40
КОЕ СУЫ 40
ГАУРӘТ 41
ГОЗЕРЛЕ ХАТЫННАР 42

НАМАЗ 43
НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ 44
КЫЙБЛА 46
НИЯТ 47
АЗАН ҺӘМ КАМӘТ (ИКАМӘТ) 48
АЗАННЫҢ МӨСТӘХӘБЛӘРЕ 51
НАМАЗНЫҢ ЗИКЕРЛӘРЕ 53
ИКЕ РӘКӘГАТЬЛЕ НАМАЗ УКУ РӘВЕШЕ 63
ДҮРТ РӘКӘГАТЬЛЕ НАМАЗ УКУ РӘВЕШЕ 64
ХАТЫННАР НАМАЗЫ 66
ТӘСБИХ ҺӘМ ДОГА 67

ЗӘГЫЙФЬ КЕШЕНЕҢ НАМАЗЫ 71
НАМАЗНЫҢ ШАРТЛАРЫ 73
НАМАЗНЫҢ РӨКЕННӘРЕ.......... 73
НАМАЗНЫҢ ВӘҖИБЛӘРЕ 74
НАМАЗНЫҢ СӨННӘТЛӘРЕ 76
НАМАЗНЫҢ МӨСТӘХӘБЛӘРЕ.......... 79
НАМАЗНЫҢ МӘКРУҺЛАРЫ.......... 81
НАМАЗНЫҢ МӨФСИДЛӘРЕ 86
НАМАЗДА МӨБАХ БУЛГАН (РӨХСӘТ ИТЕЛГӘН) ЭШЛӘР 87

ҖӘМӘГАТЬ 90
МӨДРИК ҺӘМ МӘСБҮК 92
МӘЧЕТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ 94
НАМАЗНЫҢ КАЗАСЫ 96
СӘҖДӘИ СӘҺҮ.......... 98
НАМАЗДА САТАШУ 101
СӘҖДӘИ ТИЛӘВӘТ.......... 103
МОКЫЙМ ҺӘМ МОСАФИР.......... 105
ҖОМГА НАМАЗЫ.......... 107
ГАЕТ (БӘЙРӘМ) НАМАЗЛАРЫ.......... 111
ТӘРАВИХ НАМАЗЫ 113
ҖЕНАЗА НАМАЗЫ.......... 117
НӘФЕЛ НАМАЗЛАРЫ 121

УРАЗА, ЗӘКЯТ ҺӘМ ХАҖ.......... 129
УРАЗА.......... 130
ИГЪТИКЯФ 136

ЗӘКЯТ 137
ЗӘКЯТ МАЛЛАРЫ 138
НИСАБ (ЗӘКЯТ МАЛЫНЫҢ КҮЛӘМЕ) 139
ЗӘКЯТ БИРЕЛӘ ТОРГАН КЕШЕЛӘР 141
ГОШЕР (ҖЫЕЛГАН УҢЫШНЫҢ САЛЫМЫ) 142
ФИТЫР.. 143
ФИДИЯ.. 144
СӘДАКА.. 145
КОРБАН.. 146
ХАҖ 149
ХАҖ ГАМӘЛЛӘРЕ 152
ТӨРЛЕ ДОГАЛАР.. 158
МӨСЕЛМАН ЕЛЫ (АЙЛАРЫ) 167
БӘЙРӘМ КӨННӘР ҺӘМ КИЧӘЛӘР 168

Белешмәләр өчен

Ахмадхади МАКСУДИ

«Гыйбадат Исламия»

На татарском языке

Әхмәдһади МАКСУДИ

«Гыйбадәте Исламия»

Безгә яхшырак булырга ярдәм итегез!
Әгәр дә текстларда хаталар күрсәгез,
marketing@huzur.ru электрон почтасына языгыз

Редакция фикере автор фикере белән
тәңгәл килмәскә мөмкин

**Күпләп сатып алу өчен +7 (843) 202-07-74
номерына шалтырата аласыз.**

«Хозур» нәшрият йорты.
420111 Казан, Лобачевский урамы, 6.
Тел./факс: +7 (843) 202-07-74.
Сайт: http://www.huzur.ru
Электрон почта: huzur.inform@mail.ru
Интернет-кибет: http://huzurshop.ru

Оригинал-макеттан басарга кул куелды: 28.03.2016.
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$, басма кәгазьдә.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан шәһ., Декабристлар ур., 2.

Тиражы 5000 данә.
Заказ М-1005.

ISBN 978-5-9907871-2-4
9 785990 787124